Людмила
Васильева-Гангнус

Әдәплелек әлифбасы

Людмила
Васильева-Гангнус

ӘДӘПЛЕЛЕК ӘЛИФБАСЫ



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1992

ББК 74.113
В19

Русча икенче басмадан
Ф. Г. Иштирәкова һәм *Р. И. Раскулова*
тәрҗемәсе

Художнигы В. А. МАЛЯКИН

Икенче басма

В $\frac{4312000000—046}{М\ 132(03)—92}$ Б3—58—53—91 ББК 74.11

ISBN 5—298—01110—1

© Издательство «Педагогика», 1984
© Татарчага тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 198

ЭЧТӘЛЕК

Һәркем белергә тиешле әлифба... 5

Әкият ничек туа 7

Әти-әниләргә киңәшләр 11

Әкият-шәһәр һәм анда яшәүчеләр 13

Әдәпле булу ни өчен кирәк? 16

Феянең кайтуы 17

Акыллы-зирәк Гномнар 22

Әдәпкә өйрәнүнең беренче дәресе 25

«Әдәпле кеше» дип кемгә әйтәләр? (әти-әниләр белән сөйләшү) 26

Алешаның әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие ничек итеп әкияттәгедәй әдәпле кешегә әверелгәннәр 28

Әти-әниеңә һәм гаиләгездәге башка кешеләргә карата мөнәсәбәтең турында 34

Әбием бәйрәме 36

Әдәпкә өйрәнүнең икенче дәресе 37

Дуслар белән ничек һәм нәрсә уйнарга? 38

Нәрсәдән башларга? (әти-әниләр белән сөйләшү) 39

Җанланган рәсемнәр 42

Син яшәгән йортта 48

Күмәк уеннар 49

Буяулар бәйрәме 50

Әдәпкә өйрәнүнең өченче дәресе 51

Иҗатка якынайтып тәрбияләү (әти-әниләр белән сөйләшү) 52

Акылга сыймаслык маҗаралар 54

Чын тылсым ияләре (балалар белән сөйләшү) 59

Әдәпкә өйрәнүнең дүртенче дәресе

Могҗизалар бәйрәме 62

Бәйрәмнәрнең тәрбияви роле (өлкәннәр белән сөйләшү) 63

Алдау 66
Намуслы булу нигә кирәк? 71
Шат күңелле хыялыйлар бәйрәме 73
Балалар нигә ялган сөйли?
(өлкәннәр белән сөйләшү) 74
Урманда әдәплелек дәресләре 76
Урман уеннары 78

Аждаһа сатам! 79
Малайлар, кызлар 86
Дуслар бәйрәме 87
Акыллы-зирәк Гномнар белән хушлашу 89
Үз үрнәгеңдә тәрбияләү
(өлкәннәр белән сөйләшү) 89

Феяне ничек уятырга инде? 94
Кунакка чакыру 100
Имтихан сораулары 101

Могҗизалар кире кайта 102
Әкият иленә сәяхәт 107
Ышаныч күрсәтеп тәрбияләү 109

ҺӘРКЕМ БЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ӘЛИФБА...

Сез укыячак әлеге китапның эчтәлеген сөйләп тормыйм, ул — балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятының матур традицияләрен дәвам иттерә. Лев Кассильнең, мәсәлән, «тәрбиялелек тәрбияләү», әдәплелек тәрбияләү яисә төгәлрәк итеп әйтсәк, аралашу культурасына багышланган акыллы һәм тирән эчтәлекле публицистик әсәрләре аз түгел. «Әдәплелек әлифбасы»ның авторы үзалдына шул ук максатны — бик җитди һәм игелекле максатны куйган.

Әлеге китапны балалар белән өлкәннәр бергәләп укырга тиеш. Театр, концерт, күргәзмәләргә гаилә белән бару, бергәләп китаплар уку бик мөһим һәм ике як өчен дә гаять файдалы. Өлкәннәрнең сабыйларга нәрсәнедер төшендерә, аңлата алуы гына түгел, бәлки бәләкәйләрнең ничек кабул итүләре, аларның сораулары һәрвакыт үтә гыйбрәтле, ә кайчак тәрбиячеләр өчен көтелмәгән булуы белән дә һәр ике якка файдалы дип әйтер идем.

Әкият ялган, ләкин хак —
Шәп егетләргә сабак.

Хикәяләрнең эчтәлегенә табигый үрелеп барган әкият мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге шук малайлар-кызлар күңеленә хуш килер дип уйлыйм. Ул, балаларга, аларның өлкән дусларына багышланган әңгәмәләр шикелле үк, кызыклы һәм мавыктыргыч итеп язылган, анда күңелсез үгет-нәсыйхәтләр юк, үзе тирән фикерләргә, хыялга гаять бай.

Яшьләр һәм өлкәннәр өчен Людмила Васильева-Гангнус тәкъдим иткән «Әдәплелек әлифбасы»н белү һәркемгә зарур.

Китапның беренче битен ачыгыз әле — сезне «әлифба» көтә.

Анатолий АЛЕКСИН

ӘКИЯТ НИЧЕК ТУА
(Кереш сүз урынына)

Олы кешеләр дә кайчандыр бәләкәй булганнар бит, тик күбесе моны оныткан гына.
Антуан де Сент-Экзюпери

Һәрбер олы кеше хәзерге көненә балачакны узып килә. Аның балачагы нинди булган — бу Барлык Башлангычның да Башлангычы,— безнең бүгенге тормышыбызны билгели.

Балаларыбызга мирас итеп нәрсә калдыра алабыз, аларга нинди тәрбия бирәбез — болары да балачагыбызга бәйле.

Улларыбыз-кызларыбызның акылфигыльләре нәкъ менә балачактан (алай гына да түгел, бик кечкенәдән) тәрбияләнә. Моны безгә, өлкәннәргә, аз гына да истән чыгарырга ярамый. Баланы тәрбияләү һәрвакыт, иң элек тәрбияченең, олы кешенең үз-үзен тәрбияләвеннән башлануын да безгә нык истә тотарга кирәктер, мөгаен. Педагогик белемнәребезне туктаусыз, даими рәвештә тирәнәйтү, тулыландырып тору, югары культуралылыкка омтылу, үзеңне кешеләр белән дөрес аралаша белергә күнектерү, үзебез һәм балаларыбыз яши торган чиксез киң дөньяның бар нәрсәсенә игътибарлы булырга өйрәнү менә ни өчен кирәк икән.

Һәр гаиләнең педагогик культурасын шул халыкның педагогик традицияләре билгели. Бу культура бөртекләп җыелырга һәм буыннан-буынга күчә барырга тиеш.

Шунлыктан, безгә әти-әниләребезнең тәҗрибәсен аңлау, шулардан иң яхшысын сайлап алу, алар җибәргән ялгышларны кабатламас өчен, вакыт-вакыт үзебезнең балачагыбызга борылып карау бик тә мөһим.

... Безнең буын кешеләре үзенең балачагын искә төшергәндә, хәтердә сугыштан соңгы еллар яңара. Баласына бер сынык икмәк тоттырырга аптыраган аналар... Әле генә фронттан кайтып, йортыннан, гаилә җылысыннан читләшкән аталар... Ә кайтмый калганнары күпме...

Үз әтисенең йөзен дә хәтерләмичә үскән малайлар һәм кызлар... Андый гаиләләрдә тормыш авырлыгы тулысы белән аналар җилкәсенә төште, алар туйдыручылар гына түгел, балаларына бердәнбер тәрбияче дә үзләре булдылар.

Ата тәрбиясеннән башка бала үс-

терүнең никадәр авыр икәнен аңлатырга мөмкинме соң? Ул чактагы сугыш җимереклегән һәм иң кирәкле нәрсәләрнең җитешмәвен искә алсак, бигрәк тә... Гаиләдә һәр бала күңеленә ятышлы атмосфераны булдыру өчен, бу аналар үзләрендә ни рәвешле көч һәм батырлык, кайдан вакыт тапканнар соң? Әлеге рәхимсез, ачлангач елларда да балаларына ягымлы караш, сөю, ана мәхәббәтен бүләк итә алганнар икән, нинди бетмәс-төкәнмәс хатын-кыз һәм ана назына, нинди сабырлыкка ия булган бу аналар!

... Әтиебез яраланса да, безнең бәхеткә каршы, сугыштан исән-сау кайтты. Шуңа күрә әти-әниемә дүрт баланы тәрбияләп үстерү (башка бик күп әтисез гаиләләргә караганда) җиңелрәк булгандыр дип уйлыйм. Ләкин шулай да, уйларымда ул авыр, хәрабәле елларга әйләнеп кайтсам, мин әти-әниемнең булуларын, безне дәгъвасыз, ләкин таләпчән ратуларын искә төшереп гаҗәпләнми кала алмыйм. Алар эштән бушаган сәгатьләрен һәм минутларын (ә ул вакытта өлкәннәр, эшче көчләр җитмәгәнлектән, бик күп эшләделәр, илне җимереклектән чыгарырга кирәк иде!) безгә багышладылар. Бу, күрәсең, әнинең укытучы булуыннан да килгәндер. Нәкъ менә аның педагогик белемнәре һәм тәҗрибәсе безнең балалык дөньябызны төрле уеннар, тылсымлы әкиятләр, күңелле хыял-фантазия белән тулыландырырга ярдәм итте.

Әниебезнең тырышлыгын мөмкин кадәр әтиебез куәтләп тора иде. ... Безнең өебездә сатып алынган бер генә уенчык та булмады. Аның каравы, гаҗәеп матур итеп агачтан кисеп эшләнгән, төрле тавыш чыгарып сызгыра торган сыбызгы, курайлар, сырлап ясалган уенчык җәнлекләр һәм тагын шундый әкәмәт әйберләр (алар, ихтимал, авылдан, әтинең балачагыннан ук килгәндер) белән уйнап үстек. Без үзебез һәм дус малайларның күпчелеге бу уенчыклар белән уйнаганда, сирәк очрый торган серле бер могҗизага караган кебек, аларга карата ихтирамлы һәм игътибарлы була идек.

Безнең театр да шундый ук тылсымлы могҗизага әверелде. Ул, һәр кич, бердәнбер кысан бүлмәбезне тулыландырып, әкиятләр укудан башланды...

Безгә әкият тыңларга күп санлы дусларыбыз һәм әнинең укучылары җыела иде. Бергәләшеп китаплар укый, үзебез уйлап чыгарган әкиятләрне сөйли торган идек. Соңыннан, әкияттәге кайсы да булса геройның кылган эшләрен дөрес аңларга һәм аңа үзебезнең мөнәсәбәтебезне билгеләргә, «киная» белән әйтелгән (ул «киная» безнең өчен әкият тылсымы биргән чираттагы «дәрес» була иде) төп фикерне отып алырга тырышып, кызып-кызып бәхәсләшә идек.

Шундый сөйләшүләрнең берсендә әни безгә әкият геройлары өчен маска рәсемнәрен ясап, аларны кисәргә һәм әкиятне «сәхнәләштереп» уйнарга тәкъдим итте.

Менә шуннан башланып китте инде.

Ял көннәрендә бу «тамаша»ны без биек өйалды баскычында күрсәтә идек. Якын-тирә малайлары һәм кызлары җыйнаулашып баскычны урап алалар иде. Соңыннан барыбыз бергә — «артистлар» һәм «тамашачылар» — бер-беребезне уздыра-уздыра әкияттәге вакыйгаларны, аның геройларын тасвирлап бирергә тырыша идек. Әлеге бәхәсле әңгәмәләргә, күңелле өстәп, ләкин аз гына да йөдәтмичә, гомумән, безгә сиздермичә әни җитәкчелек итте. Безнең кечкенә шәһәрчегебездә театр булмавын һәм китапханә дә мәктәптә генә оеш-

тырылып, анысы да бик ярлы булуын истә тотыпмы, әни безгә, сүз уңаеннан, чын театр һәм төрле батырлыклар тасвирланган китапларның эчтәлеген сөйли, китап геройларының характерларын һәм кылган эшләрен чын тормыштагы кешеләр характеры белән чагыштырып күрсәтә иде. Әни безне әнә шулай әкияттән тормышның үзенә алып чыкты, безне уйларга, әйләнә-тирә дөньяга игътибарлы булырга өйрәтте.

Әти белән әнинең ызгышканын минем ишеткәнем булмады. Тормышның четерекле һәм күңелсез якларына алар һәрвакыт түземле булдылар, шәхси проблемаларын яки кәефсезлекләрен башка кешегә аудармыйча, уен-көлке белән үткәреп җибәрәләр иде. Без боларның барысын да күрә һәм үзебезгә отып ала идек.

Гаиләдәге эшләр олылар һәм кечеләр арасында төгәл бүленгән, иде, әти белән әни һәркайсыбыздан үз бурычларыбызны даими үтәвебезне катгый таләп иттеләр. Шул ук вакытта алар мактауга, назга беркайчан саранланмадылар. Иң шатландырганы — безнең өйдә өлкәннәрдән беркем һичкайчан балаларга ялыктыргыч үгет-нәсыйхәт биреп вәгазь укымады. Ул вазифаны Саумы фея үтәде.

Саумы фея — алъяпкыч, кемнеңдер иске күзлеге кидерелгән зур, килбәтсез чүпрәк курчак иде. Әни безне, Саумы феянең күзлеге тылсымлы һәм аның пыяласы аша ул сезнең кыланышларыгызны күрә, хәтта уйларыгызны да укый ала дип, алдан кисәтеп куйды. Ә без исә аның шулай булуына күп тапкырлар ышандык. Чөнки нәрсә генә кылсак та, феянең кесәсеннән шул эшкә карата бәя табып ала идек. Әгәр бу начар эш булса, Саумы феянең ачуы чыга иде. Гөнаһларыбыз артык күбәеп китсә, ул үзенең иске зонтында әкияттәге билгесез юнәлештә очып та китә ала иде. Ә без, фея кире әйләнеп кайтсын өчен, өч көн буена әтиәнидән кисәтү алмаска тиеш идек.

Атнага ике тапкыр Саумы фея әни кулында җанлана һәм әдәплелек дәресләре үткәрә. Әни тавышы белән ул кунакта, транспортта, урамда, табын янында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында сөйли. Безнең өчен файдалы әллә никадәр мәгълүмат әйтә. Чынында, бу безнең кебек балаларны, күңелле, итагатьле булырга өйрәтүче кызыклы уен һәм әкият булып чыга иде.

Безгә кунакка килгән апаның әлегә кадәр күргәнем булмаган һәм шуңа күрә миңа могҗиза булып тоелган бик кечкенә сәгатен сүткәч, әнинең шелтәле карашыннан качу өчен, иске зонтны тикшергәләп, кая да булса ераккарак очу теләге белән хыялланып йөргән бер вакытта фея кинәт (йокысыз төнгә каршы, соң гына) әни кулында тагын җанланды, пышылдап кына сәгатьнең гаҗәеп тарихын сөйләп бирде. Аны искиткеч осталар эшләве, сәгатьнең кешегә нинди хезмәт күрсәтүе... гади генә булып күренгән бик күп әйберләрне ничек итеп сак тотарга кирәклеге турында сөйләде ул... Шул вакытта дип әйтмим, әмма тагын шундый берничә дәрестән соң, мин тирә-юнемдәге әйберләрне кетмәгәндә башкача тоя башладым. Хәзер инде савытсабаларны юганда, иске китапларны ябыштырганда, тузан сөрткәндә тырышыбрак эшли торган булдым. Өлкәннәрнең һәркайсына балаларны тәрбияләү хокукына ирешү өчен, чиксез зур түземлелек, киң күңеллелек һәм чаманы белеп ярату таләп ителә. Күрәсең, минем әти-әнием бу сыйфатларга ия булганнардыр. Менә шуның өчен дә мин күңелем белән еш кына балачагымда йөрим дә инде.

Һәркемнең балачагы әйләнеп

кайтмаслык юллар, үтә алмаслык диңгез, урман, таулар артында, җиде кат җир читендә калса да, хәзерге көненә һәркайсыбыз шул юлларны кичеп килгән бит. Әлеге юллар Барлык Башлангычның да Башлангычы булып тора. Безнең бүгенге көнебез шуңа бәйле дә.

Хәзерге балалар муллыкта үсәләр. Барысы да матур киенгән, буй-сыннары килгән, сәламәтләр, күп яклары белән алар безнең балачагыбызны хәтерләтмиләр инде. Бүгенге баланың бүлмәсендә нәрсә генә юк! Шүрлек тулы китап, киштә тулы уенчык. Кинопроекторлар. Велосипед. Буяулар, төсле карандашлар.

Бүгенге көндә бездә яшь буынның дөрес һәм һәрьяклап үсеше өчен материаль шартларның бөтенесе дә диярлек бар. Бу шартлар баланы физик яктан сәламәт, матур итеп үстерү, аның аңын камилләштерү, хисточгыларын тәрбияләү һәм аңарда игелеклелек чаткыларын кабызу өчен тудырылган.

Һәр ата-ана бөтен җаны-тәне белән үз баласының яхшы булуын тели! Менә ни өчен без малайларыбызда һәм кызларыбызда кайчак әлеге ата-ана хыялына бөтенләйгә туры килмәгән кайбер чит сыйфатларны күреп ачынабыз. Яшерен-батырын түгел... хәзерге балалар кайчак кеше хезмәте белән исәпләшмиләр, аны хөрмәтләмиләр, өлкәннәргә илтифатсызлык күрсәтәләр. Еш кына җәмәгать урыннарында, урамда кешеләргә һәм өйдә якыннарына карата үзләрен итагатьсез тоталар. Кайчак игътибарсыз булалар, тупаслыкка кадәр барып җитәләр. Ә иң ачындырганы — аларда, вакыт-вакыт, һәр кеше өчен мәҗбүри булган миһербанлылык, игелеклелек, әйләнә-тирәгә игътибарлы, инсафлы караш җитми.

Бәлки, безнең гаилә һәм педагогик белемнәребез җитәрлек булмавының аяныч нәтиҗәседер бу? Бәлки, без сезнең белән хөрмәтле әниләр, әтиләр, әбиләр, бабайлар, тәрбия эшендә әлекке тәҗрибәләребезгә, үз сиземләвебезгә генә таянырга ярамаганлыкны, аны идея белән сугарырга, хәзерге педагогик белемнәр белән ныгытырга кирәклекне бик еш онытып җибәрәбездер? Бәлки әле, хикмәт бөтенләй башкададыр. Без, өлкәннәр, үзебезнең улларыбызга, кызларыбызга миһербанлылык, игътибарлылык, сабырлык һәм ихтирамлылык мисалларын үз арабызда сирәк күрсәтәбездер? Бәлки, гаилә эчендә үзара аңлашу, дуслык, ышанучанлык һәм кайгыртучанлык атмосферасын даими булдырып тору, ныгытуда җитәрлек эшләмибездер! Бу җәһәттән безгә кадәрге буыннар туплаган педагогик тәҗрибәдән шактый киңрәк файдаланырга кирәктер, күрәсең.

Әти-әни, әби-бабайларның роле һәм җаваплылыгы елдан-ел арта. Һәр тәрбиячenең эше иҗади эшкә әверелә бара. Чөнки тәрбияче — һәрчак тикшеренүче, тирән акыллы кеше, тәҗрибәче, хыял чыганагы һәм уйлап чыгаручы ул. Тәрбияче — бүгенге борчулар өчен йөрәге белән әрни торган гражданин ул.

Ата-аналар, балалар укырлык, аларга бер-берсен яхшырак аңларга азык бирерлек, бала тәрбияләүдә ярдәмче булырлык китап язу теләген миндә менә шушы уйлар уятты.

ӘТИ-ӘНИЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР

Әдәплелек — кеше белән аралашу осталыгының аерылгысыз өлеше.

Шуңа күрә дә бу китапның төп максаты — өлкәннәргә һәм балаларга мондый аралашуның катлаулы, тирән эчтәлекле булуын һәм шатлык китерүен ачып бирүдән гыйбарәт.

Әдәпле булу — тирә-юньдәге кешеләргә игътибарлы, инсафлы мөгамәлә дигән сүз ул.

Баланы кечкенәдән үк үз-үзен әдәпле тоту күнекмәләренә гадәтләндерү мөһим. Аны миһербанлы булырга, кылган эшләренең асылына төшенә белергә, «яхшыны яманнан аера белергә» өйрәтергә кирәк.

«Әдәплелек әлифбасы» нәкъ шушы темага багышлана да инде.

Балалар белән һәм алар өчен укылачак бу китап ата-аналарга, балаларга атап чыгарыла. Ә бала вакытта, бигрәк тә кече яшьтә, өлкәннәрнең ачыктан-ачык сөйләнүләре, үгет-нәсыйхәтләре балалар аңында бөтенләй диярлек үзләштерелмәгәнлектән, педагогик киңәшләр китапның күп урыннарында әкият телендә бирелә.

Әкият — әдәбиятның бәләкәйләр яраткан жанры. Әлеге шаян, хыялга бай, уенчак жанрда балага югары әхлакый хакыйкатьне аңлату бигрәк тә җиңел.

Һәр баланың табигатендә өлкәннәр дөньясын аңларга, катлаулы тормышта үз урынын табу өчен күбрәк олылар булып уйнарга, тормышның төрлечә үрелгән вакыйгаларын кабатларга тырышу теләге ята. Бу яктан караганда да әкият — нәниләрнең иң яхшы булышчыларыннан берсе, чөнки әкият әле ул тапкыр «ялган» гына түгел, бәлки уен да. Сез бу китаптан нәкъ менә шушы өзлексез уенны табарсыз. Моңардан тыш, «Әдәплелек әлифбасы»нда балагызга үзегез оештырырлык махсус уеннар да күп. Әлеге уеннар балага әкияттәге хәлләрне, андагы геройларның кыланышларын тирәнрәк һәм яхшырак аңларга, аларның кылган эшләренә бәя бирергә ярдәм итәчәк. Бу уеннарны уйнап бала әдәплелекнең мәҗбүри кагыйдәләрен (китапта бу кагыйдәләрне дә табарсыз) тизрәк үзләштереп кенә калмый, бәлки күбрәк мөстәкыйль эшләргә, уйларга өйрәнә, беренче хезмәт күнекмәләре ала.

Китапта сценарийлары эшкәртелеп бирелгән гаилә бәйрәмнәре бер үк максатка — балаларны тәрбияләү максатына юнәлтелгән.

Үз өендә кунакларны, яшьтәшләрен һәм өлкәннәрне кабул итеп, бала аралашу культурасын, сөйләм культурасын үзләштерә. Ул җәмгыятьтә үз-үзен дөрес тоту күнекмәләре ала. Табын янында дөрес утырырга өйрәнә. Мондый бәйрәмнәргә әзерләнү үзе үк тәрбияви чара булып тора: бала өлкәннәргә өй җыештыруда булыша, әбисе яисә әнисе белән берлектә табын җәя, үзе киенергә һәм пөхтә, матур күренергә тырыша.

Гаилә бәйрәменең һәрберсе әдәплелеккә чираттагы имтихан була.

Баланың акыл үсешен, күңелен, хисләрен тәрбияләү процессы бу китапта даими һәм киеренке хезмәт буларак тик-

шерелә. Ләкин бу хезмәт — бәхетле, иҗади хезмәт. Шуның өчен дә китапның бер өлеше — өлкәннәр белән әңгәмә — күпмедер дәрәҗәдә ата-аналарга үзенең баласы белән мөнәсәбәтенә шушы күзлектән чыгып карарга ярдәм итәчәк.

Китапның кайбер бүлекләре («Өлкәннәр белән сөйләшү», «Өлкәннәргә кайбер искәртмәләр») турыдан-туры ата-аналарга атап язылды. Әкият, уеннар, дәресләр исә — балаларга һәм өлкәннәргә бергәләшеп уку өчен бирелде. Әдәпкә өйрәтү кагыйдәләрен тирәнрәк үзләштерү, әкиятне аңлау өчен, кайбер бүлекләргә карата сораулар тәкъдим ителә. Бу сорауларны кечкенәләргә әти-әниләре түгел, бәлки әкияттәге Саумы фея яисә сезнең өегездә пәйда булган акыллы-зирәк Гномнар бирсә яхшырак булыр. Онытылган кагыйдәне Гномнардан әйттерсәгез яисә искә төшерсәгез дә балага күңеллерәк булачак.

Иптәшләре яисә гаиләдәгеләрнең б
рәрсе катнашында сәхнәләштерелгән уе
нар бала өчен кызык һәм мавыктыргы
Андый уен-спектакльләр, уен-дәресл
өчен махсус костюмнар таләп ителм
Әкият геройларына ясалган маскала
(битлекләр) белән чикләнергә мөмки

«Әдәплелек әлифбасы»н укыганда, б
ла белән берлектә, аерым бүлекләрне
һәр соравына җавап бирергә, әкият
бара торган вакыйгаларны уйдан кичере
тикшерергә тырышыгыз.

«Әдәплелек әлифбасы»нда әкият уе
бәйрәм, әңгәмә бергә бәйләп алып б
рыла. Тәкъдим ителгән һәр очракта се
балагызның үз-үзен тотышын, турыдан
туры реакциясен күзәтә аласыз, ан
характерын өйрәнә, белә һәм, бу белем
нәрне кулланып, аның үсешен идарә ит
аласыз.

Бу эзләнүләрдә сезгә шатлык, уңыш
лар телим.

Авто

ӘКИЯТ-ШӘҺӘР ҺӘМ АНДА ЯШӘҮЧЕЛӘР

Ялан кырлар-аланнар, куе кара урманнар, ерак-ерак юллар үткәч, шикәр тавы артында бар бер шәһәр...

И нәни дустым, синең теләгең — минем боерыгым белән, әгәр дә син күз ачып йомган арада шул шәһәргә очып барып төшсәң икән! Гаҗәпләнүдән бермәл авызыңны ябарга онытып таңга калыр идең!

Ул шәһәрдә өйләр шоколадтан. Түбәләре монпасидан. Тәрәзә капкачлары клиндердән. Прәннек манараларның нәкъ очында калай этәчләр әйләнеп тора.

Әкият-шәһәрнең бөтен могҗизаларын санап китсәңме... исәбе-хисабы юк.

Беренчедән, очы күккә тигән манарада, сөйли торган сәгать астында, тәрәзәсе бизәкле кечерәк бүлмәдә дөньядагы иң тыйлемле фея яши. Ул Тылсым Фәннәре Академиясен шоколад медальгә тәмамлаган. Аның исеме — Саумы фея.

Икенчедән, Әкият-шәһәрдә дөньядагы иң шат күңелле Хат ташучы яши. Үзе мәзәкчән, үзе шыркылдык. Шундый кызыктырып көлә белә, ул шыркылдарга тотынса, янында көлмәгән бер җан иясе калмый! Аны юкка гына шат күңелле Хат ташучы димиләр шул.

Өченчедән, Әкият-шәһәрнең нәни генә бер шоколад өендә акыллы-зирәк Гномнар яши. Бабай Гном. (Ул озын сакаллы, тылсымлы кызыл калфак кигән.) Әти Гном. (Анысының җирән мыегы, тылсымлы калфагы яшел.) Малай Гном. (Бусының почык борыны сипкелле, башындагы тылсымлы зәңгәр калфагының түбәсе чуклы.)

Гномнар баканы томаудан терелтә алалар, чикерткәнең ертылган канатын типчи белә-

ләр... һәм, кирәк икән, Әкият-шәһәрнең бөтен халкын теләсә нинди авырудан сихәтләндерү дә хәлләреннән килә.

Ләкин... Әйтсәм әйтим, Әкият-шәһәрдә халык ныклы режим белән яши. (Һәр иртә алар, әлбәттә, зарядка ясыйлар. Салкын су белән коеналар. Аш алдыннан кулларын юалар. Вакытында саф һавада йөрергә чыгалар, вакытында йокларга яталар.) Шуңа күрә аларның берсе дә авырмый.

Шәһәрдә очар зонтлар Сатучы да бар.

Йөгерек башмаклар тегүче Читекче дә яши.

Сикертмә-кабартма пешерүче Кумәчче дә бар. Ул пешергән кабартмалар авызга сикереп керәм-керәм дип тора.

Әкият-шәһәрнең калган барлык кешеләренең һөнәрен күреп, таңга калырсың, дустым... Әгәр син (үзеңнең теләгең — минем боерыгым белән) бер дә бер көнне күз ачып йомган арада әкияткә юлыксаң, әлбәттә.

Һәм, һичшиксез, бу очракта алар иң башлап шәһәрнең үзәк мәйданы артындагы гаҗәеп фонтанны әйтерләр. Парктан ә-әз генә сулдарак...

Фонтанның алтын-көмеш, зәңгәр суы күккә, алсу-зәңгәр болытларга кадәр җитеп сибелә. Ә кабат җиргә төшкәндә кырыкмаса-кырык тылсымлы
тамчы булып чәчри. Әгәр д
мәгәр кем дә бу гаҗәеп с
белән юынса һәм өч кенә йо
тымын эчеп җибәрсәме... У
чагында аның теләсә нинди из
ге теләге тормышка ашачак.

Бу шәһәрдә көн итү — го
мер кичерү үзе бер рәхәт.

Аның барлык кешеләр
әкияттәгечә әдәпле... Хәтта эт
ләре дә артык гауга күтәре
өрергә оялалар. Ә эт балалары
үткән-барганга күрешү өче
тәпиләрен сузалар.

Чыпчыклары сугышырга
базмыйлар. Чәүкәләр һәм кар
галар чыр-чу килмиләр, үз эш
ләрен шау-шусыз, тыныч кына
хәл итәләр.

Ә прәннек манаралардагы
калай әтәчләр үзләренең яңгы
равыклы тавышлары белән шә
һәр халкын уяталар:

— Кикрикү-ү-ү-к! Торы-
гыз! Хәерле иртә!

Бу — дөньядагы Әкияти шә-
һәрләрнең иң-иң әдәплесе.

Ләкин гел алай булмаган ул...

Без сөйлисе вакыйга күп
тәннән башланган. Ул вакыт
ларда шәһәр Гадәти шәһәр
булган. Анда гади Хат ташу-
чы, гади әдәп-тәртип Сакчысы
очар зонтлар Сатучы түгел
гомумән, гади Сатучы гына
яшәгән... һәм барлык калган
кешеләре дә гади генә булган-
нар. Алар үзләре бик үк тәр-
бияле һәм әдәпле кешеләр бул-
маганнар. Көннәрдән бер көн-

не Алеша Иванов дигән малай фея белән тиктомалдан сүзгә килешкәнгә кадәр, Гадәти шәһәр кешеләре шулай яши биргәннәр...

Бу Алеша дигәнебез әкияттәгечә әдәпсез малай булган.

Дөресен әйткәндә, нәни дус тым, мин синең аз гына д Алешага охшавыңны теләмә идем.

Шуңа күрә, сүземне бүлеп сиңа аңлатып алыйм әле:

ӘДӘПЛЕ БУЛУ НИ ӨЧЕН КИРӘК

Балалар гына түгел, өлкәннәрнең дә күбесе барлык дусларыннан, күршеләреннән, һәм хәтта бөтенләй таныш булмаган кешеләрдән дә игътибар. игелеклелек, ягымлы караш һәм хөрмәт көтә. Беркемнең начар сүз ишетәсе килми.

Ләкин хикмәт шунда, үзе инсафлы, тәрбияле, яхшы кешегә генә кешеләр һәрвакыт яхшылык белән җавап бирәләр. Шундый кешене генә барысы да ярата, хөрмәт итә. Андыйның ышанычлы якын дуслары була, алар белән ул бервакытта да ямансуламый.

Хәер, әдәпле, чын тәрбияле баланың ямансулап торырга вакыты да калмый. Чөнки ул ныклы режим белән яши.

Иртән иртүк зарядка ясый. Юына. Урын-җирен җыештыра. Пөхтә итеп киенә. Аннан әнисенә, әбисенә иртәнге аш әзерләргә һәм табын җыярга булыша.

Тәрбияле бала, әгәр инде ул бакча яки мәктәп баласы булмаса, көндез һичшиксез әбисенә бүлмә җыеш гырышырга булышыр. Гөлләргә с сибәр, песине һәм аквариумдагы балыкларны ашатыр. Андый кеш киемен чистартырга, кибеткә бары ипи-сөт алып кайтырга да иренмәс..

Әдәпле кеше һәрвакыт үзене якыннары, дуслары турында кайгыр тып яши, аларга ярдәм итәргә әзер тора.

Шулай итеп бик дөрес эшли. Әгә чынлап уйласаң, бу дөньяда барлы кешеләр дә бер-берсе белән ярдәм ләшеп, бер-берсе өчен хезмәт ите яшиләр. Шулай булгач, алар хезмәте синең өчен дә ул, дустым.

Төзүчеләр синең өчен йорт төзи

Урам себерүче, сиңа уйнарга, саф һавада йөрергә чиста булсын өчен ишегалдын һәм сезнең уен мәйданчыгыгызны тәртипкә китерә.

Шоферлар сине шәһәр буйлап машинада йөртәләр.

Врачлар авырудан дәвалыйлар. Бакчачылар һәм урманчылар си-нең өчен голбакча үстерәләр, яшь рманнар утырталар.

Ни өчен соң безгә бер-беребезгә арата игътибарлы, итагатьле бул-аска һәм изгелек эшләмәскә? Бу ит бик үк авыр түгел!

Трамвайда урыныңнан торып, олы ешегә урын бирү, очрашканда кеше белән исәнләшү, аерылышканда «ху-ыгыз», «хәерле юл» дип әйтү бер а авыр түгел.

Синең белән аралашу башка ке-еләргә рәхәтлек бирсен өчен, пөх-э итеп киенү, чәчеңне матур итеп арау, чиста итеп юыну шулай ук авыр түгел.

Өйдә өлкәннәргә булышу кыен тү-ел.

Бүлмәдә үз әйберләреңне теләсә кая ташламау, уенчыкларыңны бер урынга җыеп кую да авыр түгел.

Ләкин әдәпле кеше бу кагыйдә-ләрне үтәү белән генә чикләнеп кал-мый. Ул кагыйдәләр бик күп. Әгәр син, дустым, әдәпле кеше белергә ти-ешле мәҗбүри кагыйдәләрнең бары-сын да белеп бетермәсәң, борчылма. Мин сиңа ярдәм итәргә тырышып карармын. Мин генә дә түгел, әкият-нең барлык геройлары да тырышыр.

Ләкин иң элек... Шушы минуттан башлап, үзеңнең әдәпле кеше булыр-га дигән ныклы карарга килүең бик мөһим. Моннан соң, үз тирәңдә бик күп яңа яхшы дуслар булдыру зарур.

Болардан тыш, әниеңнең, әтиең-нең, бабаң, әбиең, күршеләреңнең һәм хәтта сиңа бөтенләй таныш бул-маган кешеләрнең сине хөрмәт итү-ләре кирәк.

Болардан тыш... Сүз бирәм, син чын-чынлап әдәпле, тәрбияле кешегә әверелүгә үк, минем боерыгым — синең теләгең буенча, көннәрдән бер көнне әкият дөньясына барып керер-сең.

ФЕЯНЕҢ КАЙТУЫ

иңа барысы да ачык һәм аңлаешлы булсын өчен, безнең маҗа-алларны, ерактан, Әкият-шәһәр әле Гадәти шәһәр дип аталган аманнардан башлыйк. Ул заманнарда бу шәһәрнең Хат ташу-ысы да, әдәп-тәртип Сакчысы да һәм калган барчасы да гади кешеләр булганнар.

Алар арасында Алеша Иванов дигән малай яшәгән.

Алешаның әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие булган. Алар Алешаны бик нык яратканнар, аны күз өстендәге каш итеп үс-тергәннәр.

Шунлыктан Алеша дигәнебез үзе теләгән вакытта йокла[...]га яткан. Төшкә кадәр йоклаган. Уянгач... Авызын кеше й[...]тардай зур ачып иснәгән. Шунда түтие аның авызына какао ко[...]торган. Ә ике әбисе пирожный каптырган. Алешаның әтис[...] бәпчегенең күңелен күтәрү өчен, сыбызгы сызгыртып торга[...] Әнисе кибеткә, Алешага бүләккә йөгергән.

Бу малайның кеше ышанмаслык күп уенчыклары, альбомн[...]ры, китаплары, буяулары булган! Алеша бу уенчыклардан шу[...] кадәр туйган, ул аларны тәрәзәдән урамга, кешеләр башына то[...]дыра башлаган. Әтисе бу вакытта авыз гармуны уйнатып торга[...] әбиләре барабан сукканнар. Әнисе исә бәпчеген көлдерү өче[...] кулларын чәбәкләгән.

Алеша бернәрсәдән дә кызык тапмаган. Шуңа күрә эче п[...]шудан кызларның чәчләреннән тарткан. Кечкенәләрне кыйнага[...] Кошларга таш аткан. Узган-барганнарны эткән-төрткән. Хәт[...] әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие дә күңелен күтәрә алма[...]ганнар моның. Һәм менә көннәрдән бер көнне, киңәшле эш та[...] калмас дип, Алешаны зоопаркка алып барырга булганнар.

... Беләсез бит инде, зоопарк һәрчак шаулап-гөрләп тор[...] Анда балаларны атландырып тар юллардан карт дөя чаба. Ма[...]мыл үзенең койрыгына кузлекләр тезү белән мәшгуль. Ә таш[...]бака аркасына самовар утыртып куйган да, балаларны һәм өл[...]кәннәрне чәй белән сыйлый.

Зоопаркта тормыш Алеша килгәнгә кадәр әнә шулай кайна[...] торган.

Алеша, зоопаркка килеп керүгә, карт дөягә төкергән. Җирә[...] маймылның койрыгыннан тарткан. Ташбакага ташны шунды[...] итеп ыргыткан, хәтта аның аркасыннан самовар тәгәрәп төш[...]кән.

— Ай-яй! — дигәннәр җанварлар, башларын чайкап.

Зирәк арыслан белән нәрсә турындадыр сөйләшеп торга[...] фея да, әңгәмәсен бүлеп, башын чайкаган.

Ә зирәк арыслан ырылдап ризасызлыгын белдергән.

— Әгәр син һаман да шундый әдәпсез һәм усал булсаң, — дигән фея, — бер заман син кинәт аждаһага әверелерсең.

Шулчак Ивановлар гаиләсе — әнисе, әтисе, ике әбисе һә[...] түтие — фея каршысына чабышып килгәннәр дә әйткәннәр:

— Баланы чыгырыннан чыгармагыз! Әгәр сез чыннан д[...] фея икәнсез, безнең теләгәбез — сезнең боерыгыгыз буенча — аны тәрбияле һәм әдәпле итегез. Әйе-әйе!

Андый могҗизалар гади феянең кодрәтеннән килми, әлбәттә. Шуңа күрә ул, тылсымчылык белемен арттыру теләге белән, кичекмәстән Тылсым Фәннәре Академиясенә укырга китәргә карар кыла.

Зирәк арыслан, шулай ук Гадәти шәһәрнең олысы-кечесе һәм калган барчасы белән саубуллашып фея юлга чыга. Ул йөз ел элек сөекле бабасы бүләк иткән тылсымлы зонтында очып китә. Шикәр тавы өстеннән... Ерак-ерак юллар... Ялан кырлар-аланнар өстеннән оча.

Өч төн һәм өч көн оча ул. Ниһаять, Тылсым Фәннәре Академиясенең нәкъ каршысына барып төшә.

Анда фея өч елда, өч айда, өч көн һәм өч сәгать гыйлем ала. Ул дөньядагы барлык тылсым фәннәрен бик яхшы үзләштерә, шуның өчен аңа зур шоколад медаль тапшыралар.

Медален күкрәгенә тагып, фея почтага бара һәм Гадәти шәһәргә телеграмма җибәрә: «Көтегез. Кайтырга чыгам. Фея».

Гади Хат ташучы бу телеграмманы укыганда олысының-кечесенең шатлыгы эченә сыймый. Чөнки соңгы өч елда, өч айда, өч көн һәм өч сәгать эчендә Гадәти шәһәрдә энә очы кадәрле дә могҗиза булмаган! Ә могҗизасыз тормыш — бик күңелсез тормыш бит ул.

Менә ни өчен шәһәр халкы, берсе дә калмыйча, кайсы тәрәзәдән башын тыгып, кайсысы балконга чыгып, кайберсе янгын каланчасы кыегына менеп... менә-менә фея күренергә тиешле шикәр тавы өстен күзәтә башладылар.

Берәүләре — телескоптан, икенчеләре — күзәтү торбасыннан, кемнәрдер — күзлек киеп микроскоптан карады һәм хәтта болай гына караучылар да булды... Ниһаять, үзенең чуар зонтигында очып кайтучы фея күренде.

Олысы-кечесе, калган барчасы бертавыштан:

— Саумы, фея! — дип феяне сәламләделәр.

Беләсезме, аның Саумы фея дигән исеме дә шуннан калган.

— Сезнең белән кабат очрашуыма мин чиксез шат! — дип сузды фея, шәһәр өстендә әйләнеп. Алай гынамы соң! Инде хәзер сезнең барлык теләкләрегезне үти алуыма мин бик-бик шат! Ни телисез — боерыгыз, мин әзер!

— Телибез! Безнең шәһәрнең Әкият-шәһәр булуын телибез! Өйләре — шоколадтан! Түбәләре — монпасидан! Тәрәзәләре клиндердән булуын телибез! — дип чыр-чу килделәр әлегә кадәр бик үк тәрбияле булмаган малайлар һәм кызлар.

— Ә манаралары — прәннектән! — дип кушылды иң кечкенәсе.

— Рәхим итегез! — диде фея.

Һәм Гадәти шәһәр күз ачып йомганчы Әкият-шәһәргә әверелде!

Малайлар һәм кызлар, куанышып, кулларын чәбәкли-чәбәкли биергә-сикерергә керештеләр. Ләкин рәхмәт әйтү берсенең дә башына килмәде. (Алар бит әлегә бик үк әдәпле түгел иделәр.)

Шуңа күрә эти-әниләре, әби-бабалары һәм түтәйләре оятларыннан керер җир тапмадылар. Һәм бергәләшеп:

— Безнең теләгебез — синең боерыгың белән, фея, балаларыбызны тәрбияле һәм инсафлы ит, — диделәр.

— Рәхим итегез! — диде фея. Һәм Әкият-шәһәрдә ургылып фонтан ата башлады. Үзәк мәйдан артында. Парктан ә-әз генә сулдарак...

Алтын-көмеш зәңгәр суның энҗедәй бихисап тамчылары алсу-зәңгәр болытларга кадәр атылды. Һәм, яңадан җиргә төшеп, кырыкмаса-кырык тылсымлы тамчы булып тирә-юньгә чәчрәде. Олысы-кечесе, калган барчасы — өстенә фонтанның тылсымлы суы чәчрәгән һәркем бер мизгелдә әкияттәгедәй тәрбияле һәм әдәпле кешеләргә әверелде. Алар бер-берсенә ягымлы елмаештылар.

— Сезне күрүебезгә бик шатбыз...

— Рәхим итегез, зинһар...

— Рәхим итеп утырыгыз.

— Түрдән узыгыз!

Саумы фея шатлыгыннан кулларын чәбәкләде.

— Шундый шәһәрдә, сездәй тәрбияле һәм әдәпле балалар һәм зурлар арасында яшәве әкияттәгедәй рәхәт! Бу көн сезнең һәркайсыгыз өчен, кадерле малайлар һәм кызлар, теләкләрегез тормышка ашу көне булсын! Сөйләгез! Тыңлыйм сезне!..

— Рәхмәт...— диделәр әкияттәгедәй әдәпле кызлар һәм малайлар.

— Зинһар өчен,— дип әдәпле генә сорады Кызчык-Бөтерчек,— минем әтием — гади Хат ташучы — дөньядагы иң шат күңелле Хат ташучыга әверелсен.

— Ә безнең әти...— дип ялвардылар Читекченең җиде улы,— йөгерек әкият-башмаклар тексен. Үтенеп сорыйбыз!

— Минем бабакаем авызда эреп китә торган сикертмә-ка-

бартмалар пешерсен, алар кешеләрнең авызына үзләре барып керсеннәр,— дип үтенде иң нәни сабый.— Зинһар өчен!

— Ә безнең әниебез бөтен кешегә очар экият-зонтлар сатсын! — дип оялчан гына әйтеп куйдылар игезәк кызчыклар.— Рәхим итеп, әгәр булдыра алсагыз!

— Әкият-шәһәрдә көн саен кемнең дә булса теләге тормышка ашсын иде,— диештеләр калган балалар.— Үтенеп сорыйбыз!

Чыннан да, шул көн килде бит.

Гафу ит, мин шушында сүземне бүләм, нәни дустым. Ишектә кемдер бар... Бераз гына көт! Мин хәзер, хәзер!..

Фея сорау бирә:

1. Алеша Ивановка карата синең фикерең нинди: син аны ошаттыңмы?

2. Кайсы ягын ошатмадың?

3. Аның нинди әдәпсез кыланышлары бар?

4. Әкият-шәһәрнең башка кешеләре сиңа кайсы яклары белән ошады?

АКЫЛЛЫ-ЗИРӘК ГНОМНАР

Ишекне ачып җибәрүем булды, өч зонт очып килеп тә керде. Бу ни бу?! Күз күрмәгән, колак ишетмәгән могҗиза!

Зонтларның өчесе дә бик җай гына иске креслога килеп кундылар. Һәм шунда ук акыллы-зирәк Гномнар пәйда булды.

Ә-ә-ә... Менә эш нәрсәдә икән!

— Уф!!! — дип куйдылар Гномнар.

Һәм як-якка ялт-йолт каранып алдылар. Кухня өстәлендә банкасы белән кара җиләк вареньесы күрүләре булды, рөхсәт тә сорап тормастан, куллары белән тыгылып, зур кашыкны чиратлашып ялый-ялый, ашый да башладылар.

— Гафу итегез...— дип пышылдадым мин, чөнки гаҗәпләнүдән хәтта тавышым эчкә киткән иде.— Туктагыз әле... Болай ярамый бит! Сез каян килеп чыктыгыз?.. Миңа калса, сез әлегә кадәр тылсымлы әкияттә генә тормыш иткәнсез булса кирәк.

— Әкияттән чынлыкка — бер адым,— дип җавап бирде бабай Гном. (Озын чал сакаллы, тылсымлы кызыл калфак кигәне.)

— Җил арттан иссә, бигрәк тә...— дип мыгырданды авызын тутырып варенье капкан килеш әти Гном. (Җирән мыеклы, тылсымлы яшел калфаклысы.)

Малай Гном, башыннан салган тылсымлы җете зәңгәр калфагы белән вареньега буялган авызын сөртә-сөртә:

— Шуны исбат итәргә кирәк иде дә...— дип хихылдады.

Менә Гномнар минем яраткан аньиулыгыма банкасы белән вареньены түктеләр, ә үзләре өстәлгә суга башладылар.

— Эчәсебез килә! Тизрәк эчәргә бир! — дип кычкырдылар алар.

— Әнә кран...— дидем мин ачулы тавыш белән.— Менә чокырлар. Ә минем сезнең белән утырасым килми — теләмим.

— Ни өчен? — дип гаҗәпкә калдылар акыллы-зирәк Гномнар.

— Әлегә кадәр сезнең кебек әдәпсез Гномнарны күргәнем булмады — менә ни өчен,— дидем мин.

Гномнар акырып елый башладылар.

— Бөтен бәла дә шунда шул! Берничә генә көн элек, без бер чир йоктырдык... Шуннан башлап, бик начар чир — әдәпсезлек чире белән авырый башладык!..

— Ничек булды соң бу? — дип сорадым мин.

Мышнап борын тарта-тарта, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, өстәлдәге савыт-сабаларны шалтыратып, куллларын болгый-болгый Гномнар миңа менә нәрсәләр сөйләделәр:

— Дөньяда булган ди бер шәһәр. Аның кешеләре бик яман чир — әдәпсезлек чире белән сырхаулаганнар.

Очрашканда алар бер-берсенә сәлам дә бирмәгәннәр.

Аерылышканда «хуш», «исән бул» димәгәннәр.

Табын янында аякларын селки һәм ашаганда сөйләшә торган булганнар.

Көчлеләр көчсезләрне кыерсыткан.

Олылар ызгышканнар, бер-берсенә җикеренгәннәр.

Балалар автобус яки трамвайда өлкәннәргә беркайчан да торып урын бирмәгәннәр.

Кыскасы, бу шәһәрнең халкы үзләрен шундый әдәпсез тотканнар ки, менә-менә бер дә бер көнне бөтенесе аждаһага әверелергә тиеш булганнар. Аларның бәхетсезлеккә юлыгулары турында акыллы-зирәк Гномнар ишеткән.

Озакка сузмыйча, Гномнар ашыгыч әкияти командировкага җыенганнар.

Гаҗәеп-фонтаннардан һәм чишмәләрдән тылсымлы алтын-көмеш зәңгәр су тутырып, үзләре белән өч кечкенә чиләк алганнар.

Шуннан соң акыллы-зирәк Гномнар тылсымлы калфакларын алдын артка әйләндереп кигәннәр дә күзгә күренми торганга әверелгәннәр.

Гномнар, зонтларын ачып, тылсымлы су тутырган чиләкләрен эләктергәннәр дә очып та киткәннәр...

Үткән-барганнарга өч зонт һәм өч чиләк күккә ашкан кебек күренгән.

Шуңа күрә әдәпсезлек чиренә тарган шәһәр кешеләре гаҗәпләнүләреннән авызларын ачып күккә те-

кәлгәннәр һәм күзләрен ачкалап-йомгалап күзәтә башлаганнар. Шул чакта күзгә күренмичә очкан Гномнар һәр кешенең авызына өчәр йотым тылсымлы су тамызганнар. Һәркемнең битен юдырганнар. Шәһәр халкы авызын япканда, инде барысы да экияттәгечә әдәпле, тәрбияле кешегә әверелеп өлгергәннәр.

Шул вакыттан башлап, алар, очрашканда, бер-берсе белән исәнләшә торган булып киткәннәр.

Аерылышканда «хуш», «исән бул!» дия башлаганнар.

Табын янында утырганда аякларын селкемәгәннәр, ашаганда беркайчан да сөйләшмәгәннәр.

Көчлеләр биредә көчсезләрне яклаганнар.

Өлкәннәр бер-берсе белән шулай ук балалар белән дә игелекле һәм итагатьле булганнар.

Балалар автобус яки трамвайларда өлкәннәргә торып урын бирергә күнеккәннәр.

Бу экияти командировканың азагы бик-бик яхшы бетәр иде дә, тик акыллы-зирәк Гномнар әлеге коточкыч начар чирне — әдәпсезлек чирен — үзләре йоктырганнар.

И анда ни булганны күрсәң иде! Син аны күз алдыңа да китерә алмыйсың, нәни дустым...

Күренмәс Гномнар рөхсәтсез-нисез кибетчедән утыз морожный алганнар. Авызларын чәпелдәтә-чәпелдәтә ашап бетергәннәр, кәгазьләрен юлга ташлаганнар.

Алар шәһәр бакчасындагы бөтен чәчәкне өзеп бетергәннәр.

Соңыннан тиктомалдан дәү карт карганы үчекли башлаганнар. Теге өч чиләкне аңа ыргытулары булган, чиләктә калган тылсымлы алтын-көмеш зәңгәр су карга өстенә коелган...

— Карр! Карр! — дип каркылд... ган карга һәм шунда ук экиятт... әдәпле кошка әверелгән! — Гномн... бичаракайларым! Сез әдәпсезл... чире белән авырый башладыгы... Карр! Әгәр сез үзегезне һаман шул... тотасыз икән, бервакыт сез ки... аждаһага әвереләчәксез! Карр!

— Нишләдек без! — дип курку... гөшкәннәр Гномнар.— Инде ни к... лырга?

— Кичекмәстән күзегез күр... якка очыгыз,— дип киңәш бирә ала... га әдәпле карга.— Карр! Бәхет у... мындагы илле икенче йортның б... шенче катына кадәр очыгыз! Ан... сезне кабат экияттәгедәй әдәп... Гномнарга әверелдерерләр. Ка... Ашыгыгыз!!!

Менә ни рәвешле килеп кергә... нәр икән минем өйгә Гномнар.

— Сезне кабат экияттәгечә әдә... ле Гномнарга әверелдерү бик ав... эш! — дидем мин көрсенеп.— Мо... эшләү өчен миңа тылсымлы тая... кирәк булачак...

Шалт!.. һәм акыллы-зирәк Гном... нар миңа чын тылсымлы таяк то... тырдылар.

— Рәхмәт...— дидем мин.— Алайса... Мин сезгә ярдәмгә әзе... сезне әдәплелеккә өйрәтү буенча бе... ничә дәрес бирергә ризамын. Л... кин, зинһар өчен, шуны истә тоты... гыз: дәрестә сез экияттәгечә иг... тибарлы һәм экияттәгечә түзем уку... чылар булырга тиешсез.

— Тырышырбыз...— диделәр бе... авыздан Гномнар.

Шунда мин тылсымлы таягымн... селтәдем.

Бер! Ике! Өч!

— Башлыйбыз.

ӘДӘПКӘ ӨЙРӘНҮНЕҢ БЕРЕНЧЕ ДӘРЕСЕ

Кухнида яңадан тәртип урнашты. Бөтен әйбер үз урынында. Кәстрүлләр дә киштәләрдә. Өстәлгә минем яраткан ашъяулыгым җәелгән. Аның аклыгы-пакьлеге бәйрәм төсе биреп тора. Анда чынаяк, чокыр, тәлинкәләр, варенье, печенье һәм конфет вазалары — зурысы, кечкенәсе — тәртип белән тезелгән. Кашыклар, чәнечкеләр табында — һәрберсе үз урынында.

— Шулай итеп,— дидем мин акыллы-зирәк Гномнарга,— без бүген табын янында үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында сөйләшербез.

— Әһе! Сөйләшик! — дип куаныштылар Гномнар, тырмаша-тырмаша, зәңгәр кәнәфидә этешә-төртешә, төмле-татлы ашамлыклар куелган вазага үрелергә тырышып.

Мин яңадан тылсымлы таягымны селтәдем.

Бер! Ике! Өч!

Һәм иске зәңгәр кәнәфи җан-фәрманга ванна бүлмәсенә чыгып чапты.

— Ни дигән сүз инде бу?! — диделәр Гномнар ачу белән.

— Бу — ашар алдыннан һәрвакыт кулны юарга кирәклекне аңлата.

Краннан шаулап салкын су ага башлады... Шунда ук сабын белән мунчала эшкә керештеләр... Акыллы-зирәк Гномнар кулларын юып сөрткәннән соң, мин аларны табын янына чакырдым.

Гномнар тагын өчәүләшеп зәңгәр кәнәфигә тырмашып менәргә тырыштылар.

Тагын тылсымлы таякны селтәргә туры килде.

Бер! Ике! Өч!

Һәм урындыклар, җырлап:

— Тынычлык! Һәркайсыгыз үз урынына утырсын!..— диештеләр.

Гномнар үз урыннарына барып утырдылар һәм оятларыннан аякларын тагын да ныграк селки башладылар.

— Зинһар, табын янында аякларыгызны селкемәгез,— дим мин аларга.— Кашыгыгызны да тәлинкәгә бәрмәгез. Табын янында кабаланмыйча, тавышланмыйча, тыныч утырырга кирәк.

— Әһе... Аңлашыла,— дип минем белән килештеләр акыллы-зирәк Гномнар һәм, тәлинкәләрен күтәреп, ашларын чөмерә башладылар.

Миңа тагын аңлатырга туры килде:

— Ашны — кашык белән, ә икенчегә бирелгән ризыкны чәнечке белән ашыйлар. Әгәр сез ашаганда ялгышлык белән авыз тирәсен яисә кулыгызны буясагыз, тастымалдан файдаланырга кирәклеген онытмагыз.

Шунда мин, отып калсыннар дип, гномнарның каймакка буялган кулларын сөртеп алдым:

— Табын яныннан торып киткәндә, рәхмәт әйтергә онытмагыз.

— Рәхмәт...— дип мыгырданды бабай Гном.— Ләкин бу бик тә авыр фән икән...

— Карр! — дип куйды кинәт кем-

дер кухня тәрәзәсе төбеннән. Бу, әлбәттә, акыл иясе әдәпле карга булып чыкты.— Карр! Әдәплелекнең барлык мәҗбүри кагыйдәләрен өйрәнү, истә калдыру өчен, түземлелек һәм хезмәт кую кирәк. Хәтерләп калыгыз, зинһар! Карр! Карр!

Һәрвакыттагыча, ул хаклы иде, әлбәттә. Шуңа күрә акыллы-зирәк Гномнардан табынны җыештыруда һәм савыт-сабаны юуда миңа ярдәм итүләрен сорадым. Алар моңа би... теләп... риза булдылар.

«ӘДӘПЛЕ КЕШЕ» ДИП КЕМГӘ ӘЙТӘЛӘР?

(әти-әниләр белән сөйләшү)

Әдәплелек — кешенең эчке культурасын билгеләп торган эшләренең суммасы ул. Шул ук вакытта, «культура» төшенчәсе үзе әхлакый-мораль һәм хәтта социаль нормалардан килеп чыга дигән фикерне, мөгаен, беркем дә инкяр итмәс. Шулай итеп, «әдәплелек» төшенчәсе һәр кешенең әхлакый-мораль укымышлылыгыннан, социаль тәрбиялелегеннән килеп чыгучы конкрет кыланышлар суммасы, безнең җәмгыятьтәге тәртибебез комплексы белән билгеләнеп, эчке культурабызның һәм рухи халәтебезнең тышкы гына булса да чагылышына әйләнеп, үзенең тар кебек тоелган кысасыннан үсеп чыга.

Менә ни өчен без балага кечкенәдән үк үзен ничек тотарга һәм ни өчен шулай тотарга икәнлеген аңлатканда, иң башлап улыбызда яки кызыбызда гуманизм, әхлаклылык, рухи хисләрне уятырга һәм үстерергә тырышабыз. Аларны кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә, киң күңелле булырга өндибез.

— Яхшы бул. Кешенең шатлыгын да, кайгысын да күрә бел, чын күңелеңнән уртаклаша һәм изгелек кылып ярдәм итә бел,— дип өйрәтәбез.

— Намуслы бул! Кайчак бу бик үк җиңелдән булмаса да, кешеләрнең күзенә карап дөреслекне әйтүдән курыкма. Битеңә оят китерерлек эшләр кылмаска тырыш. Әгәр инде шундый эшкә барган сың икән, намусыңа тугры калып, гаебең не танырга тәвәккәллек ит, гаебеңне төзәтергә тырыш,— дибез.

— Хезмәт итәргә өйрән. Бөтен уеңны түземлелегеңне, тырышлыгыңны һәм йөрәгеңне биреп эшләгән эш рухи яктан баета, аңыңны ача. Хезмәт кешеләрне үзебез яши торган гаять киң, гүзәл дөньяны аңлый белергә һәм хөрмәт итәргә өйрәтә,— дибез.

— Горур булып, мөстәкыйльлеккә омтылып үс,— дип өйрәтәбез.— Хисләрен якты, теләкләрең изге, йөрәгең кайнар булсын!

Культуралылыкны күрсәтеп торган әдәплелек, тәрбиялелек, һәр тәрбияле кеше өчен мәҗбүри сыйфатлар булса да, бүгенгесе көндә без «әдәпле кеше», «тәрбияле кеше» төшенчәләренең нигезенә үзеңне инсафлы тота белүне генә салмыйбыз...

Инсафлы дип хатын-кызны хурламаган кешегә түгел (моның башкача булуы мөмкин түгел!), бәлки йөгәненнән ычкынган хулиган яныннан ваемсыз узып китмәүче кешегә әйтәләр.

Әдәпле дип беркайчан да агач ботагын сындырмаган, урманнан кочак-кочак

...чәчәкләр күтәреп кайтмаган (ул ... булырга тиеш тә, бүгенгесе көндә ... кыргыйларча тоту безнең өчен ят нәрсә) кешегә түгел, табигатьнең үз натурлыгын сакларга уйламаган эгоистларча туктатучы кешегә әйтәләр.

Хәзерге тәрбияле кеше — ул актив кеше. Ул теге яки бу эшне кылырга гына түгел, бәлки кылган эшенә җавап бирергә дә сәләтле кеше. Җитди һәм ныклы белемле, тирән акыллы кеше.

Әдәпле кеше — ул, табигать биргән темпераменты нинди булуга карамастан, үзенең хисләрен идарә итә алучы кеше... Ул һәрвакыт югары дәрәҗәдә кешелекле кеше. Хәзерге вакытта дөньяда булган барлык бәйләнешләрне һәм мөнәсәбәтләрне туплаган шәхес.

Кешеләргә карата салкын битарафлык, ялагайлануга һәм үз рәхәте өчен генә табан ыларга сәләтлелек, карьеристлык, байлык җыю, бозыклык — безнең культурага ят нәрсә!

Менә ни өчен без бүгенгесе көндә үзебезнең улларыбызда, кызларыбызда гражданлык активлыгы һәм югары әхлакый җаваплылык тәрбияләү теләге белән янабыз. Аларны кешелек дөньясының культура байлыгына, кешеләр арасындагы гаять катлаулы һәм күптөрле мөнәсәбәтләргә тартырга тырышабыз. Без алар алдында хәзерге гыйлем, бүгенге фән дөньясының гаҗәеп якларын ачып бирү белән генә чикләнмибез, бәлки аларның күңелләренә, уйларына изгелек, шәфкать, бөек максатка омтылыш, иҗатка ялкынлы дәрт орлыкларын салырга омтылабыз.

ӨЛКӘННӘРГӘ КАЙБЕР ИСКӘРМӘЛӘР

Кешенең эчке культурасы аның үз-үзен көндәлек тотышында чагылыш таба. Бу турыда онытырга безнең хакыбыз юк. Үзебезнең тәртибебез, кылган эшләребез, бер-беребезгә карата мөнәсәбәтебез теләсә нинди үгет-нәсыйхәтләргә караганда да балаларны көчлерәк тәрбияли.

Шуңа күрә ниндидер сәбәп белән әдәп кагыйдәләренең кайберләрен онытып җибәргән әни, әти, әби, бабайларның исләренә тизрәк шуны төшерим.

1. Зинһар өчен, танышларыгыз белән очрашканда исәнләшергә онытмагыз. Әлбәттә, ир кеше (яисә кем яшьрәк) сәламләү сүзен беренче булып әйтә. Ә хатын-кыз (яисә кем өлкәнрәк) күрешү өчен кулын беренче булып суза. Ир кеше, кемне дә булса еракта ук сәламләгәндә, баш киемен салып кигәндәй итә.

2. Перчатканы салмый күрешү килешми.

3. Кем янына булса да өйгә яки эш урынына кергәч, йортның хуҗасы яисә үз кешеңнең бергә эшли торган иптәшләре белән исәнләшергә кирәк.

Кергәч ирләр (һәм балалар) баш киемнәрен салырга тиеш. (Кибетләрдә салынмый.) Ә кино-театрларда баш киемнәрен хатын-кызлар да сала.

4. Кинода яки театрда үз урыныңа шул рәттә утыручылар алдыннан узып керергә туры килсә, алардан гафу үтенергә кирәк һәм утыручыларга алдың белән үтү мәҗбүри.

5. Әдәпле ир кеше (әгәр ул зәгыйфь яисә бик карт булмаса) транспортта хатын-кызга, бигрәк тә өлкән яшьтәге хатын-кызга, урын тәкъдим итми калмый.

6. Кунакта, җыелышта һәм башка теләсә кайсы урында ир кешегә хатын-кызлар утырып беткән очракта гына килеп утыру гадәткә кергән.

Янында басып торган хатын-кыз белән ир кеше утырган килеш сөйләшсә, монысы бигрәк тә зур әдәпсезлек.

АЛЕШАНЫҢ ӘНИСЕ, ӘТИСЕ, ИКЕ ӘБИСЕ ҺӘМ ТҮТИЕ НИЧЕК ИТЕП ӘКИЯТТӘГЕДӘЙ ӘДӘПЛЕ КЕШЕГӘ ӘВЕРЕЛГӘННӘР

Бөтен шәһәр халкы феянең кайтуын көткән бу иртәдә, Ивано
лар да гаилә ялына җыенганнар. Әнисе, әтисе, ике әбисе, түт
һәм. Алеша моторлы әкияти-машинага утырып, үзләре теләг
якка чыгып киткәннәр.

Алар шикәр тавы артына юл тотканнар... Ерак, бик ер
юллар... Ялан кырлар-аланнар узып... яшеллек дөньясы — кару
манга килгәннәр.

...Карурман уртасында тавык тәпиләрендә кечерәк бер е
утыра икән.

Аның тирә-ягында, узган-барганнарга ягымлы елмаеп, кı
зыл-сары-зәңгәр гөлләр баш иеп кала. Кояшка омтылып зәңг
чирәм үсә. Көмеш куак очларында кызыл тиеннәр, бөтен дөн
яга яңгыратып, чикләвек ватып утыралар.

Черт тә черт!

Өй баскычы төбендә үк бик карт нарат үсеп утыра. Очы кү
кә тигән. Аның ботаклары арасында төннәрен йолдызлар к
чыш-качыш уйныйлар. Иртәләрен болытлар һәм кошлар кунь
ял итәләр. Ә кичләрен аның караңгы куышлыгына оялаган к
лакчын Байгыш күзен елтыратып утыра. Ухх-хохх килеп урма
җан ияләренә әкиятләр сөйли.

Менә нинди гүзәл җиргә килеп чыккан Алеша үзенең әнис
әтисе, ике әбисе, түтие белән.

— Миңа чәчәкләр кирәк! — ди Алеша.

Эһ итәргә өлгергәнче, чәчәкләр ачы күз яше белән еласала
да, түтие кызыл-сары-зәңгәр чәчәкләрне өзә дә башлый... Ә тү
алар телен аңламый шул, бары тик үзүен белә.

— Чикләвек кирәк! — дип акырып җибәрә Алеша.

Тиеннәр бик-бик ачуланып каһәрләсәләр дә, ике әбисе бер
юлы, кызыл тиеннәрне куып, көмеш ботакларны сындыра-сы

дыра шунда ук чикләвек җыярга керешәләр. Әбиләр тиен тел аңламыйлар шул.

— Учак! Учак ягыгыз бу нараттан! — дип кычкыра Алеш

Әнисе кабалана-кабалана әтисенә зур балта тоттыра. Әт се исә, зур-зур селтәнеп, балта белән наратка чабыпмы-чаб

Ыңгыраша-сыкрана карт нарат, калтырап куя.

— Бәла! Бәла! — дип очып чыга посып утырган караңг куышлыгыннан колакчын Байгыш.

— Ярдәм итегез! — дип аңа кушыла тиеннәр.— Талыйла

Бу хәбәр ак каенлыктагы куяннарга барып ирешә. Тыр тырт сикерешеп алар килеп җитә.

Ерак ермактан — төлкеләр!

Чытырманлы чыршы урманыннан — ике соры бүре!

Өненнән чыгып, балалары белән алпан-тилпән Аюниса кил җитә... Ул Саумы феянең күптәнге якын дусты, кешечә би шәп сөйләшә белә икән.

— Оялыгыз, кешеләр! — ди ул, йөнтәс башын чайкап. А ияреп башка киек-җанварлар һәм кошлар да башларын борг лап кычкыра башлыйлар:

— Оят түгелме сезгә?

— Сез нишләп чәчәкләрне өзәсез, харап итәсез? — ди телгә килә куяннар.

— Чикләвек ботагын нигә сындырасыз? — дип ләңгелди төл келәр.

— Ни өчен наратны харап итәсез! — дип улый бүреләр

Ә колакчын Байгышның чынлап торып ачуы чыга:

— Уфф! Табаныгызны ялтыратыгыз! Явызлар! Әдәпсе ләр! — дип кычкыра ул.

Тиеннәр исә, Байгышны хуплап:

— Табаныгызны ялтыратыгыз! Ялтыратыгыз! Ялтырат гыз! — диләр.

Әнисе, әтисе, ике әбисе, түтие һәм Алеша куркышып к лалар. Моторлы әкияти-машина янына чабалар һәм, моторы кабызып, элдертәләр генә урманнан!

Ялан кырлар-аланнар аша... Ерак, бик ерак юллардан. Биек шикәр тавын әйләнеп... Караңгы төндә көч-хәлгә үзләр яши торган шәһәргә кайтып җитәләр.

Акны-караны күрмичә, Ивановлар өйләренә кереп бикләнә ләр һәм, ятуга, тирән йокыга талалар.

Икенче көнне әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие таң белән ук уяналар.

Ниһаять, Алеша Иванов та уянып күзен ачып җибәрә һәм исни башлый.

Түтие ялт кына аның авызына какао коя.

Әбиләре берьюлы берничә пирожный каптыра. Әтисе сыбызгы сызгыртып тора. Алеша барыбер кычкыруын белә:

— Миңа күңелсез!

— Сабыйга нинди дә булса бүләк алмый булмас,— ди әнисе һәм кибеткә чаба.

Тик бусаганы атлап чыгуы була, кинәт туктап, күзләрен челт-челт ачкалап-йомгалап ала. Хәтта гаҗәпләнүдән авызын ачып кала.

Тирә-юньдә шоколад өйләр тезелешеп утыра. Түбәләре монпасидан. Тәрәзәләре клиндердән. Прәннек манараларның нәкъ очында калай әтәчләр утыра.

— Кикрикү-ү-ү-к! — дип кычкыра алар.— Хәерле көн, Иванов әнисе! Ашык тизрәк гаҗәеп фонтан янына! Сине анда Саумы фея көтә.

— Могҗиза!..— ди Алешаның әнисе.

Аяклары үзләреннән-үзләре фонтан янына атлады. Анда эскәмиядә фея утыра иде.

— Исәнмесез,— диде ул Алеша әнисенә һәм бер стакан тылсымлы зәңгәр су сузды.— Өч кенә йотым. Инде хәзер калганы белән юынырга киңәш итәр идем... Рәхим итеп...

— Чынлап та — могҗиза! — ди әнисе. Дөресен әйткәндә, ул үзе тыңлаучан кеше була. Фея әйткәннәрнең барысын да төгәл үти, һәм шунда ук дөньядагы иң инсафлы әнигә әверелә. Оятыннан комач кебек була.

— Ай-яй! Нинди оят! Кичә карурманда мин үземне бик ямьсез тоттым ләбаса!

— Миңа барысы да мәгълүм,— ди фея аңа.— Менә алыгыз әле бу су сиптергечне. Тылсымлы су тутырыгыз да... китегез урманга. Әнә теге чатны борылгач, Сатучыдан зонт сатып алырга онытмагыз. Сез әйләнеп кайтканчы, мин Алешаны фонтан янына китерергә тырышырмын.

— Рәхмәт сезгә! — ди Алешаның әнисе һәм очар зонтлар Сатучы янына йөгерә.

Тиздән ул шәһәр өстендә иде инде... Шикәр тавы өстеннән... Ерак, бик ерак юллар... Ялан кырлар-аланнарны үтеп... яшеллек дөньясына чумган карурманга юл тотты.

Көтеп-көтеп тә әниләре кайтмагач, Ивановлар борчуга ка-
ла. Җитмәсә, малайны елавыннан туктата алмыйлар.

— Бүләкне үземә барып алырга туры килә,— дигән фикерг
килә этиләре һәм ашыгып өйдән чыгып китә.

Бусагадан атлап чыгуы була, күзләрен бер ача, бер йом
һәм авызын ачып катып кала.

Тирә-юньдә түбәләре монпаси шоколад өйләр тезелешеп кит
кән. Манара башларында калай этәчләр кычкыра:

— Кикрикү-ү-ү-ү-к! Сәлам сиңа, Иванов этисе. Ашык! Га
җәеп фонтан янында сине фея көтә!

Һәм этисе озак көттермичә фонтан янына йөгерде.

— Хәерле көн,— диде Саумы фәя һәм Алеша этисенә бер
стакан тылсымлы су бирде.— Үтенәм сездән. Өч кенә йотым
эчегез. Һәм, авырсынмыйча, фонтанның тылсымлы алтын-көмеш
зәңгәр суы белән бит-кулларыгызны да юыгыз.

— Мөмкин,— дип ризалашты этисе.

Фея ни кушса, барын да эшләде һәм дөньядагы иң инсафлы
этиләрнең берсенә әверелде.

— Нинди оят! — дип кычкырып җибәрде ул, шунда ук кыза-
рып.— Кичә урманда бик тупас кыланганмын!

Саумы Фея Алеша этисенә бер капчык орлык һәм көрәк суз-
ды.

— Борчылмагыз,— диде ул,— Алеша фонтан янына үзе
йөгереп килеп җитәр... Ә сез... Сез әнә теге чатны борылгач
та Сатучыдан очар зонт алырга онытмагыз, зинһар.

— Рәхмәт сезгә,— диде түбәнчелек белән Алеша этисе.

Күз ачып йомганчы шәһәр өстендә... Шикәр тавы өстендә...
Ерак, бик ерак юллар өстендә иде инде ул...

Көтеп-көтеп тә этиләре кайтмагач, Ивановлар тагын борчу-
га төште.

— Миңа бүләк кирәк! — дип кычкырды Алеша.

— Хәзер сатып алырбыз,— диде ике әбисе беравыздан.

Ә үзләре бусаганы атлап чыгуга телсез калдылар.

Очы күккә тигән прәннек манара башларында калай этәч-
ләр утыра.

— Кикрикү-ү-ү-к! — дип кычкырды алар.— Сәламлибез сез-
не, Иванов әбиләре! Гаҗәеп фонтан янына ашыгыгыз!

Әбиләр фонтан янында өчәр йотым тылсымлы су эчтеләр,
бит-кулларын юдылар, һәм дөньядагы иң инсафлы әбиләрг
әверелделәр.

— Ай-һай! — диделәр алар, башларын чайкап.— Кичә ниләр кыланганбыз бит! Искә төшерүе оят!

Фея аларга өлгергән чикләвекләр белән тулы кәрзин бирде, очар зонтлар сатыла торган урынны күрсәтте.

Тиздән Ивановның ике әбисе дә шәһәр өстендә... Шикәр таны өстендә бөтерелеп... Карурман ягына юл тоттылар.

Иң соңгы кеше булып фея янына сулуы капкан түти килеп җитте. Тиздән ул да әкияттәгедәй инсафлы түтигә әверелде. Үзенә очар зонт сатып алып, Әкият-шәһәр өстеннән очып үтте... Карурманга таба юл тотты.

Урманда, тавык тәпиләрендәге кечкенә өй каршында Иванов әнисе тылсымлы тере суны куакларга, гөлләргә һәм үләннәргә сибеп йөри. Ике әбисе кызыл тиеннәргә тук чикләвекләр ашата. Әтисе аланлыкта искиткеч матур агач һәм чәчәк орлыклары чәчеп йөри. Ә түтие фея биргән шифалы май белән карт наратның яраларын дәвалый.

Артык зарыктырмыйча, урман аланлыгында кызыл-сары зәңгәр чәчәкләр ягымлы елмайдылар. Зәңгәр чирәм кояшка тартылды. Ботакларда тиеннәр сикерә-бии башладылар. Ә караңгы агач куышлыгыннан колакчын Байгыш карады.

— Уфф! — дип аваз салды ул.— Барыгыз да җыйналыгыз!

Ап-ак каенлыктан куяннар йөгерешеп кайтты.

Ерак ермактан — төлкеләр.

Чытырманлы чыршылыктан — ике соры бүре.

Өненнән чыгып, балалары белән алпан-тилпән Аюниса килеп җитте.

— Рәхмәтебез чиксез зур сезгә, кешеләр! — диде Аюниса, түбәнчелек белән башын иеп.

Калган киек-җанварлар һәм кошлар да Ивановларга рәхмәтләрен белдерделәр.

— Рәхмәт! — дип куяннар кычкырды, төлкеләр ләңгелдәде, бүреләр улады, тиеннәр телләрен шартлаттылар.

Карт нарат исә Алешаның әнисенең кулларына кечкенә генә энҗе йолдыз төшерде.

Бу хәлләрдән соң Алешаның әнисенә, әтисенә, ике әбисе һәм түтиенә шундый рәхәт булып китте, өйләренә кайтканда котта җырлап ук җибәрделәр. Шул җыр белән Әкият-шәһәр өстенә килеп җиттеләр.

Ниһаять, җирдә төрле төстәге монпаси түбәләр ялтырап күренде.

Алешаның әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие, гаҗәеп фонт
янына килеп төшүгә, фонтан янындагы эскәмиядә Саумы фе
нең хәсрәтләнеп күз яше түгеп утыруын күрделәр.

Ә фонтанның алтын-көмеш зәңгәр тамчылары астында, лы
ма су булып, чәчләре тузгыган Алеша Иванов басып тора и

— Дөньяда иң-иң-иң әдәпсез малай буласым килә! — д
акыра Алеша.

— Бәхетсезлеккә каршы, ул биредә шактыйдан басып то
инде...— дип көрсенде фея.— Иң дә аянычы... Аның тел
үтәлде. Феянең шулай дип әйтүе булды, Алешаның әни-əти
ике әбисе һәм түтие беравыздан кычкырып елый башлады

Фея сорау бирә:

1. Алешаның әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие карурман башта үзләрен ничек тотканнар: әдәплеме, әллә әдәпсезме?

2. Урманда син үзеңне ничек тотасың?

3. Алеша ни өчен үзсүзләнә?

4. Үзсүзләнү, киреләнү әдәплелеккә кирәме? Син нич уйлыйсың?

5. Әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие әдәпле-инсафлы кеш ләргә әверелгәч, урманда үзләрен дөрес тотканнармы?

ӘТИ-ӘНИЕҢӘ ҺӘМ ГАИЛӘГЕЗДӘГЕ БАШКА КЕШЕЛӘРГ КАРАТА МӨНӘСӘБӘТЕҢ ТУРЫНДА

Әгәр бала Алеша кебек тәрбиясез һәм усал булса, тел белән сөйләп, каләм белән язып бетерә торган түгел.

Син андый түгелсеңдер бит, нәни дустым?

Иң турылыклы, иң ышанычл дусларың әниең белән әтиең, әби белән бабаң, гаиләгездәге башка к шеләр икәнен син беләсең инде, ә бәттә! Алар һәрвакыт янында — бә рәмнәрдә дә, иң авыр минутларың да.

Алар арыган, хәтта авырган вакытларында да сине ашата-эчертә, җырларыңны тыңлый, иркәлиләр. Сиңа [illegible] киңәш бирәләр.

Шулай түгелмени?

Үзеңнең авырып, урын өстендә ятканыңны [illegible] иткән вакытыңны хәтерлисең әле, бу көннәрдә әниең, әбиең сиңа карата нинди игътибарлы, кайгыртучан булалар. Сиңа дару бирәләр. Горчичник, градусник куялар. Көйсезләнгән чагыңда колагыңа иркәләү-назлау сүзләре пышылдыйлар, бу сүзләр авыртуны оныттыра, савыктыра.

Ә бәйрәмдә?.. Әйтик, Яңа елда... Әтиең-әниең синең катнашыңда өйне бизәп, чыршыны матур итеп киендерә. Әбиең бәлеш пешерә. Бу көннәрдә күңелле мәшәкатьләрдән һәм якыннарыңның яратуыннан өйгә шундый җылылык иңә, хәтта бу җылыга Кыш бабай белән аның оныгы Кар кызы да килми калмый!

Өегездәге һәм үзеңдәге һәрбер нәрсә — барлык әйберләр, китаплар, уенчыклар әти-әниең, якыннарың кулы белән булдырылган яки алар эшләгән акчага сатып алынган. Әниең, әтиең, әбиең, бабаең бөтен гомерләре буена хезмәттән туймыйлар бит.

Әбиең яки бабаеңның сөялле кулларына игътибар белән кара әле, дустым. Үз гомерендә күпме эш эшләгән бу куллар!.. Алар, мөгаен, йортлар төзегәннәрдер? Бәлки, диңгездә кораб йөрткәннәрдер? Яки күктә самолетны идарә иткәннәрдер?.. Бәлки әле, синең әбиең һәм бабаең мәктәптә балалар укытканнардыр? Кешеләрне дәвалаганнардыр? Яисә икмәк, бакча үстергәннәрдер?

Син алардан ничек тә булса үзләре турында сөйләүләрен йомшак кына сора әле. Аларны тыңлап, үзегезнең гаиләдә искиткеч кешеләр яшәвен тагын да яхшырак аңлый төшәрсең.

Кайбер малайлар һәм кызлар үзләренең әти-әниләрен бик үк белеп бетермиләр, алар турында бик үк еш уйланмыйлар. Ә чынында бит...

Менә әниеңне алыйк... Көне буе күпме эш эшләргә өлгерә ул! Иртәнге ашны әзерли. Табынны җыештыра. Син сабыйны — балалар бакчасына, ә абыеңны яки апаңны мәктәпкә озата. Әллә ничә сәгать эшләп кайта. Ләкин әле кибеткә барып кайтырга һәм кичке аш пешерергә, өйне тәртипкә китерергә, синең белән утырып китап укырга һәм уйнарга, сине юындырып йокларга яткырырга да өлгерә. Шулардан соң кер уып, типчеп, бәйләп һәм азрак телевизор да карап ала. Әкияттәге бер тылсым иясе дә өлгерә алмый бер көн эчендә шулкадәр эш эшләргә! Тылсым иясенең тылсымлы таягы була торып та... Ә әниеңнең андый таягы юк шул.

Хәер... Әтиең (яки гаиләдәге башка кешеләр) булышмаса, бу эшләрнең барысын да башкарып чыгу әниеңнең берүзенә авырга туры килер иде.

Синең әтиең дә әкияттәгедәй диярлек яхшы күңелле, әкияттәгедәй диярлек акыллы, әкияттәгедәй диярлек белемле кеше. Дөньядагы бар нәрсә турында да белә ул. Үзе эшли торган завод, хоккей, йолдызлар, бик салкында чаңгыларны нинди май белән майларга кирәклеге, төрле илләр, сезнең төбәк аша ага торган елгада нинди балыклар үрчүе, танылган шахматчылар һәм кайчак хәтта йомырка тәбәсенең ничек кыздырылуы турында да белә.

Менә нинди гаҗәеп кешеләр яши сезнең гаиләдә, нәни дустым. Алар барысы да синең иң турылыклы һәм иң ышанычлы дусларың.

Ә дуслыкны сакларга, дуслар турында кайгыртырга, һәр очракта да аларга ярдәм итәргә тырышырга кирәк.

Шуңа күрә, зинһар дип әйтәм, ашаганнан соң савытыңны үзең юарга тырыш. **Бу эшне әбиеңә, әниеңә калдырма.**

Әбиең, бабаең, әниең кайтып чишенгәндә, аларга булыш, башмакларын китереп бир.

Ә инде сиңа әти-әниең (яки әбиең һәм бабаең) белән берәр җиргә автобуста, трамвайда барырга туры килсә, иң беренче үзең утырырга ашыкма. Буш урынга башта сөекле өлкән дусларың утырганны көт. Бигрәк тә хатын-кызларның утырганын. Аларга бит ял болай да аз эләгә.

Сөйләшкәндә өлкәннәрне бүлдермә. Алар белән, зинһар, тупас сөйләшмә...

Өеңнең кайгыртучан хуҗасы булырга тырыш. Яхшы хуҗа һәрвакыт җыйнак-пөхтә була. Ул үз әйберлә... нең, уенчык һәм китапларының у... нын яхшы белә. Өен һәр көн тәрт... кә китерә: идән себерә, тузан... сөртә. (Чиста, пөхтә өйдә яшәү к... кенәләргә дә, өлкәннәргә дә рәхә...

Әгәр якыннарыңнан берәрсе а... рып китсә яки эшләп утырса, тавы... ланма. Энең яки сеңлең булса, ал... белән кычкырышырга-сугышырга т... рышма.

Үзеңнең якыннарың, тирә-юн... дәгеләр белән, зинһар, ягымлы һ... яхшы мөнәсәбәттә бул.

Син шундый булып үссәң, әние... әтиеңә, әбиеңә яки гаиләдәге баш... кешегә беркайчан күңелсезлек я... массың, һәм безнең әкияттәге А... шага да охшамассың.

ӘБИЕМ БӘЙРӘМЕ

Бәйрәм һәркемгә дә күңелле.

Әбиең үз гомерендә барчагызга караганда да күбрәк хезмәт иткән — көч түккән.

Ул синең әниеңне яки әтиеңне үстергән. Әбиең сине дөньядагы бар нәрсәдән кадерлерәк күрә.

Әлбәттә, син аны үзең дә бик-бик яратасың.

Әбиеңнең бәйрәмен уздырырга күптән хыялланып йөрисеңдер әле, мөгаен.

Ләкин, акыллым, бөтен бәйрәм мәшәкатьләрен өлкәннәр җилкәсенә (бигрәк тә әбиеңә!) аударма. Бәйр... күңелле, чын бәйрәм булсын өче... аны бөтенесе әзерләргә тиеш. һ... иң элек син үзең. Моның өчен ме... нәрсәләр эшләргә тиешсең.

1. Өлкәннәргә өйне җыештыру... булыш. Бүлмәләрне чистарт. Дым... чүпрәк белән тузаннарны сөрт.

2. Әниеңә табын җәяргә булы... Тәлинкәләрне, чәнечке, кашык һ... кирәкле башка әйберләрне дөрес у... наштыр.

3. Әниеңә салат ясарга булы... Бәлки, әниең сиңа сөткә манчып и...

лар телемнәре кыздырырга яки бәлеше әрчергә рөхсәт итәр. Бусы инде тагын да кызык.

4. Аннан әбиеңне әдәпле генә табын янына чакыр.

5. Син барлык кунакларны әдәпле каршы алырга, чишенгәндә ярдәм күрсәтергә һәм табын янына чакырырга тиеш.

6. Әбиеңә үзең ясаган нинди дә булса берәр бүләк тапшыр. Бу — кәгазьдән кисеп ясалган чәчәкләр, берәр җанвар сыны яки энәләр өчен мендәр булырга мөмкин.

7. Табын яныннан барысы да кузгалгач, савыт-саба юарга һәм аны урынына куярга булышырга онытма.

Нәрсә бу?.. Кемдер елый һәм күрсенә түгелме?.. Акыллы-зирәк Гномнар икән ләбаса! Ни булды!

— Нинди аяныч! — дип көрсенделәр **акыллы-зирәк Гномнар.— Безнең әбиебез юк! Һәм шуңа күрә беркайчан да!... Беркайчан да әбиләр бәйрәмен үткәрә алмыйбыз.**

— Еламагыз! — дидем мин.— Күңелле, матур бәйрәмне дуслар өчен дә ясарга була. Дусларыгыз бардыр ич сезнең?

— Әлбәттә! — дип куаныштылар Гномнар.

— Бик шәп,— дидем мин.— Әйдәгез, алар бәйрәмендә без дә катнашыйк...

ӘДӘПКӘ ӨЙРӘНҮНЕҢ ИКЕНЧЕ ДӘРЕСЕ

— Кызганыч, безнең чын мәктәпләрдәге шикелле, яңгыравык кыңгыравыбыз юк...

— Ничек инде ул юк? — дип мыгырданды бабай Гном, һәм үзенең кесәсеннән зур, бик зур зәп-зәңгәр кыңгырау чәчәк чыгарды.

Шунда ук бик еракка, күз күрмәгән — колак ишетмәгән патшалыкларга ишеттерерлек итеп кыңгырау тавышы яңгырады.

... Көтмәгәндә-уйламаганда тәрәзәләрдән, ишекләрдән әкияттәге аллы-гөлле бәхет кошлары очып керде, әкияттәге могҗизалы җанварлар чабышып керделәр!..

Принцессалар. Принцлар! Орчык кадәр малай! Һәм дә Уймаккыз!

— Исәнмесез! — дип сайраштылар аллы-гөлле бәхет кошлары.

— Хәерле көн! — дип әдәпле генә исәнләштеләр җанварлар.

— Без сезне күрүебезгә бик шат,— дип күмәк сәлам бирделәр принцесса, принцлар һәм Гномнарның башка дуслары.

— **Мин дә сезнең килүегезгә бик-бик шат,— дип җавап бирдем мин.**

— **Шулай да... Кемнең дә булса ишегенә ачып кергәнче, башта шакылдатырга** яки звонокка басарга, ә аннан соң — кергәч, хуҗаларга сәлам

бирергә кирәк,— дип сузып җибәрделәр кинәт ишек-тәрәзәләр телгә килеп.

— Ай! Гафу итегез! — диде Уймаккыз.

— Рәхим итегез. Түрдән узыгыз,— дип өйгә чакырдым мин Гномнарның дусларын.— Ләкин... Кемнең дә булса өенә кергәндә, баш киемен салырга кирәклеген барыгызның да исенә төшерергә рөхсәт итегез. Хәтта күренмәс бүрек булса да.

Шунда принцлар, принцессалар, хәтта могҗизалы җанварлар — барысы да тиз генә баш киемнәрен салдылар һәм ишек төбендәге келәмгә аякларын, тәпиләрен сөртергә ашыктылар.

— Булдыклылар! — дип мактадым мин барысын да.— Тик ишек төбенә бөтенегез берьюлы өелешмәгез. Принцлар алдан принцессаларны һәм өлкәннәрне уздырырга тиеш... Мәсәлән, менә бу чал Өлкән Аждаһаны.

Барысы да уздылар. Аллы-гөлле бәхет кошлары бер рәт булып тәрәзә төбенә утырыштылар һәм сайрарга керештеләр. Могҗиза-җанварлар карават астына кереп ырылдаша башладылар. Принцессалар шунда ук бөтерелеп биеп киттеләр. Ә принцлар арасында нәрсәдәндер кинәт кенә бәхәс чыкты.

Кыскасы, шундый шау-шу купты, хәтта Гномнар да кычкыра башладылар.

— Без чукракландык, ахрысы!

— Гомумән,— дидем мин,— кунакта тавышланырга һәм барын берьюлы сөйләшергә, бигрәк тә ызгышырга-сугышырга ярамый. Җиһазларны вату-җимерү дә начарлык. Әйдәгез, иң яхшысы, бергәләшеп нәрсә булса да уйныйк.

— Уйнарга! Уйнарга! — дип сайрадылар, ырылдадылар, кычкырдылар акыллы-зирәк Гномнарның дуслары.

— Тик, зинһар, уйнаганда ызгышмагыз, бер-берегезгә карата тупас мөгамәләдә булмагыз, рәнҗетүле сүзләр әйтешмәгез.

— Рәхмәт... Без аңладык,— диделәр кунаклар, түземсезләнеп аякларын тыпырдата-тыпырдата.— Ә нәрсә уйныйбыз?

ДУСЛАР БЕЛӘН НИЧЕК ҺӘМ НӘРСӘ УЙНАРГА?

1. Әдәпле качыш-качыш уены. Башка кач-кач уеннарындагы шикелле үк, уйнаучылар, башта үз араларында санамыш үткәреп, эзләүчене билгелиләр.

Эзләүче күзен йомып унга кадәр саный. Уйнаучыларның башкалары кача. Ләкин бик еракка түгел. Табышлары эзләүчегә ишетелерлек урынга качалар.

Эзләүче барысына да ишетелерлек итеп: «Ун!» — дип кычкыруга, качкан уйнаучылар, җавап итеп, әдәпле кеше телендәге нинди дә булса сүзне әйтәләр. Кем нинди сүзне тели:

— Саумы!
— Хәерле кич!
— Сау-сәламәт бул!
— Рәхмәт...

Эзләүче, тавышка карап, кемнең кайда качканын әйтә. Әгәр беренче кычкыруда ук тавыштан таный алмаса, ул «Уи!» — дип, тагын ике тапкыр кычкыра ала.

Әгәр эзләүче, кемне дә булса әйтә алмаса, уенда эзләүче кеше булып икенче тапкыр кала. Әгәр барысын да әйтеп чыкса, исеме беренче әйтелгән кеше эзләүче була.

2. Әдәпле күз бәйләш уены. Санамыш үткәреп эзләүчене билгелиләр. Аның күзен бәйлиләр, һәм ул кечерәк бүлмәдә үз тирәсендә йөгерешеп уйнап йөрүчеләрне тотарга тырыша. Тоткан кешесен үзенең ярдәмчесе итә. Шулай ук аның да күзен бәйлиләр.

Хәзер инде эзләүчеләр икәү булды. Өченче кеше итеп кемне тоталар, аны да ярдәмче итәләр. Барлык уйнаучыларны тотып бетергәнче, уен шулай дәвам итә.

Иң соңыннан тотылган кеше икенче уенга эзләүче булып кала.

Дуслар белән бергә рәсем ясарга, рәсемнәр кисеп ябыштырырга, **яисә пластилиннан уенчыклар әвәләп ясарга мөмкин. Бу да бик кызыклы.** Мин сиңа, нәни дустым, берничә кызыклы уенчык ясарга киңәш итәр идем. Тырышып эшләсәң, алар әбиеңә, әниеңә яки сеңлеңә бүләккә дә ярап куяр.

НӘРСӘДӘН БАШЛАРГА?

(әти-әниләр белән сөйләшү)

«Туган көннән башлап биш яшькә кадәр — иң җаваплы чор». Лев Николаевич Толстойның бу сүзләре белән килешмичә мөмкин түгел.

Бала без яши торган катлаулы дөньяга — мәшәкатьләр, теләкләр белән тулы, һәм Җирдә ун меңнәрчә еллардан бирле тупланып килгән чиктән тыш күп шатлык-шомнары белән тулы дөньяга — әйтерсең лә икенче планетадан килеп төшә.

Биш еллык «арада» бала гомерендә беренче күргән төсләр чуарлыгыннан, аерым төсмерләр балкышыннан сызыкларның юнәлешен һәм ачыклыгын, предметларны эченә алган күләмнәрнең өч үлчәнешлелеген аңлап алырга тиеш. Алай гына да түгел, бу вакыт эчендә бала гаять күпсанлы предметларның нәрсәгә хезмәт итүен аңлап истә калдыра һәм аларның кайберләреннән файдалана белергә өйрәнә.

Төрле яктан килгән авазлардан ана телендәге сүз булып яңгыраганнарын аерып ишетү өчен, биш ел эчендә бала ачык-төгәл ишетү сәләтенә ия булырга, аерым сүзләрнең мәгънәсен аңларга, сөйләм теленең четереклелегенә төшенергә тиеш.

Беренче биш ел дәвамында бала үз хәрәкәтләрен идарә итәргә өйрәнә. Тәүге адымнарын атлаганнан соң, ул сабыйлык чорының үсеш баскычлары буйлап «алга һәм югарыга» омтыла. Җәмгыятьнең барлык кешеләре өчен үтәлүе мәҗбүри бул-

ган кагыйдәләрне үзләштереп, дөньяны өйрәнә, танып белә. Сынап-уйнап, дөньяда үз урынын эзли.

Бу елларны гади нарасыйлык еллары дип кем әйтә ала? Кайбер өлкәннәр уйлаганча, нәниләр бу елларны уен белән мавыгып кына үткәрмиләр! Бу гадәттән тыш мөһим «чор» баланың бөтен организмында, бөтен психикасында чагыла торган киеренкелек һәм катлаулылыклар белән шыгрым тулы.

Шуңа күрә без, өлкәннәр, бу чорда (хәер, һәрвакытта да) балаларыбызның киң күңелле, нәзакәтле һәм акыллы ярдәмчеләре булырга тиешбез. (Күрәсең, бала тәрбияләүне нәкъ менә шушы максатны аңыбызга сеңдерүдән башларга кирәктер...)

3 яшьтән 7 яшькә кадәрге чорны психологлар һәм педагоглар уен яше дип атаганнар.

Сабый тирә-юнендәге үзе күреп күзәткән бар нәрсәне уен итеп кабатлап, олылар дөньясын танып өйрәнә һәм аңа кушылып китә. Аңарда инде азмы-күпме тормыш тәҗрибәсе туплана. Баланың хәтере искиткеч яхшы. Ул бик игътибарлы, кызыксынучан — дөньяга тикшеренүче, күзәтүче, беренче ачыш ясаучылар күзе белән карый.

Дөрес, бала әле үз-үзен мөстәкыйль тоту дәрәҗәсенә ирешмәде, аның үзе омтылган кешеләргә һәм вакыйгаларга карата үз фикере дә юк. Ул чагыштырып карарга, бәя бирергә дә өйрәнеп җитә алмады. Аның каравы, талантлы актер сыман, ул үз тирәсендәге олы кешеләрнең барлык кылган эшләрен, сүз-кыланышларын кабатлый ала (һәм кабатлый да!). Ата-аналарга бу турыда беркайчан да онытырга ярамый.

Бу яшендә без бала белән мөмкин кадәр күбрәк һәм ешрак уйнарга, үзебезгә яхшы таныш уеннарны өйрәтергә, алар белән гади генә булса да яңа уеннар уйлап табарга тиешбез.

Баланы үз-үзен тоту культурасына уен белән күнектерү; аны кешеләр белән аралашырга өйрәтү; һәм, ниһаять, уйнаганда, баланы дисциплинага, тәртипкә һәм хезмәткә күнектерү зарури.

Баланы мәктәпкә әзерләү дә — безнең бурыч. (Бусы да уен белән!) Чөнки балалык чорының уен этабын уку этабы алмаштыра.

Асылда балада кызыксынучанлык, белемгә омтылышы шактый иртә уяна. Безнең балаларыбыз 3—5 яшьтән үк «сораулар белән йөдәтергә» бик һәвәсләр. Бала белән дөрес шөгыльләнгән тәкъдирдә, аңа 7 яшь тулганда, ул «очраклы сораулар» бирергә генә түгел, бәлки даими үткәрелә торган дәресләргә дә әзер була.

Безнең улларыбыз һәм кызларыбызда белемгә сусау табигатьтән килә. Өлкәннәрнең педагоглык бурычы — алар җилкәсенә төшкән катлаулы (!) бурыч — әлеге искиткеч сәләтне үстерү мөмкинлеген ычкындырмау; бертуктаусыз демагогик үгет-нәсыйхәт тукып тору, катгый кистереп әйтүләр белән бу сәләтне юкка чыгармаудан гыйбарәт.

Шуңа күрә, балаларда культуралы тоту күнекмәләре тәрбияләгәндә, аларны инсафлы, миһербанлы, нәзакәтле булырга өйрәткәндә, без, өлкәннәр, бала үсешендәге психологик үзенчәлекләрне күздә тотып эш итәргә тиешбез.

Мәктәпкәчә яшьтәге баланың психикасына күндәмлек, йомшаклык хас. Бу елларда бала — охшатып кабатлауларга, хисләнеп кеше хәленә керүгә һәвәс була. Ә үзе, әлбәттә, нәрсәгә ияреүгә кирәклеген һәрвакыт аңлап та бетерми. Нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтә баланың аңында, йөрәгендә рух тойгылары бөреләнә. Шушы чорда ата-аналар үзләренең балаларын башкаларга карата миһербанлы һәм итагатьле итеп тәрбияләргә бурычлылар.

Өлкәннәр бу сыйфатларны балаларда үз үрнәкләрендә һәм, һәр кылган уңай эше өчен, сабыйга дусларча мактау-хуплау сүзләре әйтеп тәрбиялиләр. Шул ук вакытта баласының дорфалыгы, ялкаулыгы, комсызлыгы, гаделсезлеге яки ялган сүзе ата-анада үзеннән-үзе чиктән тыш зур ризасызлык уятырга тиеш.

Нәниләргә карата таләпчәнлекне киметмичә, назга саранланмаска кирәк. Әгәр өлкәннәр балага дусларча ягымлы мөнәсәбәттә булсалар һәм аның мөмкинлекләренә, көченә ышаныч белдерсәләр — балада уңай тойгы барлыкка килә. Ул чакта безнең таләпчәнлегебез һәм житди-

[illegible] аны чыгырыннан чыгармый, бары тик тиешле тәртипкә генә өйрәтә.

Психик һәм физик яктан һәр баланың үзенең үсеш үзенчәлекләре бар.

Шуңа да карамастан, безнең һәркайсыбыз — ата-аналар һәм тәрбиячеләр өчен — мәҗбүрилеге бәхәссез булган изге кануннар яши.

Кеше күңелен, характерын иҗат итүче кеше иң элек, һичшиксез, үзен-үзе иҗат итәргә тиеш.

Чын кешелекле кеше генә кешелекле кешене тәрбияли ала.

Үзе актив кеше генә актив шәхесне тәрбияли ала.

Үзе намуслы кеше генә намуслы кешене тәрбияли ала.

Һәм, ниһаять, югары культурага ия булган кеше генә чын культуралы кешене тәрбияли ала.

Үз баласын яраткан, аның эчке дөньясын, тойгыларын тәрбияләргә теләгән ата-ана китапларга, сынлы сәнгатькә, театр, музыка, радио һәм газеталарга мөрәҗәгать итәргә тиеш. Алар иң элек үзләре укырга — күргәннәрен яки укыганнарын уйдан кичерергә, фикер йөртергә тиешләр. Ата-аналарның һәркайсы сәнгать ярдәмендә һәм табигать белән аралашып үз зәвыгын үстерергә бурычлы. Алар һәр җанлы нәрсәгә, иң беренче чиратта кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә булып, үзләренең хис-тойгыларын баетырга тырышалар. ... Баланың инсафлылыгы үзен дөрес тота, әдәп-тәртип кагыйдәләрен үти белүендә, аның тышкы кыяфәтендә, сөйләшүендә, әйберләргә мөнәсәбәтендә, тирә-юнендәгеләр белән аралашу рәвешендә чагыла. Шулай итеп, балага бу кагыйдәләрне үзләштерергә һәм аларны үти белергә кирәк.

Педагоглар һәм психологлар фикеренчә, мәктәпкәчә яшьтәге бала түбәндәге күнекмәләрне үзләштерергә тиеш. Болар:

баланың шәхси пөхтәлегенә;

табын янында үз-үзен дөрес тотуына, ашау-эчү приборларыннан файдалана белүенә;

өйдә һәм җәмәгать урыннарында — өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу культурасына;

уйнау культурасына, хезмәт бурычларын үтәвенә бәйле күнекмәләр.

Бик кечкенәдән режимга күнектерү гигиена һәм тәртип белән эш итү күнекмәләрен ныгытырга, мөстәкыйльлеккә өйрәтергә мөмкинлек бирә.

Балага әдәп-тәртип күнекмәләре ничек бирелә соң? Әлбәттә, бу иң беренче чиратта ата-ананың үз мисалында алып барыла, аннан соң ачык аңлатып күрсәтеп бирү һәм күнегүләр ясауга күчәргә мөмкин.

Даими, планлы эш (искә төшкәндә генә түгел), һичшиксез, уңай нәтиҗәгә китерә.

Боларга баланы кайчан күнектерә башларга соң? Бик кечкенәдән. Әдәп кагыйдәләрен бала никадәр иртәрәк үзләштерсә, аларны үтәве дә шулкадәр табигыйрәк булачак.

Бу җәһәттән педагоглар һәм балалар психологиясен өйрәнүче белгечләр гаиләдә бала тәрбияләүне әдәплелек, киң күңелләлек, түземлелек, бер-береңнең хәленә керүчәнлек һәм ягымлылык «атмосферасы»н булдырудан башларга кирәклеген һаман әйтә киләләр.

Баланың хыялын, иҗатын һәм җанлы күзәтүчәнлеген үстерү өчен, алда әйтелгәннәргә өстәп — әлеге дә баягы үз балабызның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып — бала тәрбияләүне, бәлки уенга корып, һәрбер өйдә урын алырга тиешле кызыклы әкияттән башларга кирәктер. Нәни кеше шәхесен һәрьяклап иҗат итү кебек авыр эштә, һәрхәлдә, аның башлангыч чорында, безнең иң турылыклы, ышанычлы ярдәмчебез фәкать уен һәм әкият кенә була ала.

«Әдәплелек әлифбасы» һәм аның геройлары күпмедер дәрәҗәдә мондый тәрбияви уенда ярдәмче-фикердәшләребез булырга мөмкин.

Бу уенны балалар бүлмәсендә Саумы фея күренүдән башлап җибәрсәң дә була. Бала үзенең киеме кесәсендә шаян кисәтү-күрсәтмә яки күнегү табып ала (аңа охшашлы күрсәтмәләр бу китапта аз бирелмәде, аларны бала үтәп карарга һәм үзенең кыланышларына бәя бирергә тиеш). Бәя гадәткә кереп киткән баллар белән генә күрсәтелергә тиеш түгел... Бала бүлмәсенең стенасына, көн саен, тиешле бәяләгеч-маска элеп куярга мөмкин. Әгәр бала үзен бөтен яктан үрнәк тоткан

икән — Саумы феянең елмаюлы маскасы күренә. Әгәр ул аз гына шаярган икән — шом маскасы. Әгәр үзен әйтеп бетермәслек начар тотса, стенага аждаһа сурәте эленә. Әлбәттә, боларның барысын да өлкәннәр оештырырга һәм эшләргә тиешләр.

Бала янында (ата-ана теләге белән) акыллы-зирәк Гномнарга да җан керсен. Аларның һәркайсына бала (безнең ярдәмебез белән) үзе үзләштергән әдәп кагыйдәләрен аңлатып бирә ала.

Шушы вакыттан башлап гаиләдә га дәткә кергән тәрбияви уен дөньясына әкият дөньясына баланың дус-ишләрен гаиләнең барлык кешеләрен һәм хәтта уенчыкларын да катнаштырырга мөмкин Без, өлкәннәр (бигрәк тә әниләр!), әгәр бик-бик телибез икән, беразга гына тылсым иясе булырга да көчебездән кила ләбаса.

ҖАНЛАНГАН РӘСЕМНӘР

Кызганычка каршы, теләсә нинди теләкне каршылыксыз үти торган гаҗәеп фонтан Алешаның яман теләген үтәде! Һәм шулай итеп Алеша дөньядагы иң әдәпсез малайга әверелде.

Ул әнисен, әтисен, ике әбисен һәм түтиен үчекләп, аларга телен күрсәтте дә үзе теләгән якка чыгып чапты. Юл уңаеннан Алеша йорт стеналарын ялый барды... Этләрнең, мәчеләрнең койрыкларыннан тартты... Кошларга таш ыргытты. Кечкенәләр кулыннан ашый торган морожныйларын тартып алды... Ул үзен шундый ямьсез тотты ки, аның бу кыланышларыннан Әкият-шәһәрнең олысы-кечесе һәм калган барчасы оятларыннан нишләргә белмәделәр. Алар кызардылар-бүртенделәр һәм киңәшләшү өчен биек манара төбенә фея янына йөгерешеп килделәр.

— Безнең теләк белән, Алеша әдәпле балага әверелсен өчен нишләргә кирәк?

— Гафу итегез... Бу турыда ныклабрак уйлап карарга кирәк булыр,— дип җавап бирде аларга фея.— Хәзергә мин сезне калдырып торам!

Шулай диде дә бүлмәсенә кереп бикләнде. Уйланды, баш ватты, тик бер фикергә дә килә алмады. Аптырап, яшерен тартмадан тылсымлы энциклопедиясен алды һәм эзләнергә, ак-

тарынырга, укырга кереште. Алай да эш барып чыкмагач, кәефе китүдән хәтта башы авырта башлады.

Саумы фея, аспирин эчеп җибәрде дә, ярдәмгә Читекчене, әдәп-тәртип Сакчысын, Күмәччене һәм Хат ташучыны чакырып алды.

— Алеша Ивановны тәртипкә кертү өчен ни кылабыз? — дип мөрәҗәгать итте ул аларга.

Сүзне Читекче башлады.

— Менә болай, — диде ул. — Мин аңа йөгерек башмаклар бүләк итәм. Алеша аларны кияр. Бөтен шәһәрне әйләнеп йөгереп үтәр... Андагы әкият могҗизаларын күрер һәм үзеннән-үзе яхшы, әдәпле малай буласы килер.

— Кызганычка каршы, — дип авыр сулап куйды Саумы фея, — төрле начар эшләр кылудан бу малайның күзләре матурлыкны күрмәскә әйләнде. Аңа бернинди могҗиза да тәэсир итми шул...

— Алайса... — диде әдәп-тәртип Сакчысы, кулын маңгаена куеп, — Алешага юлда йөрүнең барлык мәҗбүри кагыйдәләрен аңлату кирәк булыр. Әкияттәге дисциплинага һәм тәртипкә күнегеп, баланың үзеннән-үзе әдәпле буласы килер.

— Төрлечә кылануларын бу малайны ишетмәс иткән... — дип көрсенеп куйды фея. — Ул бер кагыйдәне дә ишетми.

— Әйдәгез, аңа мин пешергән сикертмә-кабартмаларны ашатыйк, — дип елмайды Күмәчче. — Алар авызга үзләре керәләр һәм әкияттәгедәй эреп китәләр! Аны ашауга, баланың әдәпле буласы килер.

— Шулай булса икән! — дип көрсенде фея. — Алеша — иркәлектән бозылган бала. Аның хәтта ашыйсы да килми, ул сикертмә-кабартмаларны ашамаячак...

— Ул вакытта бәйрәм ясыйк! — дип фикер әйтте шат күңелле Хат ташучы.

— Нинди бәйрәм? Тиктомалданмы?

— Барча балаларга һәм хәтта өлкәннәргә дә мөмкин кадәр ешрак күңел ачарга кирәк, — диде шат күңелле Хат ташучы. — Көләргә! Биергә! Әкият дөньясында йөзәргә! Ә әкият, белгәнебезчә, һәрвакыт яхшы тәмамлана. Шат күңелле шаян малайның, ахыр чиктә, үзенең тәрбияле кешегә әвереләсе килә башлар.

Шулчак манара очындагы калай әтәчләр бөтен дөньяга яңгыратып кычкырып җибәрмәсеннәрме:

— Кикрикү-ү-ү-к! Кызлар һәм малайлар! Бүген үзәк мәйданда Тылсымлы рәсемнәр бәйрәме үткәрелә.

Моны ишетүләре булды, малайлар, кызлар — сары чәчлесе дә, коңгырт һәм кара бөдрә чәчлесе дә — өлкәннәрдән әдәплегенә рөхсәт сорарга йөгерештеләр... Ә олылар, әлбәттә, балаларга бераз вакытка шөгыльләрен калдырып торырга, мәйданга ашыгырга рөхсәт иттеләр.

Ә биредә... Үзәк мәйданга бер машина да керми, кешеләр йөрми...

Мәйдан уртасында үзенең тылсымлы таягын күтәргән әдәп-тәртип Сакчысы басып тора. Аның янәшәсендә — эскәмиядә зонтик астында Саумы фея утыра. Тылсымлы буяулар, пумала һәм төрле төстәге акбурлар салынган тартмасы да үзе белән.

— Рәхим итеп,— диде Саумы фея балаларга,— һәркайсыгыз, кулына буяу, пумала, акбур тотып, үзәк мәйданның асфальтына теләгән нәрсәгезне ясагыз... Шуннан рәсемнәрегезгә җан керер!

— Ура! — дип кычкырдылар шатланышып малайлар һәм кызлар — сары чәчлесе дә, коңгырт чәчлесе дә, кара-бөдрә чәчлесе дә.

Узыша-узыша рәсем ясарга керештеләр.

Әй, бер заман асфальтта могҗиза-гөлләр чәчәк атты, могҗиза-күбәләкләр канатларын җилпеделәр. Могҗиза-агачлар ботакларын күккә җиткезде. Могҗиза-кошлар сайрап җибәрде.

...Шушы сәгатьтә Алеша паркта үсеп утырган юкәгә тырмашып менәргә маташмасынмы. Юкәнең нәкъ очында үзенең җиде нәни баласы белән карга гаиләсе яши иде.

— Ха-ха! Тузгытам хәзер оягызны! — дип кычкырды Алеша.

— Үтенеп сорыйбыз! Тимә безгә! — дип ялварды әти карга.

— Нинди начарлык! Әдәпсезлек! Оятсызлык! — дип оялтырга тырышты әнкә карга.

Юкә дә бик кызганды каргаларны.

Шулчак юкәнең Алеша ябышкан ботагы сынып китте... шарт итеп.

Барып төште Алеша җиргә... Шап итеп!

— Күрсәтәм әле мин сезгә! — диде малай ачудан кабарынып.

Ләкин шул вакытта калай әтәчләр кычкырып җибәрделәр:

— Кикрикү-ү-ү-к! Малайлар һәм кызлар! Йөгерегез үзәк мәйданга! Сезне анда тылсымлы акбур һәм буяулар көтә!

Алеша иркесездән шәһәр мәйданына чапты.

Үзәк мәйданда...

Мәйданның чем-кара асфальтына Читекченең берсеннән-берсе кечкенә җиде улы искиткеч чәчәкләр ясап утыралар. Аларның соңгы таҗ яфрагын ясап бетерүләре булды, чәчәкләр җанландылар, нечкә сабакларында тирбәлеп, башларын күтәрделәр, кояшка, балаларга ягымлы елмайдылар.

Үзәк мәйданда Күмәчченең оныгы күбәләк ясады. Аның соңгы ноктаны төртүе булды... Күбәләккә кинәт җан иңде! Канатларын җилпеп һавага күтәрелде!

Ә Хат ташучының Кызчык-Бөтерчек исемле кызы асфальтта башта, чәчәкләргә охшатып, сөйкемле карашлы шаян ике күз һәм алар янына әрекмән яфрагы кебек ике колак ясап куйды. Соңыннан бөдрә җирән ялын сызгалады.

— Нәрсә бу? — дип сорадылар аңардан рәсем ясарга кыймыйчарак торган иң нәни сабыйлар.

— Бу, мөгаен, күбаяклы Тулпар ат булыр, — дип көлде Кызчык-Бөтерчек. Дөньядагы иң-иң игелекле әкияти ат. Теләгән һәркем аңа берәр аяк ясасын. Юртак әкият-атның аяклары бик күп булырга тиеш.

Нәниләр, шуны гына көткәндәй, куанышып эшкә керештеләр. Күбаяклы Тулпар атның калган бөтен гәүдәсен Кызчык-Бөтерчек үзе ясап бетерде, озын кыллы койрык та тагып куйды. Шулчак күбаяклы Тулпар чын тере атка әверелде. Ыргылды! Җирән ялын селкетеп кешнәп тә җибәрде.

— Миһаһай! Менеп атланыгыз! Барыгызны да утыртам!

Малайлар һәм кызлар — сары чәчлесе, коңгырт чәчлесе, кара бөдрә чәчлесе — атка дәррәү сикереп менеп тә утырдылар. Алар артыннан фея менде... Аңардан калышмыйча әдәп-тәртип Сакчысы үрмәләде... һәм күбаяклы ат үзәк мәйдан буйлап чабып китте!

— Миһаһа!

Алеша Иванов шулчак читтә басып тора иде. Балалар аны да чакырдылар.

— Карагыз аны, — диде ул җене чыгып. — Күрсәтәм хәзер мин сезгә!

Алеша акбур һәм буяулар алды. Иң элек ике усал күз ясап куйды. Аннан соң — ике озын колак. Ике өркәчле борын östәде.

— Нәрсә бу? — дип сорады аның янәшәсендә басып торган Кызчык-Бөтерчек.

— Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян! — диде Алеша, кашларын җыерып.— Әкияттәге иң-иң явыз сихерче.

— Ай! — дип кычкырып җибәрле кыз куркуыннан.— Зинһар! Кирәкми! Ясама!

Әмма Алеша, эшен дәвам итеп, кулларын-аякларын ясады, хәтта аякларына биек үкчәле башмакка хәтле кигезде. Сул аягындагы башмакны ясап бетерүе булды... Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян төчкереп җибәрмәсенме! Асфальттан тере чын сихерче күтәрелде.

— Ә! Кем ясады мине?

— Мин,— дип кашын җыерды Алеша.— Ә син шуның өчен... Мине беркем дә беркайчан да тәрбияли алмаслык ит!

— Шым бул! — диде сихерче.

Һәм яман сүзләр әйтеп әфсен пышылдады...

Малайларның, кызларның барчасы — сары чәчлесе, коңгырт чәчлесе һәм кара-бөдрә чәчләре күбаяклы Тулпар аттан җиргә егылып төштеләр... Хәтта фея дә... Хәтта әдәп-тәртип Сакчысы да. Әкият-ат та туктап калды.

— Миһа-һа! Нәрсә бу! Уенмы? — дип гаҗәпләнде ул.

— Уйныйбыз! — дип акырды сихерче. Аннан Алешаны эләктереп алды һәм күбаяклы атка менеп тә атланды.— На! Чап! Әйдә!

Үзәк мәйдандагы халык аңга килеп өлгергәнче, алар инде билгесез юнәлештә күздән югалдылар!

Фея сорау бирә:

1. Алеша юкәгә нинди уй белән менә? Аның кыланышлары нинди?

2. Хат ташучының Кызчык-Бөтерчек исемле кызы сиңа ошадымы? Кайсы ягы белән ошады? Ни өчен?

3. Тылсымлы буяу белән Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян рәсемен ясап, Алеша яхшы эшләдеме? Аның бу эше яхшылыкмы, әллә яманлыкмы?

4. Син үзең кемгә охшарга теләр идең? Кызчык-Бөтерчеккәме? Әллә Алешагамы? Ни өчен?

СИН ЯШӘГӘН ЙОРТТА

Әкият-шәһәр кешеләре Алеша Иванов кая китеп югалды дип баш ваткан арада, әйдәгез, әкият маҗараларыннан китеп, бераз ял итеп алыйк. Иң яхшысы — синең туган йортың турында сөйләшүгә күчик...

Син беләсеңме икән ул йортны ничек төзегәннәрен?

Башта архитектор ватманда (сызым яки рәсем ясау кәгазендә) сызымын сыза. Ул синең тәрәзәңне (һәм барлык калган тәрәзәләрне), синең балконны (һәм башка балконнарны), сезнең кухняны (һәм икенче кешеләрнең кухняларын), алгы бүлмәләрне, коридорларны, баскыч алларын, бөтенесен-бөтенесен-бөтенесен сыза...

Бу искиткеч сызым төзүче-инженер кулына күчә. Төзүче-инженер бульдозерчыларга гаять тирән котлован казырга куша.

Котлован — ул йортның нигезен салу өчен ясалган чокыр. Нигезне бетоннан коеп ясыйлар. Бу — йорт җирдә нык утырсын, хәтта көчле әкият җилләре искәндә дә аумасын өчен шулай эшләнә.

Бульдозер эшен тәгәлләргә дә өлгерми, башка машиналар чаптырып килеп җитәләр. Беришеләре — цемент, икенчеләре — кирпеч, өченчеләре зур-зур төзү блоклары китерә. (Блоклар — йортның аерым өлешләре. Аларны заводларда ясыйлар.)

У-ух! Әнә ничек күңелле һәм үрчемле эшли монтажчылар, шоферлар, ташчылар... Көчле-акыллы машиналар һәм краннар, кешеләрне тыңлап, этаж артыннан этажны өеп кенә торалар.

Буяучылар килгәндә йорт төзелеп бетә язган була инде. Алар түшәмнәрне буйыйлар. Аннан обойчылар стеналарына обой ябыштыралар. Электрчылар йортка ут кабыза. Слесарьлар калган эшләрне тәмамлыйлар.

Шундый матур-күркәм килеп чыга өй!

Аның һәр тәрәзәсендә кояш нурлары уйный. Ә баскыч алларында кырыс йорт хуҗасы арлы-бирле йөри. Фатирларга күз сала: барысы да тәртиптәме, юкмы, шуны тикшерә. Тикшермәгән бер җирне дә калдырмый ул, бар нәрсәдән канәгать булгач кына:

— Өй туйларын башларга да була...— дип, күченергә рөхсәтен бирә.

Менә шунда башлана инде шатлыклы мәшәкатьләр! Яңа йортка бер-бер артлы мебель төялгән машиналар килеп туктый. Чәчәкләр белән! Баскыч алларында балаларның шатлыклы көлүләре яңгырый. Лифтка кемнеңдер юаш йонтач эте керә! Йорт каршына куелган эскәмиягә кемнәрнеңдер әбиләре чыгып утыра. Шул көннән башлап, кемнәрнеңдер әниләре, әтиләре, бабайлары, апалары әлеге менә шушы йортта гомер итә башлый...

Әлбәттә, син үзеңнең йортны бик яратасың, аны кадерләп саклыйсың. Шулай бит?

Менә шуның өчен син баскычка һәм баскыч алдына беркайчан да чүп

ташламыйсың. Матур өең чиста булса, синда да рәхәт ич. Өстәвенә, син әле җыештыручының хезмәтен ихтирам итәсең. Югыйсә аның хезмәте авыр икәнен үзең күреп торасың бит!

Син, йортка барып кергәнче, һәрвакыт аягыңны ышкып аласың.

Стеналарга һичкайчан язмыйсың, сызмыйсың. Лифтта уйнамыйсың. (Лифт бөтенләй балалар уйный торган урын түгел. Аның эшләми башлавы да бик мөмкин.)

Гомумән, дус-ишләрең белән баскычта һәм ишек төбендә уйнау әдәпсезлек... Уйламаганда берәү авырып китте, ди. Кемдер ял итә, яисә иҗат итә — көйләр чыгара, балалар өчен әкият яза, ди. Бу вакытта аларга теләсә нинди тавыш комачаулый. Шунлыктан иң җайлысы һәм әдәплесе — ишегалдына чыгып уйнау.

Анда балалар мәйданчыгы, ком, таганнар бар. Биредә дуслар белән туп уйнарга да ярый. Әгәр ишегалдын себерүче абзый рөхсәт итсә, агачларга һәм чәчәкләргә шлангтан су сиптерергә аңа булышырга мөмкин. Кышын ишегалдында кардан тау өяргә, хәтта крепость ясарга да була.

Хәер, азмыни андый кызыклы уеннар?

КҮМӘК УЕННАР

1. Асфальтта рәсем ясау. Эшкә керешкәнче, иң элек әниегез яки әтиегез, өлкәннәрнең берәрсе белән киңәшләшергә, алардан төсле акбурлар сатып алуларын һәм ишегалдында уен өчен яраклы урынны күрсәтүләрен сорарга онытмагыз.

Бу уенда теләгән һәркем катнаша ала: бер йорт балалары яки күрше йортныкылар да — биш тә җитә, егерме дә ярый.

Үз арагызда һәм өлкәннәр белән көнен, сәгатен сөйләшегез. Барыгыз да җыелгач, арагыздан кем дә булса, уенда катнашучыларның һәркайсына акбур, асфальтта рәсем ясау өчен мәйданчык бүлеп бирә.

Менә әзерләнеп тә беттегез. Хәзер кем дә булса боерык бирсен:

— Бер! Ике! Өч!

Барыгыз берьюлы асфальтта төсле акбурлар белән рәсем ясарга керешә. Безнең әкиятнең кайсы да булса героен, яки Әкият-шәһәрне — хәер, ни телисез шуны ясагыз. Сезнең ишегалды асфальтында җан керсен аларга!

Бу уенда катнашучылар барысы да җиңеп чыга. (Шуңа күрә, призга алма яки матур открытка һәркайсына бирелә — бу турыда олылар кайгыртырга тиеш, әлбәттә.)

2. Стенага рәсем ясау. Бу уенны әти-әниең яки әбиең рөхсәте белән генә башларга ярый. Алар бүлмә стенасына берничә табак ак кәгазь элеп куярга тиеш. (Ак ягы белән элеп куйсагыз, обой да ярый.) Сез-

нең үтенечегез буенча, өлкәннәр нәни уенчыларга төсле карандашлар, акварель буяулары яки гуашь сатып алалар.

Боларны син җыйнак кына итеп өстәлгә тезеп саласың һәм иптәшләреңне чакырасың.

Нәни малайлар һәм кызлар, кулларына пумала, карандаш, буяулар алып, безнең әкият геройларын ясарга керешәләр. Соңыннан нәни рәссамнарның һәрберсе ни өчен теге яки бу геройның рәсемен ясавы турында аңлата. Ул сайлаган геройның үзенә кайсы ягы белән ошавын әйтә.

Иң соңыннан нәни рәссамнарның барысына да призлар — төсле карандашлар һәм открыткалар тапшырырга мөмкин.

БУЯУЛАР БӘЙРӘМЕ

Әлеге һәм башка бик күп уеннарны дусларың белән Буяулар бәйрәмендә уйнарга мөмкин.

Аңа, бергәләшеп, гаиләнең барлык кешеләре белән хәзерләнсәң күңеллерәк була... Иң элек әти-әниләрең белән бәйрәм уздырылачак көнне һәм аның вакытын билгеләргә кирәк. Шул көнгә үз бүлмәңне тәртипкә китер. Әниеңә яки әбиеңә кунаклар өчен сый-хөрмәт әзерләшергә булыш. Табын җәй. Кунаклар өчен буяу карандашлары, җилем, кайчы, төрле зурлыктагы кәгазь битләре һәм буяулар әзерләгез.

Кунакларга аларны көтүең турында әйтеп куярга, буяулар бәйрәме уздырылачак көнне һәм сәгатен хәбәр итәргә онытма, дустым.

Кунакларны ачык йөз белән каршы ал. Кыз балаларга һәм иң нәниләргә чишенергә булыш. Аларның барысын да үз бүлмәңә чакыр. Һәрберсенә берничәшәр бит кәгазь, пумала, карандашлар һәм буяулар таратып чык. Хәзер рәсем ясый башласагыз да була. Кем ничек тели, шулай ясасын... Үзегез әкияти шәһәр уйлап ясагач, кызыклырак булыр. Моның өчен

1 нче күнегү. Һәр кунак йорт, манара яки сарай рәсемен ясасын. Бу рәсемнәрне тигез итеп кисеп, бер зуррак кәгазьгә ябыштырыгыз... Менә сезнең шәһәр рәсемегез булды да.

2 нче күнегү. Хәзер һәркайсыгыз агач яки гөл рәсеме ясасын. Аларны кисегез. Үзегез ясаган агач һәм гөл рәсемнәрен шул ук кәгазьгә ябыштырыгыз, әкияти шәһәрегездә сезнең теләк белән агачлар һәм гөлләр үсеп чыга.

3 нче күнегү. Инде хәзер аерым бер кечерәк кәгазьдә һәркайсыгыз төрле-төрле җәнлекләр һәм кош рәсемнәре ясагыз. Аларны кисегез һәм йортлар каршына чыккан, гөлләр чәчәк атып утырган әлеге кәгазьгә ябыштырыгыз. Шулай итеп, сезнең әкияти шәһәрегездә, нәкъ чын, тыл-

сымлы әкияттәге сыман, тере җан ияләре пәйда булыр.

Кунакларың рәсем ясап арыгач, дустым, аларны табын янына чакыр. (Тик башта кулларыгызны юарга кирәк булыр!) Юынгач, аларны бутерброд һәм чәй (яисә әниең яки әбиең белән бергә үзең пешергән тагын берәр ашамлык белән) сыйла.

Сыйланганнан соң, кунаклар белән хушлаш, бар нәрсәне дә тәртипкә китер.

Өлкәннәрдән сорарга онытма: алар фикеренчә, хуҗа буларак син үзеңне ничек тоттың икән?

Бәлки әле син, курчак-фея кесәсендә, үзеңнең Буяулар бәйрәмендәге тәртибең өчен берәр билге табып алырсың?..

Шунда минем янга тагын акыллы-зирәк Гномнар атылып килеп керделәр һәм:

— Урамга шулай озак чыкмый тору әдәплелек буламы? — дип кычкырып җибәрделәр.

— **Зинһар өчен, үтенеп сорыйм — акрынрак сөйләшегез,— дидем** мин аларга.— **Онытмагыз, бу гади һава сулап йөрү генә түгел...**

ӘДӘПКӘ ӨЙРӘНҮНЕҢ ӨЧЕНЧЕ ДӘРЕСЕ

Әмма минем сүзләремне акыллы-зирәк Гномнар ишетмәде булса кирәк, өйдән атылышып чыгып чаптылар! Түбәнге катка баскыч култыксасына утырып шудылар. **Ишек төбендәге нәни кызчыкны бәреп ектылар... Мин** тылсымлы таягым белән селтәнергә чак өлгереп калдым.

Селтәнүем булды, Гномнарның борын төбендә үк ишекләр шартлап ябылды.

— Нинди тәртипсезлек! — дип җырлап шыгырдады ишекләр.— Беренчедән, ишекне тотып торып, иң элек хуҗа апаны яисә теләсә кайсы башка хатын-кызны уздырып җибәрергә кирәк. Икенчедән, баскыч култыксасына утырып шуарга ярамый. Аның өчен лифт бар. Өченчедән, сезгә үзегез аяктан еккан кызчык алдында гафу үтенергә кирәк!

— Гафу ит...— дип борын астыннан гына мыгырдандылар Гномнар.— Без ни... Ашыктык!

— Мин ачуланмыйм,— диде кызчык, кулын сузып.— Мин Алена исемле.

— Ә без Гномнар,— диештеләр алар һәм ашыгып китеп тә бардылар. Урам аркылы шундый җилдерттеләр, чак кына автобус астына барып кермәделәр. Ә каршыга килә торган йөк машинасы алар гаебе белән шундый кискен тукталды, чакчак капланмый калды.

Шулчак Гномнар каршысында әдәп-тәртип Сакчысы пәйда булды.

— Гафу итегез,— диде ул әдәпле генә, кулын чигәсенә тидереп.— Сез юлда йөрүнең мәҗбүри кагыйдәләре белән бөтенләй дә таныш түгел, ахрысы.

— Нинди кагыйдәләр тагын ул?! — дип барысы берьюлы кычкырдылар Гномнар.— Безнең морожный ашыйсыбыз килә! Менә шул!

Әдәп-тәртип Сакчысы җай белән генә аларны урам аша чыгарып куйды һәм болай диде:

— Исегездә тотыгыз! Урамның икенче ягына җир асты юлларыннан яисә җәяүлеләр өчен ясалган махсус юлдан гына чыгарга ярый. Анда да иң элек светофорга күз салырга кирәк. Сары һәм кызыл ут янганда урамны аркылы чыгарга ярамый. Әгәр инде яшел ут яна икән, сулга карагыз... ул яктан машина килмәсә, урамның уртасына кадәр һич шикләнмичә атлагыз. Уртасына җиткәч, туктап уңга карагыз. Бу яктан да машина килмәсә, урамны аркылы чыгып китегез. Зинһар, тагын шуны да хәтерегездән чыгармагыз, тукталып торган трамвайның алдыннан борылып узарга кирәк. Автобус белән троллейбусның артыннан узалар. Бу кагыйдәләрне үтәвегезне сорыйм.

— Без тырышырбыз...— дип борын астыннан мышкылдадылар Гномнар һәм абына-сөртенә зәңгәр ларек янына йөгерештеләр. Анда берничә кеше басып тора иде инде. Акыллы-зирәк Гномнар этkәләшә-төрткәләшә алар алдына барып бастылар. Әгәр ларек янына безнең яңа танышыбыз — Алена барып җитмәгән булса, белмим, ни белән беткән булыр иде бу хәл.

— Болай эшләү — әдәпсезлек! Әйдәгез, без көтеп торыйк, морожныйны иң элек безгә кадәр килгәннәр алсын. Аннан соң менә бу әбине уздырыйк. Аңа басып тору, мөгаен, авырдыр...— дип пышылдады Алена Гномнарның үзләренә генә ишетелерлек итеп.

ИҖАТКА ЯКЫНАЙТЫП ТӘРБИЯЛӘҮ

(әти-әниләр белән сөйләшү)

Баланы поэзия, сынлы сәнгать, музыка матурлыгы белән таныштыру аны рухи яктан баета, кешеләргә һәм әйләнә-тирәгә карата иҗади мөнәсәбәттә булырга өйрәтә.

Үзләре ясаган рәсемнәрдә (уенда, әвәләп ясауда, аппликациядәге шикелле) кечкенәләр тормыштан алган тәэсирләрен чагылдыралар. Бала тирә-юньне күзәтүеннән үзенә ачышлар ясый.

Рәсем, уен кебек үк, баланы фикер йөртергә, хыялланырга, актив кичерешләргә өйрәтә. Бу сәләтләр үз чиратында баланың рухи үстерү һәм фикерләү культурасын тәрбияли һәм формалаштыра.

Күргәнен сурәтли алу осталыгы, тәҗрибәсе безнең нәни рәссамнарыбызда әле еш кына җитенкерәп бетми. Мондый очракларда без, олылар, бала белән берлектә, предметларны һәм аларның үзенчәлекле якларын кабат-кабат игътибар белән тикшереп карарга тиешбез. Ләкин әлеге ярдәм аңа һич тә мәҗбүриләп тагылмасын. Биргән киңәшләребез дә кырт кисеп әйтелмәсен. Әгәр киресенчә эшли-

без икән, без баланы күңеле белән шуңа омтылган мөстәкыйльлегеннән мәхрүм итәбез.

Күпчелек ата-аналар тәрбия эшендә безнең һәркайсыбызга балалар иҗаты биргән мөмкинчелекләрне дөрес аңлап, аңа игътибарлы һәм җитди карыйлар. Чөнки балалар иҗаты безгә, ата-аналарга, тәрбиячеләргә, тирә-юньгә балалар күзе белән карарга; шулай итеп балаларыбызны яхшырак белергә, аңларга, аларның проблемаларын, курку-шатлыкларын һәм үсеш нечкәлекләрен өйрәнергә мөмкинлек бирә. Бу инде баланы аңлы тәрбияләүдә өстәмә мөмкинлекләр ачылу дигән сүз.

Без, ата-аналар, балаларыбызны иҗатка сак, игътибарлы булырга күнектерергә тиешбез. Моның өчен, күрәсең, бала белән бергә аның рәсемнәрен (ясаган әйберләрен, пластилиннан әвәләгән сыннарын) ешрак караштыргалап торырга кирәктер. Алар буенча фикер алышу, мөмкин кадәр мактауга саранланмау, кирәк икән, файдалы киңәшләр бирү яки бала тарафыннан сайланып алынган темага, ул сурәтләгән геройлар яки вакыйгаларга карата сораулар кую урынлы.

Баланың үз эшен төгәлләмичә, арып, рәсем ясаудан туеп, аны кинәт кенә ташлау очраклары да булырга мөмкин, андый вакытларда эшне ташлауның төп сәбәбен ачыкларга тырышырга кирәк. Нәни рәссамыбызның уңышсыз эшеннән кәефе дә китүе ихтимал. Сәбәп нәрсәдә генә булмасын, балага кушылып, башлаган эшкә яңадан кайтырга һәм аны төгәлләргә кирәк. Болай эшләп без баланы түзем булырга, теләсә нинди эшкә җитди карарга өйрәтәбез.

Ләкин шунысы мөһим, балагызның эшен күреп таңга калуыгызны аңа артык сиздерергә, аны күккә чөеп мактарга, рәссам карьерасын вәгъдә итәргә ярамый. Үзен башкалардан яхшырак, өстенрәк итеп күрү тойгысы тора-бара баланың характерында масаючанлык, дусларына (аның карашынча, алар андый сәләткә ия түгелләр бит!), гомумән, кешеләргә кимсетеп карау кебек сыйфатларның үсүенә китерә.

Әйдәгез, иң яхшысы — үз балабызның иҗади мавыгуын игелекле эшкә юнәлтик. Моның өчен, һәр форсаттан файдаланып, нәни рәссамыбызга үзенең иң-иң яхшы рәсемнәрен (ясаган әйберләрен, аппликациясен) әбисенә, дустына, сеңлесенә бүләк итәргә киңәш бирик. Бала белән берлектә, ул ясаган әйберләр һәм рәсемнәр белән курчак бүлмәсен, балалар почмагын бизәп карыйк.

Эстетик тәрбия, матурлык дөньясына кечкенәдән якынайтып тәрбияләү сәнгатьнең барлык төрләрен дә үз эченә ала. Менә ни өчен балаларыбызның тормышы сынлы сәнгать белән генә түгел, бәлки музыка, әдәбият белән дә баетылырга тиеш. (Болар иң элек гади генә балалар җырларыннан һәм балалар әдәбиятыннан башланса да була.)

Тәрбиянең теләсә кайсы башка төре шикелле үк, сәнгать белән тәрбияләү дә максатка ярашлы, тирәнтен уйланылган, педагогик белемгә корылган булырга тиеш. Баланың баш мие теләсә нинди информацияне гаять нык сеңдерүчән, һәм биредә инде тәрбиячењең төп бурычы бу информацияләрдән тиешлесен сайлап алу, балага алар белән артык мавыгырга ирек бирмәүдән гыйбарәт.

Телевизордан яки кинотеатрда караган һәрбер фильм, укылган яки сөйләнгән һәр әкият, балалар өчен булган һәр спектакль турында бала белән фикер алышу, аңардан кайсы геройның ни өчен ошавын, кайсылары ошамавын сорау; яраткан герое урынында ул булса үзен ничек тотар иде, шул турыда хыялга бирелеп алу зарури.

Шулай итеп без баланы кабул итү — үзләштерү культурасына өйрәтәбез, аның тойгыларын һәм акыл-фигылен тәрбиялибез.

Әмма эстетик тәрбиянең теләсә кайсысы — бу иҗатка якынайтып кына тәрбияләү дигән сүз түгел. Без балаларыбызны матурлыкны күреп тоя белергә аларны табигатькә якынайтып та, яши торган төбәгебезнең архитектурасы белән таныштырып та, Җир йөзендә безгә кадәр яшәгән һәм хәзер яши торган искиткеч кешеләр турында сөйләп тә өйрәтәбез. Даими рәвештә балаларыбызның белем дәрәҗәсен киңәйтәбез. Игътибар белән күзәтергә, тыңларга өндибез, дөньяга иҗади мөнәсәбәттә булырга өйрәтәбез.

БАЛАЛАР ҺӘМ АТА-АНАЛАР ӨЧЕН БИРЕМНӘР

Бу ярышларда балалар гына түгел, өлкәннәр дә катнашырга тиеш. Ике команда — балалар һәм олылар командасы оештырыла. Һәр командада өчәр-дүртәр кеше.

Ярышта катнашучы һәр кешегә төсле карандашлар, пумала, буяулар, кәгазь бирелә.

Рәсемнәрнең темасы — безнең әкиятнең теләсә кайсы сюжеты.

Рәсемнәрне олылар да, балалар да ясый. Аннан соң, ярышта катнашучыларның барысы да эшләрен тәмамлагач, һәр ике команда рәсемнәрен алмашалар. Өлкәннәр, җитди нигезләп, балалар рәсемнәренә бәя бирәләр. Балалар үз чиратында уенда катнашучы өлкәннәр рәсемнәренә бәя куя. Алар тегe яки бу рәсемнең ни өчен ошавын яки ошамавын шулай ук аңлатып бирергә тиеш.

Уен тәмамлангач, җиңүче командага алдан әзерләп куелган берәр төрле шаян приз тапшырыла.

Бала кайсы да булса бер әкиятне үзләштерсен һәм хәтерендә калдырсын өчен, аны сөйләп бирү һәм үзе катнашында сәхнәләштерү файдалы.

Шул рәвешчә, бу китаптагы әкиятнең аерым бүлекләрен, рольләргә бүлеп, укып яки сөйләп чыгарга мөмкин. Хәер, башка вариантның да булуы ихтимал.

Әкиятне чираттагы укуда аның сюжетын аз гына үзгәртергә тырышып карагыз. Бу очракта әкияттәге тегe яки бу геройның башка төрле шартларда үзен ничек тотачагы турында бала үзеннән чыгарып (сезнең ярдәмегез белән булса да ярый) сөйли.

Мәсәлән:

1. Тылсым Фәннәре Академиясеннән үз шәһәренә юл алган Саумы феянең кинәт зонтигы сына, һәм ул карурман уртасына килеп төшә...

Карурманда фея ниләргә дучар була?

Аннан ничек чыга?

2. Әдәп-тәртип Сакчысы бервакыт, үзәк мәйданда сакта торганда, барлык белгән матур сүзләрен онытып җибәрә һәм әдәпсез Сакчыга әверелә.

Моннан соң нәрсәләр була?

Шәһәрдә нинди тәртипсезлекләр башлана?

Матур сүзләрне әдәп-тәртип Сакчысының хәтеренә кем төшерә?

АКЫЛГА СЫЙМАСЛЫК МАҖАРАЛАР

Элдертә генә күбаяклы Тулпар ат! Әкият-шәһәр дә... Шикәр тавы да... Ерак, бик ерак юллар да... Ялан кырлар-аланнар да артта кала... Ә алда — карурман.

Карурман уртасында тавык тәпиләрендә кечкенә өй.

Аның тирә-ягында узган-барганнарга кызыл-сары-зәңгәр чәчәкләр ягымлы елмая. Кояшка тартылып зәңгәр үләннәр үсә.

Көмеш ботакларда кызыл тиеннәр черт тә черт чикләвек ашап утыра.

Өйалды баскычы каршында карт нарат. Аның очы күккә тигән. Төннәрен анда йолдызлар качыш-качыш уйный. Иртәләрен ботакларга кунып болытлар йокымсырап ала. Ә кичләрен караңгы куышыннан колакчын Байгыш абзыкай күзен елтырата. Ухх-хылдап, хих-хылдап урман җан ияләренә әкиятләр сөйли.

Кубаяклы Тулпар ат менә кая килеп чыкты.

Явыз сихерче белән Алеша тавык тәпиләрендәге өйгә килеп керделәр.

Өй уртасында — мич. Мичтә — казан.

Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян яман-мәкерле сүзләрен пышылдады һәм шунда ук казанда зәһәр сыекча бүлкелдәп кайный башлады.

Әлеге зәһәр сыекчаны сихерче зур сиптергечкә тутырды һәм барча җиргә сиптерде...

Кызыл-сары-зәңгәр чәчәкләр каралдылар. Үләннәр кибеп саргайды. Көмеш ботакларда чикләвекләр череде. Тиеннәр ызгышып беттеләр. Менә нинди хәлләр...

Караңгы куышлыктан Байгыш абзыкай очып чыкты. И тотынды тавышланырга:

— У-уф! Ха-ха-ха!

Бу тавышка җанварлар чабышып килделәр. Ап-ак каенлыктан сикерә-чаба куяннар килде. Ерак ермактан — төлкеләр. Чытырманлы чыршылыктан — ике соры бүре. Өненнән чыгып үзенең балалары белән Аюниса. Алар эһ итәргә дә өлгермәделәр, китте мәхшәр! Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян бөтенесенә зәһәр сыекча сибеп чыкты.

Төлкеләр ләңгелдәде. Бүреләр улады, куяннар аю балалары белән сугыша башлады. Ә Байгыш абзыкай хуплап куыштан кычкырып торды:

— Бир кирәген! Уф! Ха-ха-ха!

Аюниса, кызып китеп, бөтенесен бәргәләде-суккалады.

— Ай-ай!

Хәтта Алеша малайга да!

— Охо-хо-хо!

Хәтта усал-явыз сихерче Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янга да эләктереп алды.

— Миһаһа!

Хәтта кубаяклы игелекле әкияти атка да.

— Мин алай уйнамыйм! — дип хәтерә калды кубаяклы Тулпар атның.— Миһаһа.

Һәм үзе теләгән якка чабып китте.

— Ха-ха-ха! — дип усал көлде сихерче.— Менә хәзер мин синең теләгеңне үтим инде,— диде дә малайга зәһәр сыекча сипте.— Хәзер сине беркем тәрбияли алмас! Инде син үзең дә усал-явыз сүзләр әйтә һәм яман эшләр кыла аласың! Тик кара аны! Аждаһага әвереләсе булма!

Киек-җанварлар һәм кошлар, Алешага карап, ачынып еладылар.

— Ха-ха! — диде малай, барысына төкереп.— Хәзер мин барыгыздан да көчлерәк. Әһә!

Ул мәһабәт чебен гөмбәсен тибеп өзде дә башына чәпәп куйды. Баскычка атылып чыкты да тавык тәпиләрендәге өйгә бик тиз генә шәһәр ягына юл тотарга боерды.

Өй аны тыңлады, һәм шундый зур тизлек белән алдырып китте ки, хәтта Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян тәрәзәгә сикерергә чак өлгереп калды.

Ә Әкият-шәһәрдә ыгы-зыгы, гаугa, шау-шу! Олысы-кечесе чаба, кычкыра, кемнедер чакыра, паркта эскәмия асларын карыйлар... Һәркайда, һәр җирдә Алешаны эзлиләр!..

Аны беренче булып Кызчык-Бөтерчек күреп алды.

— Йөгер гаҗәеп фонтан янына! — дип кычкырды ул Алешага.— Сине анда әниең, әтиең, ике әбиең һәм түтиең көтәләр!

— Әһә!..— дип ысылдады сихерче.— Хәзер алар сине тәрбияли башлаячаклар.

Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян һәм малай кычкырып яман сүзләр әйттеләр...

Кызчык-Бөтерчек кинәт һуштан язып катып калды! Ул бер адым да атлый алмады. Әрнүеннән хәтта елап ук җибәрде.

Шулчак Алеша үзендә чын аждаһа койрыгы үсә башлавын сизде!

Ул да түгел, аның алдына әдәп-тәртип Сакчысы калкып чыкты.

— Нәрсә бу, ни булды? — диде тәртип Сакчысы.

— Ул сине тәрбияләргә тели...— дип зәһәр пышылдады Алешага Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян.

Алар икәүләшеп яман сихер сүзләре пышылдадылар...

Әдәп-тәртип Сакчысы кинәт авырлыгын югалтты. Шулчак аны көньяк-көнбатыш җиле очыртып шәһәр өстеннән әкияти юнәлештә билгесез якка алып китте.

Ә малайның аяк-куллары аждаһа тәпиләренә әверелде.

Алеша куркуыннан хәтта:

— Әни-и! — дип чыелдап ук җибәрде.

Ә энисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие аның каршысына ашыгалар иде.

— Инде хәзер сине болары тәрбияли башлаячак... — дип пышылдады Алешага явыз сихерче.

Һәм Алеша ялгышлык белән... Начар гадәте буенча... Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янга ияреп яман сүзләр пышылдады... Әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие асфальтта тосле акбур белән ясалган рәсемнәргә әверелделәр!

Күз ачып йомганчы Алеша чын аждаһага әверелде. Авызыннан төтен чыгарып, ут чәчеп тора торган, койрыклы, өч башлы аждаһага.

— Кикрикү-ү-үк! — дип кычкырдылар калай әтәчләр. — Әкият-шәһәрдә яман могҗизалар!

— Шым булыгыз! — дип боерды сихерче. — Югыйсә мин сезне яңгыравыклы тавышыгыздан мәхрүм итәм.

Ләкин калай әтәчләр аны тыңламадылар. Сихерче озак уйлап тормады, кычкырып җибәрде һәм үзенең явыз ниятен үтәде:

— Кикрикү-үк-ү-үк! Аждаһа! Алеша — Аждаһа! Ха-ха! Хәзер мин сине чылбырлап куям. Син минем тавык тәпиләрендәге өемне сакларсың. Узган-барганның үкчәләрен тешләп калырсың! Ут һәм төтен чәчәрсең! Кикрикү-ү-үк!

Фея сорау бирә:

1. Ни өчен син Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янны ошатмадың?

2. Алеша нинди усаллыклар кылды, ни өчен Аждаһага әверелде?

3. Сихерче Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян яхшы интешме, әллә начармы? Син аның белән дуслашыр идеңме? Юк? Ни өчен?

4. Безнең әкиятнең кайсы герое белән дуслашыр идең? Ни өчен?

ЧЫН ТЫЛСЫМ ИЯЛӘРЕ
(балалар белән сөйләшү)

Минемчә, син, дустым, усал тылсым ияләреннән курыкмый торгансыңдыр. Хәер, ни өчен куркырга ди, әкиятләрнең азагы һәрвакыт яхшы бетүен һәр кыз, һәр малай белә ич.

Безнең әкияттә дә нәкъ шулай, уңай геройлар җиңеп чыгачак. Нигә әле безгә алдан әйтеп куярга? Әкият ашыкмыйча, кабаланмыйча гына үз юлы белән бара торсын. Шул арада минем нәни дустым анда тагын ниләр булачагын уйлый торсын, шул вакыт эчендә нинди дә булса файдалы нәрсәгә өйрәнсен.

Ә тылсым ияләренә килгәндә, сүз уңаеннан әйтим, алар әкиятләрдә генә яшәми бит!

Үз эшен намус белән, тырышып, яратып башкарган яхшы күңелле һәр кеше бераз гына тылсым иясе.

Чын менә, әкияттәге кебек!

Ташландык, ялангач урында берничә ай эчендә йорт салып кую — тылсым түгелмени? Кояшка караган тәрәзәләре, рәшәткәсенә карт тирәк елышып үскән болдыры, гөлләр шаулап утырган, байраклар җилфердәгән балконнары белән.

Ә газаплы сырхаудан хезмәткә яраксыз хәлгә килгән, дуслары белән очрашудан мәхрүм булган авыруны сәламәтләндерү... Менә ул кеше хәзер яңадан чаңгыга басып походка чыкты... Дуслары белән очраша. Эшли. Яңадан сау-сәламәт, шат күңелле. Бу могҗиза-тылсым түгелмени?

Яисә... Бакча үстерү. Ул кышын ап-ак бәскә чумып утыра, йоклый. Тик ара-тирә кып-кызыл миләш кенә күренгәли. Балан чыпчыклары чикылдап ала... Ә яз җитүгә, кояшның җылы, күз чагылдыргыч нурлары астында, кар бик тиз эреп юкка чыга. Шунда бакчага әйтерсең лә алсу-кызыл ут капкан диярсең, менә-менә кабынып китәр төсле. Чәчәкләр туенда умарта кортлары гөжли. Җирнең матурлыгы турында барлык кешегә ишетелерлек итеп кошлар җыр суза. Ә җәй җитү белән җиргә чәчәк ява — күзгә һәр ботакта могҗиза-тылсым эленеп торсын өчен ул шулай ява бит. Тик иң яхшы күңелле тылсым ияләре генә моны эшли ала!

Ә йөк машинасын уйлап табу һәм ясап-җыю? Бу бер генә кеше кулыннан килә торган могҗиза түгел. Бирегә йөзләгән чын тылсым ияләре станоклар, сызымнар артында хезмәт итә.

Ә бозваткычта юл ярып полюска чыгу! Боз кыялары, боз таулары аша... әлбәттә, юлда очраган һәрбер аюга яки пингвинга әдәпле генә сәлам бирә-бирә...

Чынлап әйтәм: бик яхшы чын тылсымчы гына авызда эреп китә торган тортлар пешерә ала! Капсаң — телеңне йотарсың. Тагын-тагын ашыйсы килә!

Бу дөньяда, безнең үз тирәбездә чын тылсым ияләре аз түгел! Тик, аларны күрү өчен, бөтен танышларыңа һәм таныш булмаганнарыңа игътибар беләнрәк карарга гына кирәк.

Хәер, еракка китәсе дә юк... Синең әниең тылсым иясе түгелмени?

Кулыннан нәрсә генә килми аның! Аш пешерү дисеңме. Сиңа күлмәк тегү. Күңелле җыр җырлау. Китап уку. Әкият сөйләү. Үтүкләү. Уу-юу... Өегезгә ямь кундыручы да әниеңнең тылсымлы куллары...

Ә әтиең? Ул вакыт-вакыт чын тылсым иясенә әйләнмимени? Биек таудан чаңгыда шуып төшәргә өйрәткәндә!.. Күп булса егерме минут эчендә, уйный-көлә, паркет идәннәрне ышкып ялтыратканда!.. Фоторәсем ясаганда... Ә син караңгы тылсымлы могҗизалар бүлмәсендә аның эшен күзәтәсең... Ә йөзүен күр син әтиеңнең! Ничек чума! Нинди кыю ул, яхшы күңелле!..

Әбиең, бабаең, һәм башка танышларың да, дустым, барысы да яхшы күңелле тылсым ияләре.

Синең үзеңә тылсым ияләреннән бик күп нәрсәгә өйрәнәсең килә, әлбәттә. Әлегә бит син үзең могҗизалар ясый алмыйсың.

Хәер, алай дип әйтүем ялгыш булыр.

Әле син бик кечкенә, һәм шуңа күрә әниең яки әтиең кадәр үк күп белмисең. Ә бит синең кече туганнарың — энең яки сеңлең синнән дә кечерәк, кечерәк, синнән дә азрак беләләр. Шулай түгелме? Димәк, син алар өчен бүген үк чын тылсым иясе. Син аларга киенергә, аяк киемнәрен кидерергә булышасың. Аларны урамга алып чыгасың, манный боткасы ашатасың.

Хәзер күз алдына китер әле: әйтик, үзең яши торган төбәкнең урманы яки паркы буйлап атлыйсың, ди. Анда син һәр кырмыска, үлән сабагы, күбәләк яки чәчәк өчен кодрәтле тылсым иясе. Үз ихтыярың белән яман яисә яхшы могҗизалар тудыра аласың.

Тәрбиясез бала, явыз тылсымчы шикелле, кырмыска оясын рәхимсез туздыра, иелеп үскән агачны сындыра, матур күбәләкне тотып, аны җәберли... Урманда яшәүче нәни җан **ияләре аның аяк тавышыннан ук калтырап төшәләр.**

Әдәпле балалар кошлар һәм тиеннәр өчен үзләре җимлек ясыйлар. (Һәм көн саен җим куялар.) Алар беркайчан да чуар чебен гөмбәсен тибеп өзмиләр. Чөнки шәфкатьле тылсым ияләре, чебен гөмбәсенең агулы икәнен белсә дә, аның урман туфрагы өчен гаҗәп файдалы ашлама икәнен дә бик яхшы аңлыйлар. Алай гына да түгел, куян, тиен, кошлар һәм башка киек-җанварлар өчен бик шәп дару икәнен дә исеннән чыгармыйлар.

2—8 яшьлек нәни тылсым ияләре, сезнең кулдан килерлек игелекле эшләр аз түгел лабаса. Тик биредә сезнең ихтыярыгыз һәм тырышлыгыгыз гына кирәк. Мин үзем сезнең ялкауланмыйча, көнгә берне генә булса да, һәркем күңеленә хуш килердәй шундый могҗиза эшләргә тырышачагыгызга ихлас күңелемнән ышанам.

ЯХШЫ КҮҢЕЛЛЕ ТЫЛСЫМ ИЯЛӘРЕ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

1 нче күнегү. Әниеңнән яки әбиеңнән кечкенә таз сорап ал. Аңа бераз җылы су сал. Әниеңнең идән юа торган чүпрәген табып ал. Аны суга манчы. Аннан җайлап кына сыгып, аның белән бик тырышып кухня идәнен сөртеп ал. Кухня идәнен сөртеп бетергәнче, чүпрәкне суга берничә тапкыр манчып сыгарга кирәк. Идәннең кырыйларын, өстәл, урындык асларын да сөртергә тырыш.

Эшләп бетергәч, зинһар, чүпрәкне чайкап сыгарга, киптерергә эләргә онытма.

2 нче күнегү. Әтиең яки абыең белән (апаң яисә әниең белән дә мөмкин) урманда коры, ләкин бик үк нечкә булмаган чыбык-чабык җыеп алыгыз. Алардан тигез озынлыктагы таяклар ясагыз.

Бу таякларны үзегез күзәтеп йөргән кырмыска оясы тирәли кадап чыгыгыз.

Хәзер бу кырмыскалык һәр узып йөрүчегә ерактан күренеп торачак, беркем дә аңа ялгыш басмаячак, кырмыска өен җимермәячәк.

Ай-һай, тагы ни булды минем кухняда? Күк күкри диярсең! Кухнядан кара болытлар агыла...

Йөгердем! Тизрәк!

Әлбәттә, шулай булып чыкты да... Бу — акыллы-зирәк Гномнар! Өчәүләшеп идәнгә чүмәшкәннәр дә тыннары бетүдән еламыйлар гына. Ә яннарында ук газ плитәсендә зур таба утыра. Менә каян бөркелә икән төтен...

Кухня өстәлендәге ашъяулыкны нәрсәгәдер буяганнар. Йомырка кабыклары аунап ята, **өстәлгә түгелгән сөт идәнгә агып төшеп бара.**

— Гафу ит...— диделәр Гномнар.— Без сине шатландырмакчы идек!

— Без йомырка тәбәсе кыздырырга булдык... Ләкин таба тыңлаусыз булып чыкты.

— Ярар инде,— дидем мин, алар белән ризалашып һәм кухняны тәртипкә китерергә тырышып.— Шулай да икенче вакытта әйберләр сүзегезне тыңласын, ә кулларыгыз оста-җитез эшләсен өчен, әйдәгез, тиз генә әдәпкә өйрәнү дәресе үткәреп алыйк әле...

ӘДӘПКӘ ӨЙРӘНҮНЕҢ ДҮРТЕНЧЕ ДӘРЕСЕ

— Беренчедән,— дидем иң акыллы-зирәк Гномнарга,— зинһар өчен, хәтерегездә калдырыгыз: һәрбер гномның (шулай ук һәр малайның һәм һәр кызның) көнләп бүленгән вазифалары булырга тиеш.

— Вазифа? Ә нәрсә ул вазифа? — дип сорадылар Гномнар.

— Вазифа — һәр көн үтәлергә тиешле мәҗбүри эшләр. Һәр иртәдә, мәсәлән, үзең яткан урынны җыярга кирәк. Уйнап туйгач — уенчыкларны, китапларны, төсле карандашларны һәм альбомнарны тиешле урынга куярга. Һәр көн яисә көн аралаш үз бүлмәңне себереп чыгарырга, тузанын сөртергә, ашаган савытыңны юарга, тышта йөргәннән соң, аяк киемнәрен чистартырга кирәк.

Ә инде әкият гномы (яки тормыштагы 6—7 яшьлек малай яки кыз) гади генә иртәнге аш әзерләргә өйрәнсә, бусы инде бигрәк тә шәп. Моңа өйрәнү өчен, иң элек үзеңнең өлкән дусларыңнан — әниеңнән яки әбиеңнән — ярдәм сорарга кирәк. Өлкән дустың йомырка тәбәсен ничек кыздырырга яки манный боткасын ничек пешерергә икәнен, әлбәттә, бик теләп аңлатыр һәм күрсәтер. Әле бу эшне ике-өч тапкыр әниең яки әбиең белән эшләп карарга ки-

рәк булыр. Шуннан соң иртәнге яки кичке ашны үзең генә мөстәкыйль әзерләп карарга да ярый.

1 нче күнегү. (Уен-ярыш.) Өйалды идәненә ике-өч газета җәегез, аңа ике-өч пар аяк киеме куегыз (уен-ярышта катнашучылар санынча). Һәр уйнаучыга дымлы чүпрәк, аяк киеме щеткасы һәм тиешле төстәге крем бирегез.

Өлкәннәрдән кем дә булса боерык бирә:

— Бер! Ике! Өч!

Ярышта катнашучы һәр кеше үзенә билгеләнгән аяк киемен чистарта башлый. Эшен тиз һәм яхшырак башкарып чыкканы җиңүче була.

2 нче күнегү. (Уен-ярыш.) Берничә кисәк тукыма һәм төрле төстәге төймәләр әзерләгез. (Аларның саны уйнаучылар санынча булырга тиеш.) Команданы гаилә кешеләреннән генә дә — әти, әни, әби һәм балалардан — төзергә мөмкин. Һәр уйнаучыга тукыма кисәге, икешәр төймә, кәтүк җебе, кайчы һәм энә бирелә.

Кем дә булса боерык бирә:

— Старт!

Ярыш башлана: ике төймәне кем тизрәк һәм ныграк тегә?

Аның ни дәрәҗәдә нык тегелүен белү өчен, һәрбер уйнаучы күршесенең таккан төймәләрен тартып карый (тегеп бетергәннән соң). Ике төймәне дә тизрәк тә, ныграк һәм дөресрәк тә таккан кеше җиңүче була.

3 нче күнегү. (Уен-ярыш.) Бәрәңгене кем яхшырак һәм тизрәк әрчүен дә шул рәвешле тикшерергә мөмкин. Һәр уйнаучы пычак һәм өч бәрәңге ала. Әрчелгән бәрәңгене кыздырып, уенда катнашучыларны сыйлыйлар.

Мондый ярышларны Могҗизалар бәйрәмендә оештырырга мөмкин.

МОГҖИЗАЛАР БӘЙРӘМЕ

Бу бәйрәмне син, нәни дустым, өеңдә үткәрә аласың. (Тик элек өлкәннәр белән киңәш. Алар сиңа кайсы көндә үткәрергә икәнен әйтерләр). Әгәр әниеңнең, әтиең яки әбиеңнең бу көнне буш вакытлары булса, алар сый әзерләргә, табын җәяргә сиңа бик теләп булышырлар. Дөресен әйткәндә, Могҗизалар бәйрәмендә барлык нәрсәне балалар үзләре әзерләргә тиеш, ул башка бәйрәмнәрдән шуның белән аерыла да. Бу бәйрәмдә өлкәннәр балаларга киңәш белән генә ярдәм итә алалар.

Бүлмәңне үзең җыештырып чыгарырсың. Кунаклар өчен салат яки бутербродларны үзең әзерләрсең. Табын җәярсең. Дусларыңны каршы алырсың һәм табын янына утыртырсың. Аннан соң алар белән төрле-төрле уеннар һәм күңелле ярышлар үткәрерсең. Бәйрәм тәмамланганнан соң, кунакларны әдәпле генә озатып калырсың. Алардан соң савыт-сабаны үзең юарсың, табынны җыештырырсың һәм кухня идәнен себереп алырсың.

Могҗизалар бәйрәмендә синең әниең, әтиең, әбиең, бабаең һәм башка өлкән дусларың, кунакларың булсыннар. Әгәр син аларны әдәпле генә кунакка чакырсаң, бу аларның күңеленә бик хуш килер.

БӘЙРӘМНӘРНЕҢ ТӘРБИЯВИ РОЛЕ
(өлкәннәр белән сөйләшү)

Ихтимал, теләсә кайсы тәрбиячененң иң зур осталыгы, аның иң күркәм ягы — бала белән аралашудан шатлык, бала тәрбияләүдән тәм таба һәм бу шатлыкны үз балаларына юмарт бүләк итә алуындадыр.

Гаиләдә рухи шартларның, бала сулый торган әхлакый «һава»ның нинди булуы безгә — ата-аналарга бәйле. Гадәти эш көннәрен бәйрәм көннәренә әверелдерү дә үзебездән тора.

Өйдәге күңеллелекнең, дустанә һәм шатлыклы җанлылыкның балаларга уңай йогынты ясавын без бик яхшы беләбез, әлбәттә.

Гаилә бәйрәме бик кечкенәдән күңелле уенга әверелеп, йорт җыештырудан башланырга мөмкин. (Тик иң элек йортны ничек төзегәннәрен, кемнәрнең хезмәте кергәнен, агач эше осталарының ничек итеп мебель эшләгәннәрен, йортны төзеп бетергәч, буяу эшләре турында сөйләргә кирәк... Безнең балаларыбыз өй каршында, тәрәзә төпләрендә шау чәчәктә утырган гөлләр турында әкиятләр һәм хикәяләр белсеннәр...) Безнең йортларда һәрчак уен һәм әкият яшәсен.

Балага, әгәр ул тырышлык куйса, үзенең дә «могҗизалар» ясый алуын аңлатабыз.

«Әгәр син тәрәзә төбендә үсеп утыручы гөлләргә һәркөн су сибәсең икән, алар сиңа ияләшәләр. Беләсең килсә, нәнием, сине ярата башлыйлар, һәр сибүеңнән соң, сиңа ишеттерми генә диярлек, пышылдап «рәхмәт» әйтәләр, чөнки бу дөньядагы барлык гөлләр яхшылык кына телиләр, алар әдәплеләр. Үзләре яраткан һәркемне шатландырырга тырышалар. Бер дә бер көнне яшел яфраклар арасында кызыл, зәңгәр, ак яки кызгылт-сары могҗиза ачыла.

Шуңа күрә, нәни дустым, гөлләргә бер көн дә су сипми калма!»

«Китап шкафында тылсым ияләре һәм фейләр яши. Моны һәркем белә. Теләсә кайсы китапны ач кына, шунда ук могҗизалар башлана... һәм шуның өчен... Көлбикә күлмәгенә тузан кунмасын дисәң... Игелекле карт король тузанда үзенең таҗын югалтмасын дисәң... Әкият-батырның аты тузанга батмасын дисәң... китап шкафында бер тузан да калмаслык итеп сөртергә кирәк.

Энемме син, сеңлемме! Кулыңа чүпрәкне җәлт кенә ал да, эшкә кереш!»

Үзебез уйлап чыгарган бу тәрбия чаралары безгә, ата-аналарга, күпчелек йорт эшләрен (бу яшьтәге бала үтәү мәҗбүри булган эшләрне) уенга, кызыкка, әкияткә әверелдерергә ярдәм итә. Шулай, уен аша, без баланы хезмәттән тәм табарга, аны һәрвакыт шатлыкка, һәрвакыт бәйрәмгә санап, бәхет хисе тоярга өйрәтәбез.

Гаилә белән саф һавада йөрүне дә уенга, күңелле бәйрәмгә әверелдерергә мөмкин.

Әгәр сез балаларыгыз белән шәһәргә чыгарга җыенсагыз, иренмәгез, башта шәһәрегез турында үзегез берәр китап укып чыгыгыз. Йөргәндә, баланың игътибарын шәһәрегезнең кайбер истәлекле урыннарына юнәлдерү өчен бу сезгә менә дигән мөмкинчелек булыр. Балага шәһәр паркындагы агачларны кемнәрнең һәм кайчан утыртулары турында, әнә теге гаҗәеп матур өйне кем төзегән, шул турыда сөйлик. Шулай итеп, бала алдында без урамыбызның, шәһәребезнең бай йөзен ачабыз һәм баланың йодрык кадәр генә йөрәгенә бөек тойгы — патриотизм тойгысы булып шытып чыгачак бөртекне салып куябыз.

Бергәләшеп шәһәрдә йөргән вакытта, сүз уңаеннан, җәмәгать урыннарында балага үзен ничек тотарга тиешлеге турында аңлатырга мөмкин.

Постта торучы милиционерның эшен күзәтәбез. Узып баручы җәяүлеләрнең, машиналарның милиционер кулындагы тылсымлы күрсәткеч таякка һәм светофорның кызыл, сары, яшел утына ничек буйсынуларына игътибар итәбез.

Ә соңрак, инде өйгә кайткач, бала белән бергә, милиционер абый һәм урамда йөрү кагыйдәләре турында әкият уйлап чыгарабыз.

Паркка һәм якындагы урманга кызыклы походлар да оештырырга мөмкин. Елның теләсә кайсы фасылында биредә баланың игътибарын җәлеп итәрлек, аны йөзләгән сорау бирергә мәҗбүр итәрлек нәрсәләр бик күп. Җанлы табигать әкияттәгедәй бай. Ул безгә һәм балаларыбызга үзенең төсләр колоритын, кыңгыраулар чыңыдай җырын, күбәләкләрнең, көзге яфраклар яки ак кар бөртекләренең мәңгелек очып-биюләрен бүләк итә. Биредә табышмаклар, әкиятләр һәм уеннар өчен темалар адым саен!

Кайбер гаилә бәйрәмнәрен дә: Әбием көне, Дуслар бәйрәме, Яңа китап бәйрәме, Беренче чәчәкләр бәйрәме, Төсләр бәйрәме, Могҗизалар бәйрәмен үткәрүне дә традициягә әверелдерергә, ягъни даими үткәрергә тырышып карыйк. (Тагын бик күп темаларны, хөрмәтле укучыларым, сезнең фантазиягә калдырам.)

Әлеге һәр бәйрәмгә, өй эче көлеп торсын өчен, аны купшы киендерәбез. Ишек өстенә, стеналарга кызыклы шаян плакатлар язып эләбез. Кунакларга бүләккә кечкенә-кечкенә кызыклы сувенирлар әзерлибез.

Аларны ясауда малайлар да, кызлар да катнашсын. (Бу алар өчен һәрьяктан файдалы.)

Гаилә кичәсе яки гадәткә кергән чираттагы бәйрәм өчен уеннар: өстәл хоккее, крокет һ. б. бик отышлы. Башваткычлар әзерләү һәм аны кунаклар алдында чишү (балалар катнашында!) шулай ук кичәне күңеллерәк итә. Яраткан китаплардан өземтәләр әйтеп уен-табышмак итеп үткәрү кызыклы килеп чыгарга мөмкин.

Биредә үзебезнең хыялыбыз өчен дә, балалар хыялы өчен дә мәйдан киң. Мондый кичәләр бала өчен башкалар белән чираттагы күңелле һәм шатлыклы аралашу мөмкинлеге булып кына калмый... Мондый шартлар баланың иҗади фикере, аралашучанлыгы, инициативасы, уйлап табучанлыгы үсүенә уңай йогынты ясый.

Шуңа охшаш уеннарның гомуми тәрбияви әһәмияте гаять зур.

Болар балаларны кеше арасында, табын янында үз-үзләрен дөрес тотарга өйрәтә. Аларда оештыру осталыгын үстерә.

ӘДӘПЛЕ ЧЫРШЫ

Яңа ел — гаилә бәйрәме ул. Аңа безнең һәркайсыбызның үз мөнәсәбәте бар.

Әмма бу бәйрәмгә минем мөнәсәбәтем, кызганычка каршы, әрнүле тойгыларга барып тоташа. Һәр елның декабрь азагында гаять күп санда агач киселү уңаеннан (Мәскәүнең үзе өчен генә дә ел саен ун меңнәрчә чыршы киселә!), бу агачларның безнең өйләрдә 1—2 атна торганнан соң урамга чыгарып ташлануыннан туган тойгы ул.

Синтетик чыршы тирәли күңелле, кызыклы бәйрәм оештырырга бик мөмкин, өстәвенә, бу — табигатькә сакчыл караш турында балалар белән сөйләшү өчен менә дигән җай.

Чыршы бәйрәме буласы көнгә өегезне балаларыгыз белән бергә җыештырыгыз, бизәгез. Сезнең сабыегыз үзенең дусларына, чыршы бәйрәме буласы көнне һәм сәгатьне күрсәтеп, открытка-чакыру тапшырсын.

Бу вакытта Яңа ел чыршысы һәм шулай ук бәйрәм бизәкләре инде әзер була.

Кунаклар килешкә «Әдәплелек әлифбасы» геройларының Яңа ел маскаларын да әзерләргә мөмкин.

Ниһаять, кечкенә кунаклар килеп беткәч, аларны бүлмәгә чакырыгыз. Әлеге әкиятебезнең әчтәлеген сөйләгез һәм балаларның һәрберсенә үзләре теләгән маска сайларга булышыгыз.

Инде хәзер иң оста табышмак чишүчегә, иң оста әкиятчегә конкурс үткәрергә мөмкин. Сезнең, әлбәттә, табышмак-

ларыгыз һәм әкиятләрегез күптән әзер. Хәер, кунаклар үзләре теләгән әкиятне сөйли яки теләсә нинди табышмакны чишә алалар. Конкурста җиңеп чыгучыларга бүләкләр бирелә.

Уеннардан соң балаларны табынга чакырырга кирәк. Утырышып беткәч, Саумы фея яки акыллы-зирәк Гномнар балаларга әдәпле кеше мисалына кечкенә әкият-имтихан үткәрәләр. Имтихан өчен сорауларны сез 101 нче биттән таба аласыз.

Болардан соң кунакларга әдәпле качыш уены яки әдәпле күз бәйләш уены уйнарга тәкъдим итәргә мөмкин. Яисә аларны үзләренең якыннары өчен бик тиз генә Яңа ел бүләкләре ясап алырга күндерергә була.

Уйнатасын уйнатып, сый-хөрмәт күрсәткәннән соң, үз ихтыярыгыз белән, кечкенә кунакларыгызны, җылы сүзләр әйтеп, озатып җибәрсәгез дә ярый.

ӘТИ-ӘНИЛӘРГӘ КАЙБЕР ИСКӘРМӘЛӘР

1. Табын янына беркайчан да баш киемендә утырырга ярамый. (Бу кагыйдә хатын-кызларга да кагыла.)

2. Ризык капкан килеш сөйләшү — әдәпсезлек.

3. Сезнең балагыз табын янында тәртипкә һәм матурлыкка күнексен өчен, савыт-саба чиста һәм күркәм булырга тиеш.

4. Тәлинкәгә салганны ашап бетерергә кирәк. (Шуңа күрә балага ашап бетерерлек кенә салынырга тиеш.)

5. Ашны кашык белән ашыйлар. Кашыкны уң кулга тоталар (сул кул тезгә түгел, өстәл өстенә куела). Ашны ашап бетергәндә, тәлинкәне табын ягына янтайталар.

6. Турап пешерелгән итне, яшелчә, бәрәңге, макарон азыкларын чәнечке белән (пычаксыз), чәнечкене уң кулга тотып ашыйлар.

7. Зур кисәкле итне, пычак белән ваклап, чәнечке ярдәмендә ашыйлар. Бу очракта пычак — уң кулда, чәнечке сул кулда була.

8. Кәгазь салфеткаларны — махсус савытка, материядән тегелгән салфеткаларны тәлинкә янына куялар.

9. Ипине, кисеп өстәлгә тәлинкә яки ипи савытына салып бирәләр. Ипинең бөтен бер кисәген тешләп ашый башлаганчы, үзеңә кирәк кадәресен генә сындырып алу уңайлы.

10. Ашап бетергәч, чәнечке белән пычакны икесен янәшә, тәлинкәгә куярга кирәк. (Тәлинкәдә ризык калдыру килешми.)

11. Торт, пирожный яки кремлы башка татлы камыр ашларын кечкенә кашык белән ашыйлар.

12. Табын янында үзеңне матур, әдәпле тоту кагыйдәләре белән без балаларыбызны даими рәвештә таныштырып торырга тиешбез. Моны артык нечкәләнмичә һәм йөдәтмичә эшләргә кирәк. Биредә ата-ананың үз-үзен яхшы тотуы бала өчен иң яхшы үрнәк була.

АЛДАУ

Кояш йокысыннан уянды. Болытлар арасыннан башын сузды да кырыкмаса кырык тарафка кырыкмаса кырык нурын сибеп җибәрде... Биек прәннек манараларга менеп кунаклаган калай әтәчләр иртәнге әдәпле сүзләрен кычкырмакчы булып томшыкларын ачканнар иде... Әмма берни дә килеп чыкмады! Әтәчләрнең көчле-яңгыравык тавышын коточкыч явыз тылсымчы урлаган!

Менә ни өчен Әкият-шәһәр кешеләренең олысы-кечесе бу иртәдә йокысыннан уянмаган.

Саумы фея күзләрен ачканда, биек манарадагы сәгать төптөгәл уникене сукты.

— Әллә йоклап калганмын инде? — дип аптырады фея.— Гаҗәп!

— Тек-тек-тек! — текелдәде сәгать.— Әкият-шәһәрдә уйламаган-көтмәгән күңелсез хәл килеп чыкты... Ашык! Ашык! Ашык!

Пошаманга төшкән Саумы фея моннан ике йөз ел элек сөекле бабасы бүләк иткән тылсымлы күзәтү торбасын кулына алды. Биек манара очына менеп, уңга карады. Калай әтәчләрне күрде. Әтәчләр томшыкларын ачалар, әмма тавышлары чыкмый иде!

— Ай-яй-яй! — диде дә фея сулга карады.

Иң зур мәйдандагы әдәп-тәртип Сакчысы юкка чыккан иде!

— Ай-яй-яй! — диде фея. Алга карады. Шәһәр өстендә очып йөргән аждаһаны күрде.

— Ай-яй-яй-яй-яй-яй! — диде бу юлы фея.— Ничек? Ник? Каян? — Һәм, зонтигын ачып, үзе дә аждаһа артыннан очты.

Ун метр да китмәгәндер, елаган тавыш ишетте. Караса, үксеп-үксеп шат күңелле Хат ташучы елый икән. Шулкадәр каты елый, хәтта тирә-ягына күз яшеннән зур-зур күл җыелган. Ә күл читендә торараштай Кызчык-Бөтерчек басып тора.

— Бәла! Коточкыч явыз тылсымчы сихерләгән аны! Бәла! Бәла! Бәла!

— Кайгырмагыз, зинһар,— диде дә фея баш очында зонтын бөтереп алды.

Шунда Кызчык-Бөтерчек каршысына күл өстеннән әкияти башмаклар йөзеп килде.

— Рәхим итеп ал шуларны,— диде фея,— һәм исеңдә тот: аягыңда шушы башмаклар булганда, бернинди явыз тылсым да куркыныч түгел сиңа! Ә инде аларны киеп биесәң, сиңа карап башкалар да бии башлаячак.

— Рәхмәт...— диде Кызчык.

Гаҗәеп бәллүр башмакларны аякларына киеп куйды.

Тып итеп тыпырдап алды. Һәм... биеп китте! Аның шулкадәр матур, шулкадәр килешле биюен күргән шат күңелле Хат ташучының күз яшьләре шундук кипте. Ул да бии башлады. Шул тирәдән узып барган очар зонтлар Сатучы да, күмәчханәсенә ашыккан Күмәчче дә, остаханәсенә ооңаруына карамастан, Читекче дә... Әкият-шәһәрнең олысы-кечесе бии башлады. Хәтта Саумы фея дә кушылырга уйлап тора иде, кинәт бер тавыш ишетелде:

— Коткарыгыз!

Карасалар, аждаһа кычкыра икән.

— Шәһәребезгә аждаһа каян килгән?

— Тәңкәле!

— Койрыклы!

— Өч башлы!

Кызчык-Бөтерчек шунда:

— Бер малай ул, Алеша Иванов,— диде. Үзе, Алешаның кыланышларын исенә төшереп, кып-кызыл кызарды.

— Мөгаен, Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян эшедер бу,— диде фея.

— Әйе-әйе! Ул мине, чылбырга бәйләп, үз өен сакларга куймакчы була! — дип кычкырды аждаһа.— Ә минем саклыйсым килми! Яңадан малайга әверелсәм әверелермен! Әйе! Әйе!

Ул арада күк күкрәтеп, җир тетрәтеп Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян килеп җитте:

— Кии-кри-күүүк! Бу минем аждаһам! Ул бит инде бик күптәннән малай түгел иде! Ул бит гел әкияттәге чып-чын аждаһаларча кыланды! Шулай түгелме?

— Шулай...— диделәр олысы-кечесе һәм башкалар.— Кызганычка каршы, шулай шул. Әмма...

— Кии-кри-күүүк! Шым булыгыз! — диде тылсымчы.— Нинди «әмма» ул тагын! Алешаның гомерендә бер яхшылык та эшләгәне булмады. Беркайчан да өлкәннәргә урын, юл бирә белмәде. Нәниләрне рәнҗетте. Кош-кортка рогаткадан атты. Эт-мәченең койрыгыннан тартты. Хәтта әнисен, әтисен, ике әбисе белән түтиен дә кызгана белмәде! Йә? Кеше була аламы инде ул?

— Юк...— диделәр олысы-кечесе һәм башкалар, башларын иеп.— Кеше үзен алай тотмый, алай тотарга хакы юк...

— Ах! — дип кычкырды Алеша.— Алайса, мин сезгә ут бөрким, төтен бөрким! Үкчәләрегезне тешлим! А-ам!

Аннары шулхәтле зур итеп авызын ачты. Әкият-шәһәрдә яшәүчеләрнең котлары алынды. Алар кайсы кая качып беттеләр. Кечкенә аждаһа белән тылсымчы да, фея белән Кызчык-Бөтерчек кенә баскан урыннарыннан кузгалмады.

— Бик-бик-бик кызганыч,— диде фея, авыр сулап.— Ялгыз каласың, Алеша-аждаһа. Алай гына да түгел... Әгәр чын дустың булырга теләүче табылмаса, син инде яңадан беркайчан да кешегә әверелмәячәксең.

Шунда Кызчык-Бөтерчек аждаһага күз төшерде дә, авыр сулап:

— Мин аның дусты булам...— диде.

Аждаһа, койрыгын җиргә шап-шоп бәрә-бәрә:

— Кирәгең юк! — дип киреләнде.

— Кии-кри-күүүк! — дип кычкырып җибәрде тылсымчы.— Әдәп-тәртип Сакчысының да дуслары бар иде. Барыбер авырлыгын югалтты ул. Аннары билгесез тарафка очып китте!

Кызчык-Бөтерчек әкрен генә тагын кабатлады:

— Мин булам аның дусты.

Аждаһа авызыннан ут һәм төтен бөркеде:

— Сиңа ялынучы юк бит әле монда!

— Кии-кри-күүүк! — Тылсымчы кычкырып көлде генә.— Сезнең калай әтәчләрегезнең дә дуслары бар. Шулай да мин аларны тавышсыз калдырдым. Әйе! Әтәчләргә беркем дә ярдәм итмәде! Кии-кри-күүүк!

Кызчык-Бөтерчек ишетелер-ишетелмәс кенә тагын кабатлады:

— Мин булам аның дусты. Һәм Алеша яңадан кешегә әверелер.

Шулай диде дә, зуп-зур күлләвек аша бик җиңел сикереп чыгып, иске генә шоколад өйгә юнәлде. Анда аны пошаманга төшкән Хат ташучы көтә иде.

Алеша-аждаһа Кызчык артыннан кычкырып калды:

— Күргән бар безнең андый гына дусларны!

— Кии-кри-күүүк! — дип өстәде явыз тылсымчы.— Әниең, әтиең, ике әбиең белән түтиеңнең дә дуслары бар иде... Ә синең белән без барыбер аларны асфальттагы гап-гади рәсемнәргә әверелдердек... Ха-ха! Шулай булгач, син хәзер йөз ел аждаһа булып яшәячәксең! Ә мин... мин сине чылбырга бәйләп куям!

Моны ишеткәч, Алеша-аждаһа сулкылдап куйды, аннары елап ук җибәрде.

Моңа кадәр дәшми-тынмый игътибар белән тылсымчы һәм аждаһаны гына күзәтеп торган Саумы фея:

— Хәзер мине тыңлап карагыз инде,— дип сүз башлады.— Әкияти сүз бирәм: манарамдагы сөйләшә торган сәгать төп-төгәл уникене сугуга, явыз тылсымнарыгызның барысы да юкка чыгачак. Ә кечкенә аждаһа, өч яхшылык эшләсә, яңадан кешегә әвереләчәк.

— Кии-кри-күүүк! — диде тылсымчы.— Бик ихтимал...

Саумы фея бик-бик-бик беркатлы, ә Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян коточкыч хәйләкәр һәм мәкерле иде. Шуңа күрә феяне алдау юлын да тиз тапты:

— Эһем-эһем... Ихтимал, бераздан мин үзем дә төзәлермен әле биредә... Мәрхәмәтле әкият тылсымчысына әверелермен... Шулай булуы бик мөмкин... Шулай яки бөтенләй киресенчә! Кии-кри-күүүк! Мин сезне бик ошаттым, сөйкемле фея! Хәтта сезнең белән бергәләп гаҗәеп фонтан яннарыннан әйләнеп килергә дә ризамын.

...Ләкин, тылсымлы зонтигын ачарга дип фея читкә борылуга, Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян аны бик тиз-җитез генә баштанаяк тылсымлы төнәтмәгә коендырды. Шуннан Саумы фея тирән йокыга талды!

— Ул шулай мең ел йоклаячак! — дип пышылдады аждаһаның колагына явыз тылсымчы.— Шым бул! Киикрикүүүк! Ә хәзер... Хәзер мин фонтанны томалап куям. Тылсымлы таш белән...

Аннары ул феянең шоколад медален алып ашады, ә үзен биек манарадагы бүлмәсенә илтеп салды. Манара ишекләрен тылсымлы сүзләр белән генә ачыла торган йөз йозакка бикләде. Сөйләшә торган сәгатьне дә кабып йотты.

Яңгыравык өтәч тавышы белән кычкырып җибәрде:

— Кии-кри-күүүк! Сөйләшә торган сәгать хәзер инде уникене сукмас! Шәфкатьле феяне хәзер инде беркем дә уята алмас! Аждаһа яңадан беркайчан да малайга әверелмәс! Әкият-шәһәрнең олысы-кечесе һәм башкалар әдәпсезлек авыруы белән авырый башлар! Кии-кри-күүүк! — Тылсымчы, аждаһа янына очып килеп, аның муенына чылбыр кигезде. (Берәр явызлык эшләмичә минут та түзә алмый иде шул ул.)

Фея сорау бирә:

1. Ни өчен фея борчуга төште?

2. Әкият-шәһәрдә нинди үзгәрешләр булды? Моңа кем гаепле?

3. Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян намуслы тылсымчымы, түгелме?

4. Ә син, дустым, иптәшләреңә һәрвакыт дөресен генә сөйлисеңме? Синеңчә ничек: алдашу әдәплелекме, түгелме?

НАМУСЛЫ БУЛУ НИГӘ КИРӘК?

«Намуслылык», «намус» белән бергә «чисталык», «сафлык» сүзләре дә йөри. Шулай бит, дустым?

Намуслы дип без хәйлә, куркаклык һәм ялган белән үзен пычратмаган кешене әйтәбез.

Намуслы кеше ул — туры сүзле һәм кыю кеше. Дуслыкның кадерен белә торган, якыннарын, таныш-белешләрен һәм хәтта таныш түгел кешеләрне дә хөрмәт итә, ярата торган кеше.

Әдәпле-намуслы кеше соңыннан оят булырдай, ата-аналарына, дусларына сиздерергә ярамаган эшләрне эшләмәскә тырыша. Чөнки алардан яшереп эшләгән эш икейөзлелек, хәйләкәрлек булыр иде. Ә икейөзлелек, хәйләкәрлек кешене алдашырга һәм куркаклыкка өйрәтә.

Менә шуңа күрә дә әдәпле-намуслы кеше соңыннан сөйләп дусларын шатландырырдай, аларның күңелләрен күтәрердәй эшләр генә эшләргә тырыша.

Андый кеше дусларының уңышын күреп үзе дә шатлана белә һәм беркайчан да, беркемнән дә көнләшми. Берәрсенә яңа велосипед яисә футбол тубы алганнар икән — бигрәк әйбәт! Димәк, сезнең ишегалдында тагын да күңеллерәк булыр... Сиңа шундый туп я берәр уенчык алсалар да бик әйбәт. Димәк, дусларың белән бергәләп яңа уеннар уйнарга була.

Әдәпле һәм намуслы кеше әти-әнисе, әби-бабасы хезмәтенең дә кадерен белә, ихтирам итә. Үзе дә эш сөя.

Өй җыештыру, ашарга пешерү, кибеткә бару, фатирга ремонт ясау яисә бәйрәмгә чыршы бизәү кебек эшләрне өлкәннәр генә эшләсә, бу дөрес булмас иде.

Өйдәге эшләрнең барысын да өлкәннәр генә эшләсә, малайларга-кызларга дөньяда яшәүнең кызыгы калмас иде. Балаларның да куллары бар бит. Бу куллар оста булырга, эш белергә тиеш. Алар да хезмәт итәргә тиеш.

Шуңа күрә һәрбер әдәпле малай һәм кызның өйдә үзе башкара торган даими эше була. Әгәр дә әти-әниең, әби-бабаң яисә өлкәннәрдән бүтән берәрсе әле сиңа бер мөһим эш тә кушмаганнар икән, зинһар бу хакта аларның исләренә төшер, кечкенә дустым.

Ә инде көн дә башкара торган эшләрең булса, яхшы итеп һәм вакытында башкарырга тырыш. Гадел итеп...

Өй җыештырганда ялгыш берәр чынаяк ватсаң яки варенье-фәлән түксәң дә яшермә. Гаебеңне башкаларга сылтый күрмә. Дөресен сөйләп бир, һәм ялгышың өчен гафу үтен.

Намуслы кешегә һәрвакыт таянырга була. Шуңа күрә андый кешене барысы да хөрмәт итә, аңа ышаналар.

Әдәпле, намуслы кеше берәр иптәшенең китабын алып торса (вакытлыча, укырга гына), аны вакытында кайтарып бирә. Китапны ертмый да, пычратмый да.

Әдәпле, намуслы бала, иптәшләренә кунакка килергә вәгъдә бирсә, нәкъ билгеләнгән вакытка киләчәк. Соңга калу — ямьсез гадәт. Әгәр дә ниндидер сәбәпләр белән килә алмыйсың икән, ул чагында алдан хәбәр итәргә тырыш. Йә, һич тә булмаса, дусларыңнан беренче очрашуда ук гафу үтен.

Һәрвакыт әдәпле һәм намуслы булырга тырышкан кешедә тора-бара көчле ихтыяр һәм ныклы характер тәрбияләнә. Андыйлар турында:

— Бу кеше үзен-үзе тәрбияли ала,— диләр.

Тәрбияләү бер дә җиңел эш түгел. Хәтта бик-бик акыллы дельфиннар һәм бик-бик яхшы филләр дә моны эшли алмый. Аның каравы чын кешеләр гомер буена үз-үзләрен тәрбиялиләр, һәм моны алар бала чактан башлыйлар. Әйе-әйе! Нәни дустым! Нинди дә булса берәр малай яисә кыз һәммә җирдә, һәрвакыт намуслы, әдәпле һәм шәфкатьле булырга бөтен көченә тырыша икән,— димәк, бу бала инде үз-үзен тәрбияли башлаган. Киләчәктә анда, һичшиксез, көчле ихтыяр һәм ныклы, кыю холык тәрбияләнер.

Әгәр дә син, нәни дустым, үзеңдә ихтыяр көче һәм яхшы холык тәрбияләргә телисең икән, менә сиңа берничә киңәш:

1. Тәртипле һәм пөхтә бул. Кирелеккә һәм башка шундый ахмак эшләргә вакытыңны әрәм итмә.

2. Көчле һәм җитез булыр өчен, көн саен иртән зарядка ясა. (Көтмәгәндә берәр кызны яки көчсез нәни малайны сугыш чукмарыннан якларга туры килүе бар бит. Моның өчен син көчле булырга тиеш.)

3. Танышларың белән дә, таныш булмаган кешеләр белән дә үзеңне һәрчак әдәпле һәм яхшы тот.

4. Автобус, трамвай һәм башка транспортта үзеңнән өлкәннәргә яисә талчыккан, авыру кешеләргә һәрвакыт урын бир.

5. Иптәшләреңне дә, өлкәннәрне дә бервакытта да алдама. Куркаклар һәм тәрбиясезләр генә алдаша йә хәйләли. Алар кебек була күрмә.

Әгәр дә син миңа:

— Юри генә, бернинди куркусыз, бернинди хәйләсез, болай гына ялган уйлап чыгарасы, алдалап карыйсы килә! Хыялланып карыйсы! Дусларымның күңелен ачу өчен генә! Көләр өчен генә! — дисәң, мин:

— Рәхим ит,— диярмен.— Уйлап чыгар. Андый яхшы ниятле, әкияти дип әйтерлек ялган уйлап чыгару бөтен кеше өчен дә бик файдалы. Әйе-әйе! Чөнки әкиятләр, күңелле хикәяләр һәм балалар спектакльләре шулай туа.

Андый уйлап чыгаруның исеме дә бик матур: «фантазия».

Шулай булгач, рәхим ит, рәхәтләнеп уйлап чыгар, хыяллан, кечкенә дустым. Үзең генә дә хыяллана аласың. Дусларың белән бергәләп булса — тагы да әйбәтрәк.

Телисең икән, мин сиңа Шат күңелле хыялыйлар бәйрәмен оештыру һәм үткәрү турында сөйлим.

ШАТ КҮҢЕЛЛЕ ХЫЯЛЫЙЛАР БӘЙРӘМЕ

Син инде, берничә әдәплелек дәресен укып чыгып, ул дәресләрнең барлык күнегүләрен дә эшләдең: бүлмәңне җыештыра, әбиең яки әниең белән бергәләп кунаклар өчен бәйрәм сые әзерли аласың.

Менә кемдер ишек шакый. Мөгаен, кунаклардыр...

Тамчы да шикләнмим: син аларны якты чырай белән каршы алырсың. Һәрберсе белән әдәпле генә исәнләшерсең. Кызларга куртка, пальтоларын салырга ярдәм итәрсең. Бүлмәгә дә аларны алдан кертерсең.

Аннары кунакларыңның һәрберсенә алдан әзерләнеп куелган кайчы, буяулар, кәгазь, җилем, карандашлар бирерсең. Һәм иптәшләреңә әкиятнең төп геройларының рәсемнәрен күрсәтерсең.

1 нче күнегү. Рәсемнәрдәге әкият геройларын игътибар белән карагыз. Калын кәгазьгә аларның маскаларын ясагыз. (Бу эштә өлкәннәрдән берәрсе ярдәм итсә, бигрәк тә яхшы. Алар масканың зурлыгын, нәрсәне кая ябыштырырга икәнен күрсәтер.) Төп геройлар өчен костюмнар уйларга мөмкин. Мәсәлән, феягә калфак, күзлек кирәк булачак. Хыялыйлар өчен бу авыр эш түгел.

Маскалар әзер булгач, аларны киеп, безнең әкияттән берәр өзекне уйнап карарга мөмкин. Тик элек син дусларыңны көтмәгәндә аждаһага әверелгән Алеша исемле малайның тарихы белән таныштырырга тиеш буласың. Аны балаларга сөйләп кара. Бу эштә сиңа өлкәннәрдән кемнең дә булса, шулай ук китаптагы рәсемнәрнең ярдәме тияр дип ышанам.

Алеша Ивановның әкияти аждаһага әверелү сәбәбен кунакларыгызга

аңлатырга тырышып карагыз. Йә бу вакта барыгыз бергәләп уйлагыз.

Аннары кемнең аждаһа буласын хәл итегез. Кем Кызчык-Бөтерчек булыр? Кем — фея? Ә кем коточкыч явыз тылсымчы Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян булыр?

Хәзер әкият битлекләрен киегез дә чиратлашып бу әкиятне үзегез белгәнчә сөйләп карагыз. (Монда да өлкәннәр бераз ярдәм итсә, бигрәк тә яхшы булыр.)

2 нче күнегү. Инде әкиятнең эчтәлеген беләсез. Хәзер хыял көче белән хәл итегез: яңадан малайга әверелер өчен, кечкенә аждаһа нинди өч яхшылык эшли ала? Аның урынында сез булсагыз, ниләр эшләр идегез? Аңа яхшылыклар эшләргә кем һәм ничек ярдәм итә? Кем комачаулый? Ни өчен комачаулый? Сезнеңчә ничек: Алеша-аждаһа яңадан кешегә әверелә алырмы, юкмы?

3 нче күнегү. Дусларыгыз белән бергәләп шушы әкияткә рәсемнәр ясап карагыз.

Монда инде мин сезгә берни дә өйрәтмим. Ясагыз! Рәхәтләнеп хыялланыгыз!

4 нче күнегү. Үзең яисә дусларың белән бергәләп әкият уйлап чыгарып сөйлә. (Әти-әниең, әбиең яисә өеңдәге башка кешеләр дә — синең дусларың, уенда аларга да катнашырга ярый.) Темасын әйтә алам: иң әдәпле йорт турында әкият.

БАЛАЛАР НИГӘ ЯЛГАНЛЫЙ?

(өлкәннәр белән сөйләшү)

Балаларның ялганлавы безне борчый, ачуыбызны чыгара, аптыраштa калдыра, ә кайчакларда көләсене дә китерә, шулай бит, хөрмәтле ата-аналар? Мондый хәлләрдә без нишләргә тиеш соң? Әле генә ялганлаган балага җәза бирергәме? Алдашуның көчсезлек, куркаклык һәм башка начар сыйфатлар билгесе икәнен тагын бер тапкыр аңлатып карарргамы? Әллә, ялганы тотылганны яшермичә, бала белән бергәләп көләргәме?

Ә бит сабыйның алдашу сәбәпләреннән иң зурысы — аның өлкәннәргә ышанып җитмәвендә. Бала ялгыш эшләгән нинди дә булса ярамаган эше өчен өлкәннәр җәза бирер дип курка, шуңа күрә алдалый. Бала күңелендәге бу курку бер сәбәпсез тумый. Моңа без, өлкәннәр, гаепле.

Сабыйга җәза бирергә бик ашыкмыйбызмы икән без? (Имештер, бер-ике тапкыр суккалап алганнан берни дә булмас. Баланың сәламәтлегенә дә зыян килмәс... Аның каравы икенче тапкыр ярамаган эш эшләмәс.)

Тән җәзасының бернинди дә, хәтта иң җиңеле дә бала тәрбияләүдә яхшы чара булып исәпләнми. Кеше күңелендә курку тәрбияләргә ярамый. Ә тән җәзасы кебек чаралар балаларда мескенлек, кимсенү, тигезсезлек хисе тудыра.

Җәзадан курку күп очракта баланы ярамаган эш эшләүдән тыеп кала алмый. Өлкәннәрне алдарга, боргаланырга, хәйләләргә генә мәҗбүр итә.

Бу мәсьәләдә безгә, өлкәннәргә, ихтимал, кат-кат уйланырга, үзебезгә тагын да таләпчәнрәк булырга кирәктер. «Яра-

мый» дигән сүзне артык еш әйтмибезме? Сау-сәламәт баланың кызыксынучан, күпне белергә омтылучан, хәрәкәтчән һәм тиктормас булырга тиешлеген онытып җибәрмибезме? Бала, үзе аяк баскан дөньяның серләренә төшенү өчен, һәрвакыт, һәр җирдә тикшеренергә, сынап, тәҗрибәләр ясап карарга тиеш бит.

...Балалар ялганлавының икенче сәбәбе — сабыйның үз шәхесен расларга омтылуында. Мондый гайре табигый омтылыш кайчакларда өлкәннәрнең балага карата педагогик булмаган мөнәсәбәтеннән килә. Кайчакларда без балаларның йомшаклыгыннан, кыюсызлыгыннан, куркаклыгыннан көләбез. Сабыйга, ирония белән: «син бигрәк куркак инде!», «бер дә көчең юк икән синең!» кебек сүзләр әйтәбез, аны кайбер яклардан өстенрәк бүтән балалар белән чагыштырабыз. Шулай итеп кечкенә кешенең шәхесен кимсетәбез.

Андый хәлләрдә бала, үрнәк итеп куелган башкалардан көчлерәк тә, әдәплерәк тә, кыюрак та була алмагач, булмаган яхшы сыйфатларын да бар дип, үзен яхшырак итеп күрсәтергә тырыша. Һәм шундый ситуацияләр уйлап чыгара, имештер, ул анда гаҗәеп-искиткеч батырлыклар күрсәткән.

Мондый очракларда безгә, өлкәннәргә, мөгаен, баланың ялганын фаш итмәскә, ә сабыррак булырга, яхшы эшләре өчен аны ешрак мактарга, тырышлыгына күбрәк игътибар итәргә, сабыйда үзебез күрергә теләгән сыйфатларны булдыру юлларын эзләргә кирәктер. Курыкмаска... Бергәләп шундый әкият-вакыйгалар уйлап чыгарырга кирәк: аның төп герое безнең сабыебыз булсын һәм ул көчлелеге-кыюлыгы белән кешеләрне таң калдырсын. Җае чыккан саен балада үз-үзенә, үзенең мөмкинлекләренә һәм көченә ышаныч тәрбияләү зарур.

...Бала ялганының тагын бер варианты — якыннарын, әти-әниләрен, туганнарын һәм дусларын чынбарлыктагыдан яхшырак итеп күрсәтергә тырышу. Бер кызның искитмәле әтисе турындагы уйдырма-хыялын үземнең ишеткәнем бар: аның әтисе, имештер, түбәсен күккә терәтеп биек йорт салган... Парашют белән Африкага очкан... Кызына сөйләшә торган попугай бүләк иткән. Бу — сабыйның хыялда гына күз алдына китерә ала торган гаҗәеп әтисе турындагы беркатлы уйдырма-әкияте иде. Аның чынбарлыктагы әтисе исә — эчкече, гаиләсенә күп кайгылар китергән кеше.

Бәхеткә каршы, ата-аналарның күпчелеге андый түгел. Ә шулай да... Шулай да, ихтимал, балаларыбызның өлкәннәр өчен башка тормыш, башка мөнәсәбәтләр, башка гамәлләр һәм характерлар уйлап чыгарырга тырышуы тикмәгә генә түгелдер? Ихтимал, хакыйкатькә төшенү өчен, балаларның бу уйдырмаларына безгә дә колак салу тиештер? Һәм бу очракта безгә, мөгаен, балаларны түгел, ә үзебезне яңадан тәрбияли башларга кирәктер? Яисә, сабыйлыклары һәм аңлап бетермәүләре сәбәпле, кызларыбыз һәм малайларыбыз безнең нинди дә булса эшләребезгә дөрес бәя бирә алмаганнар икән, бала белән тыныч кына сөйләшергә, бу очракта нәрсәне ничек аңларга икәнен төшендерергә кирәк.

Балалар уйдырмасының өченче варианты да бар. Бу — ачыктан-ачык уен, бирелгән темага яисә бөтенләй берниндн темасыз-нисез фантазия.

Димәк, бала бик тере, күпне белергә омтылучан. Аның бу бик яхшы сыйфатын китаплар укып, театрларга йөреп, бергәләп уйлап чыгарган уеннарны уйнап хупларга, үстерергә кирәк. Әгәр дә инде уйлап чыгару, хыял дигән әйберләрне әллә кайчан онытып бетергән булсак (кызганычка каршы, дусларым, алай да була!), бу файдалы сыйфатны (һәрхәлдә, тәрбия эшендә) бик тиз генә үзебездә яңадан булдыру ягын карарга кирәк. Бу сыйфат безне яраткан улларыбыз һәм кызларыбыз белән якынайтып кына калмас, ә бөтен сәнгатьнең нигезендә яткан шул «матур уйдырманы», кайчакларда шуклыктан, юмор хисеннән, тормышны озаклап күзәтүдән туган зирәклекне ачыграк, тирәнрәк, җитдирәк аңларга ярдәм итәр.

Ә сәнгатьнең теләсә кайсы төренең (шул исәптән балалар иҗатының да!) гаять зур тәрбияви әһәмияте бәхәссез.

УРМАНДА ӘДӘПЛЕЛЕК ДӘРЕСЛӘРЕ

Әкрен генә ишек шакыдылар.

— Гафу итегез,— диде малай-Гном, башын тыгып.— Сез бик арыгансыз бугай?

— Күрәсеңме, дустым, акыллы-зирәк Гномнар әдәпсезлек авыруыннан савыгып киләләр инде. Хәзер алар барлык өлкәннәргә һәм танышларына «сез» дип мөрәҗәгать итәләр.

— Рәхим итегез! Хәзер барыбыз бергәләп урманга китәбез...— Мин тылсымлы таягымны селтәп җибәрүгә, барыбыз да урманда идек инде.

— Каррр! Каррр! Хәерле көн! — дип каршылады безне шул арада килеп тә җиткән әдәпле-акыллы карга.— Киңәшләремә колак салыгыз әле. Карр! Карр! Зинһар, урманда кычкырышмагыз, шаулашмагыз. Чәчәкләрне өзмәгез, агач ботакларын сындырмагыз. Урмандагы җәнлекләрне куркытып рәнҗетмәгез. Шунда гына урман сезгә барлык сер-могҗизаларын ачар! Каррр! Каррр!

Әлбәттә, без аның киңәшләрен истә тоттык. Һәм иңгыр белән кояш

иҗаты — күзге урман — безгә куенын ачты.

Әйтерсен лә ул каядыр оча иде. Чыршылар да йонлач тәпиләрен селкеп:

— Сау булыгыз! — диләр.

Казлар-аккошлар да кычкыра:

— Га-га-га! Хушыгыз, игелекле кешеләр! Киләсе елга кадәр! Язга кадәр хушыгыз! Зинһар өчен, без югында урманны саклагыз! Монда кыш чыгасы җәнлек-кошларга утлыклар, җимлекләр ясагыз! Га-га-га! Урманга килгәндә, бераз ярма, кишер, сохари, кәбестә яфраклары да алырга онытмагыз! Урмандагы дусларыгызны онытмагыз!

Ялгышып та, юри дә кырмыска ояларын туздыра күрмәгез! Югыйсә кырмыскалар, салкыннар башланганчы өйләрен төзәтеп бетерә алмыйча, һәлак булырлар. Матур алтын-сары яфраклары өчен генә агач ботакларын сындырмагыз. Ә кышын... Зинһар, Яңа елга чыршыларны һәлак итмәгез. Яңа ел — башкалар өчен бәйрәм булса, чыршылар өчен ачы хәсрәт. Кызганыгыз аларны!

Казлар-аккошлар очып китте. Акыллы-зирәк Гномнар һәм мин, киселгән агач төбенә утырып, уйга калдык...

Син дә безнең белән утырып уйла, кечкенә дустым.

Без — өлкәннәр дә, балалар да — дустыбыз урман турында бик аз кайгыртабыз. Агачлар һәм чәчәкләрне сирәк утыртабыз. Уйлап та тормыйча, үләннәрне таптыйбыз. Соңыннан тартмаларга ябып һәлак итү өчен генә чикерткә һәм күбәләкләр тотабыз. Ә бит чикерткәләр чебен-черкиләрне ашый. Димәк, алардан безне, кешеләрне, саклый... Күбәләкләр, шөпшә һәм бал кортлары (чебеннәр дә!), һәрбер, хәтта иң нечкә ботакта да орлык өлгерсен өчен, чәчәкләрне серкәләндерә. Димәк, яз саен, җәй саен ак ландышлар һәм алтын нәүрүзләр, аксыл шәмәхә умырзаялар һәм зәңгәр күкчәчәкләр күреп сөенүебез белән без аларга бурычлы...

Агачлар, үләннәр, нәни генә урман инеше һәм чәчәкләр арасындагы тар сукмак — боларның барысын да безгә урман бүләк итә. Ул бик игелекле. Әгәр дә син йөри торган урманны начар кешеләр таптап, сындырып, азаплап бетермәгән булсалар, ул әле учлап-учлап төрле-төрле җиләкләрен дә, куян кымызлыгын да бирер. Шаян усак гөмбәсенең дә, көтмәгәндә очрап, әкрен генә (теләсә кемгә ишетелерлек итеп түгел!):

— Исәнме! — диюе бар.

Урманны тыңлый белергә, аның могҗизаларын күрә белергә, анда үсүче-яшәүче бар нәрсәгә карата мәрхәмәтле булырга кирәк...

УРМАН УЕННАРЫ

1. Йәле, әйтеп кара! Безнең китапта нинди агач һәм куак яфраклары ясалган? Урманда шул агачларны табарга тырыш. Һәр агачтан иплəп кенә берәр-икешәр яфрак ал. Аларны китап арасына куеп киптер. Альбом битләренә ябыштыр. Дусларыңа күрсәтерлек гербарий килеп чыгачак.

2. Хәтереңдә тот! Зинһар 76 нчы биттәге чәчәкләрне игътибар белән кара. Исемнәрен хәтереңдә калдыр, шундыйларны урманнан эзләп тап. Рәсемнәрен ясарга тырыш. Икенче очрашуыңда инде үзеңә таныш чәчәкләргә: «Хәерле көн!» — дип әйтә аласың.

3. Беркайчан да тотма! Күбәләк, чикерткә, вак күбәләк, коңгыз һәм башкалар урманда синең белән минем күзләргә рәхәтлек биреп кенә калмый, файда да китерәләр. Чәчәкләрне серкәләндерәләр. Кырмыскалар урман-болыннарны чистарталар.

Шуңа күрә, зинһар өчен, бервакытта да аларны газаплама. Урман бөҗәкләрен, чебен-коңгызларны иректә күзәтү кызыклырак. Соңыннан алар турында хәтта әкиятләр дә уйлап чыгарырга була.

4. Рәхәтләнеп сыйлан! Урман җиләкләренең һәм башка тәмле җимешләрнең кайберләрен, мөгаен, беләсеңдер инде. Башкаларын өлкәннәр күрсәтер.

Иптәшләрең яисә әти-әниең белән урманга баргач, тирә-ягыңа игътибар белән күз сал әле. Яфрак яисә куак астында кып-кызыл каен җиләгеме, кура җиләгеме, йә башка җиләкме күрсәң, ана, рәхәтләнеп сыйлан!.. Тик соңыннан кунакчыл урманга тәмле сые өчен: «Рәхмәт, урман!» — диергә онытма.

ӨЛКӘННӘРГӘ БЕРНИЧӘ СҮЗ

Әгәр дә без, өлкәннәр, үзебез табигатькә мәрхәмәтле булырга өйрәнмәгәнбез, аны сакламыйбыз, урман, болын, паркларга кулланучылар буларак кына карыйбыз икән, аңа кешелекле, яхшы мөнәсәбәтне балаларыбыздан да таләп итә алмыйбыз.

Тәрбияле, әдәпле кеше үзен ничек тотарга тиеш соң? Шуны начаррак хәтерле кайбер әти-әниләр, әби-бабайлар, абый-апаларның исләренә төшерергә рөхсәт итегез.

1. Андый кеше, суын эчеп карар өчен генә, язын каеннарны кискәләп «елатмас».

2. Тәрбияле кеше агач ботакларын, куакларны сындырмый, урмандагы чәчәкләрне кочак-кочак өзми. Үлән катламы урманның дымын саклый, бик күп файдалы бөҗәк һәм вак җәнлекләргә сыенырр урын бирә.

Кыр чәчәкләреннән җыйнак кына букетны чабыласы болыннан да җыярга мөмкин. Ә туй чәчәге, энҗе чәчәк, кызыл һәм сары умырзая кебек юкка чыгып баручы кайбер чәчәкләр бөтенләй кагылгысыз санала.

3. Таныш булмаган гөмбәләрне яисә агулыларын тибеп-таптап китәргә ярамый. Аларның бик күбесе урманда яшәүчеләр өчен дару булса, аерым-аерым һәркайсы — табигатьнең чираттагы могҗизасы. Кайчакларда эти-әниләр һәм әби-бабайларның үзләренә дә бу матурлыкны күрергә өр-яңадан өйрәнү кирәк була.

4. Урмандагы җәнлек һәм кошларны тотып өйгә алып кайтырга ярамый. Алар уенчык түгел. Безнең шулай «юануыбыз» урман җәнлекләренә, кош-кортларга авырулар, газап һәм үлем китерә.

5. Һәм, әлбәттә инде, урманга яки болынга ял итәргә чыккан әдәпле кеше үз артында пычрак целлофан, кәгазь, бушаган консерв банкалары өеме калдырмас.

Чөнки бу — чын мәгънәсендәге культурасызлыкның ап-ачык мисалы, җирне ихтирам итмәү, анда яшәүче кешеләрне бөтенләй санга сукмау булыр иде.

...Хөрмәтле эти-әни, әби-бабай һәм абый-апалар! Табигатьне яратуыгыз, саклавыгыз, матурлыгын күрә белеп, аннан шатлык алуыгыз һәм, табигый инде, шушы сыйфатларыгызны балаларга да күчерүегез сәбәпле, сезгә бу искәртмәләремнең кирәге чыкмаса, мин бик-бик шат булыр идем.

АЖДАҺА САТАМ!

Чылбырга бәйләнгән бик-бик-бик бәхетсез Алеша-аждаһа, коточкыч ямансулап, күңелсезләнеп, тавык тәпиләрендәге өйне саклый.

Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян аңа тәрәзәдән кычкырынгалап тора:

— Кии-кри-күүүк! Нәрсә тагын койрыгыңны салындырдың, аждаһа? Узган-барганнарның үкчәләрен тешлә! Аларга утлы төтен бөрке! Ха-ха-ха!

Әмма бик күптәннән инде бу әкияти өй яныннан узучы да, аждаһага сүз кушучы да, аның белән уйнаучы да юк. Көндезләрен соры болытлардан соры яңгыр ява да, төннәрен җилекләргә үтеп әче җил исә. Хәзер инде ул әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтие белән кайчандыр яшәгән җылы өен бик еш сагына.

— Алар мине ярата иде,— дип авыр сулый аждаһа.— Ә уенчыкларым, буяуларым, карандашларым никадәр иде!.. Бер дә саклап тотмадым шул... Бигрәкләр дә ахмак булганмын икән!

Кайчакларда ул әкрен генә елый иде.

Әмма, елый башладымы, шундук коточкыч явыз тылсымчы тәрәзәдән кычкыра:

— Нәрсә боектың? Ник эшсез утырасың? Узган-барганнарны тешлә әйдә! Киикрикүүүк!

Чылбырда утырып өй саклаудан һәм Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның ахмак боерыкларыннан тәмам туйган Алеша, ниһаять, әйтә куйды:

— Тешләмим. Тешләргә теләмим.

Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян ачуыннан бүртенеп чыкты:

— Минем өемне сакларга теләмисеңме? Узган-барганнарның үкчәләрен тешләп, аларга утлы төтен бөркергә теләмисеңме? Кии-крикүүүк! Алай булса сатам мин сине!

Һәм усал тылсымчы аждаһаны базарга алып китте.

...Чылбырын чыңлата-чыңлата боегып кына сөйрәлүче Алеша урам-тыкрыкларны танымады.

Хәзер инде Әкият-шәһәр чыннан да танымаслык булып үзгәргән: коточкыч явыз тылсымчы олысы-кечесенә һәм башкаларга әдәпсезлек авыруы йоктырган иде!

Менә ни өчен аларның берсе дә очрашканда исәнләшми, ә аерылганда саубуллашмый икән!

Урамнарда чүп-чар өелеп ята.

Чат саен өлкәннәр белән балалар кычкырыша.

Көчлерәкләр көчсезләрне рәнҗетә.

Автобуста яки трамвайда өлкәннәргә урын бирүче юк.

Малайлар белән кызлар үзара тату да, дус та түгел.

...Этләренә кадәр иртәдән кичкә кадәр өреп утыра. Ә йонлач көчекләр узган-барганнарның аягын тешләп кала.

Хәтта чыпчыклар да сугыша!

Гаҗәп хәл, Әкият-шәһәрдәге барлык могҗизалар кинәт кенә юкка чыккан.

Шоколад йортлар әкренләп гади соры ташка, ә конфет түбәләр гади чирәпкә әверелгән. Тәрәзәләрдәге крендель капкачлар да әллә кая киткән.

Алай гына да түгел... Шәһәрнең барлык осталары, Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның явыз теләгенә буйсынып, менә диган һөнәр-

ләрен онытып-югалтып бетергәннәр! Шуңа алар бик нык кайгыралар иде.

Остаханәсендә Читекче ухылдап утыра. Күмәчханәсендә Күмәчче ахылдый. Бәләкәй генә өендә боек Хат ташучы ай-вай килә. Очмый торган зонтлар Сатучы гырлап-мышнап утыра. Хәзер инде ул яшел бакчадагы эскәмиядә көннәр буена йоклый.

Бары Хат ташучы кызы Бөтерчек кенә элеккеге кебек: әдәпле, шәфкатьле, уңган, пөхтә. Ләкин Әкияти-әдәпсез шәһәрдә аңа да күңелсез. Ул еш кына тәрәзә янына килеп утыра да:

— Ничек итеп шәһәребезгә элеккеге могҗизаларны кире кайтарырга соң? — дип баш вата.— Кем белән киңәшләшим? Кем ярдәм итә алыр икән миңа? — дип уйлана.

Тәрәзә каршындагы иң зур мәйданда хәзер базар. Анда сатарга дип кыска койрык куяннар, алтын-сары тиеннәр һәм төлкеләр, ике чал бүре, хәтта ике баласы белән бергә юаш Аюнисаны да китергәннәр. Аларны Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян фәрманы белән урманнан мәрхәмәтсез аучылар, тотып, читлекләргә ябып куйганнар. Мескен җәнлекләр ачы күз яшьләрен түгәләр иде.

Әмма Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян менеп кунаклаган баганага тимер чылбыр белән бәйләп куелган аждаһа барысыннан да катырак елый.

— Кии-кри-күүүк! — дип кычкыра коточкыч явыз тылсымчы.— Аждаһа сатам!

Әкияти-әдәпсез шәһәрнең олысы-кечесе аждаһа тирәсенә өелешкән.

Малайлар аңа таш ыргыта.

Кызлар койрыгыннан тарта.

Кемнәрнеңдер әбиләре тәпиенә баса.

Кемнәрнеңдер бабайлары телләрен чыгарып үчекли.

Ә кемнәрнеңдер әтиләре һәм әниләре аждаһага усал-усал сүзләр әйтә:

— Мондый аждаһаның кемгә кирәге бар?!

Мәйданга Читекче килгәнче, аждаһаны кызганучы да, сатып алырга теләүче дә булмады. Читекче, кесәсеннән акча янчыгы чыгарып, тылсымчыга сузды. Чылбырны чишеп, боерды:

— Киттек, аждаһа!

Остаханәсенә алып керде дә тылсымлы әкияти аждаһага болай диде:

— Әгәр дә әкияти йөгерек башмаклар тегеп бирсәң, сине

ireккә җибәрермен. Чөнки мин шул чагында гына гаҗәеп осталыгымны исемә төшерәчәкмен...

— Минем беркайчан да берни дә теккәнем булмады! — дип җавап бирде аждаһа.— Мин тегә белмим!

— Андый хәлнең булуы мөмкин түгел,— дип, Читекче аждаһаның кулына без, җеп, пычакише нәрсәләр тоттырды. Ә үзе караватка сузылып ятып йокыга китте.

Пычак алган иде аждаһа — шундук тәпиен кисте. Җеп тоткан иде — чуалтып бетерде. Кагылуы булды — икенче тәпиенә без кадалды. Шуннан ул елап җибәрде...

Нәкъ шул чагында ишектә Кызчык-Бөтерчек пәйда булды.

— Исәнме. Нигә шулкадәр елыйсың, нәни аждаһа? — диде кыз.

Алеша белән бик күптәннән болай әдәпле сөйләшүче юк иде.

— Ничек еламыйсың инде? Читекче миңа экияти йөгерек башмаклар тегәргә кушты... Тексәм, ул мине чылбырдан ычкындырып иреккә җибәрә. Ләкин мин итек тегә белмим шул! Мин гомумән берни дә эшли белмим. Әнием, әтием, ике әбием һәм түтием мине эшкә өйрәтмәделәр...

— Елама,— диде Кызчык-Бөтерчек.— Мин сиңа ярдәм итәрмен.

Тиз генә өенә йөгерде. Караңгы чоланнан иске йөгерек башмаклар эзләп тапты да әтисенә әйтте:

— Әтием, шушы башмакларны Читекчегә бүләк итимче?

— Ә-әй! — диде әтисе.— Итсәң итәрсең... Мине генә борчыма...

Шуннан Кызчык-Бөтерчек йөгерек башмакларны Читекчегә китереп бирде.

Читекче хәтта караватыннан ук сикереп торды.

— Менә дигән! Искиткеч! — дип кычкырып җибәрде ул, экияти башмакларны әйләндергәләп карый-карый.— Хәзер инде мин һөнәремне исемә төшерермен. Ә син, Бөтерчек, аждаһаны үзеңә ал. Теләсәң ни эшләт!

Кыз, бик әдәпле итеп, Алеша-аждаһага:

— Әйдә минем белән. Икәү дус булыйк,— дип әйткән иде, Алеша, кып-кызыл кызарынып:

— Мин кызлар белән дуслашмыйм! — диде дә каядыр очып та китте. Ләкин биек манарага да очып барып җитә алмады, каршысында Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян пәйда булды:

— Кии-кри-күүүк! Мин сине яңадан сатам!

Олысы-кечесе һәм башкалар тагын аждаһа тирәсенә өелештеләр.

Әдәпсез малайлар аңа таш ыргытты.

Әдәпсез кызлар койрыгыннан тарткалады.

Әдәпсез әбиләр тәпиләренә басты.

Әдәпсез бабайлар телләрен чыгарып үчекләде.

Ә кемнәрнеңдер әдәпсез әниләре һәм әтиләре аждаһага ямьсез сүзләр әйттеләр.

Мәйданга Күмәчче килеп кергәнче, аждаһаны кызганучы да, сатып алырга теләүче дә булмады.

Күмәчче акчасын тылсымчыга бирде дә аждаһаны биек баганадан чылбыры-ние белән чишеп алды.

Күмәчханәгә алып килеп, каймак, он һәм башка шуның ише кирәк-яракны биргәч, болай диде:

— Мин сине ирекка җибәрермен, тылсымлы әкияти аждаһа. Тик элек син миңа сикертмә-кабартма пешереп бир. Минем гаҗәеп-искиткеч осталыгымны исемә төшерәсем килә.

Шундук аждаһа ялгыш он савытын аударды... Каймакны түгеп җибәрде... Шикәр дә чәчелеп китте... Аннары шулкадәр ачы, хәсрәтле итеп елап җибәрде, хәтта Кызчык-Бөтерчекнең кергәнен дә сизмәде.

— Син тагын елыйсыңмыни, кечкенә аждаһа?

— Ничек еламыйсың инде? Күмәчче миңа гаҗәеп сикертмәкабартма пешерергә кушты... Ә әнием, әтием, ике әбием һәм түтием мине бер эшкә дә өйрәтмәделәр. Шуңа күрә мин эш белмим!

— Кайгырма,— диде кыз.— Мин сиңа ярдәм итәрмен.

Кызчык-Бөтерчек икенче савытка он, май һәм башка кирәк-яраклар салды. Мичкә ут төртте. Камыр изде. Вак-вак күмәчләр ясап, табага тезде. Табаны мичкә тыкты...

Һәм шундый күңелле итеп җырлап җибәрде, хәтта мичтәге ялкын бии башлады. Күмәчханәгә тәмле ис таралды.

— Искиткеч! — Күмәчче мич каршына йөгереп килүгә, күмәчләр, сикерешеп чыгып, аның авызына ук кереп киттеләр.

— Хәзер минем гаҗәеп осталыгым исемә төште! — диде Күмәчче.— Ал аждаһаны, Бөтерчек, үзеңә булсын. Теләсәң ни эшләт.

Кызчык-Бөтерчек аждаһаның муеныннан чылбырын салдырды да:

— Әйдә минем белән. Икәү дус булыйк,— диде.

Аждаһа, агарынып:

— Мин кызлар белән дуслашмыйм,— диде дә каядыр очып та китте.

Паркка очып килеп җитүгә, анда тылсымчыны күрде.

— Кии-кри-күүүк! Син, аждаһа, миннән ычкына алмассың! — дип, тегесе аның муенына тагын чылбыр кигезде.— Мин сине яңадан сатам!

Һәм яңадан...

Малайлар аждаһага ташлар атты.

Кызлар койрыгыннан тартты.

Әбиләр тәпиенә басты.

Бабайлар телләрен чыгарып үчекләде.

Ә кемнәрнеңдер әти-әниләре усал сүзләр әйтеп орыштылар.

Шул чак базарга Кызчык-Бөтерчек килеп керде. Тылсымчы янына барды да кайчандыр фея бүләк иткән гаҗәеп башмакларын сала башлады.

— Нишлисең син! — дип кычкырып җибәрде олысы-кечесе һәм башкалар.— Башмакларсыз син бер адым да атлый алмаячаксың бит! Алай гына да түгел... Башмакларың булмас, коточкыч явыз тылсым сиңа да тәэсир итәчәк!

Әмма Кызчык-Бөтерчек гаҗәеп бәллүр башмакларын явыз тылсымчыга сузган иде инде. Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян аларны шундук эләктереп тә алды:

— Кии-кри-күүүк!

— Зинһар өчен,— диде кыз,— аждаһаны чылбырдан ычкындырыгыз инде. Үзе теләгән җиргә очсын.

Олысы-кечесе һәм башкалар, йөгереп килеп, аждаһа муеныннан чылбырны салдырдылар.

— Бар, оч, аждаһа!

Ләкин бу юлы аждаһа беркая да очмады. Хәзер инде бер адым да атлый алмаган Бөтерчек янына килеп:

— Зинһар өчен... Әйдә синең белән дус булыйк. Утыр миңа, Кызчык-Бөтерчек,— дип үтенде.

— Кии-кри-күүүк! — дип хахылдады тылсымчы.— Нинди ахмак кыз! Нинди ахмак аждаһа!

— Ахмак кыз! Ахмак аждаһа! — дип эләктереп алды олысы-кечесе һәм башкалар. Чөнки алар хәзер барысы да коточкыч әдәпсез-тәрбиясез кешеләр иде.

Әмма аждаһа аларга борылып та карамады. Аркасына шәһәрнең иң шәфкатьле кызын утыртып, иплән кенә очып китте. Һәм үзен кеше кебек диярлек хис итте.

Фея сорау бирә:

1. Тавык тәпиләрендәге өйне саклаганда, Алеша-аждаһа нәрсәгә кайгырып елый?

2. Кечкенә аждаһаны кызганасыңмы син, дустым?

3. Әкият-шәһәрдә яшәүчеләр хәзер нишлиләр? Ни өчен алар шундый?

4. Ә син урамда, кинода, кунакта, трамвайда, өйдә үзеңне ничек тотасың, дустым? Әдәпсез кеше кебек түгелме? Әллә син һәрвакытта да әдәпле һәм акыллымы?

5. Ни өчен Алеша-аждаһа бер эш тә белми? Ә син нинди эшләр беләсең? Әниеңә, әтиеңә, әбиеңә ничек булышасың?

6. Әкият-шәһәрдә кем һәрчак әдәпле һәм шәфкатьле булып калды?

7. Аждаһаны азат итәр өчен тылсымлы башмакларын биреп, Кызчык-Бөтерчек дөрес эшләдеме, әллә ялгыштымы?

Ә син шулай эшләр идеңме? Әллә алай эшләмәс идеңме?

МАЛАЙЛАР, КЫЗЛАР

Дөресен генә әйткәндә, әдәпле, пөхтә, яхшы кызга каравы да күңелле. Андый кызлар бераз гына әкияттәге принцессаларны хәтерләтә.

Яхшы кызлар барлык танышлары белән дә, таныш булмаган кешеләр белән дә әдәпле генә сөйләшәләр. Беркайчан да кычкырмыйлар, бәхәсләшмиләр, ызгышмыйлар, тупас-ямьсез сүзләр әйтмиләр.

Ә нинди уңган, булганнар алар! Көлбикәдән бер дә ким түгел!

Дустының киемендә төймә юклыгын күрсә, андый кыз шундук пөхтә генә итеп төймәне тагып та куяр.

Энесенә яки сеңелесенә бер-ике сәгать күз-колак булуын әнисе йә әбисе үтенсә, бик теләп риза булыр. Аны җырлап уйнатыр, әнисе кушканча, яхшылап ашатыр.

Әдәпле-яхшы кыз, кечкенә булса да, өйнең чын хуҗасы. Ул китап киштәләрене, өстәлләргә тузан кундырмас. Ашагач шундук савыт-сабаны юып куяр. Идән себерер. Гөлләргә су сибәр. Песигә сөт бирер. Әбисенә бәрәңге әрчергә булышыр. Хәтта үзенең кульъяулык, алъяпкыч ише әйберләрен дә юып куяр.

Андый кыз беркайчан да холык-

сызланмас. Дусларына һәрчак якты йөз, шат күңел белән яхшы мөгамәлә күрсәтер.

Һәрбер чын-чыннан әдәпле малай андый кыз белән шатланып дуслашачак.

Чөнки барлык малайларның да экиятләрдәге рыцарь яисә принцка охшыйсылары бик-бик килә. Ә экият рыцарьлары яисә принцлары кызларны һәм гомумән хатын-кызларны бик-бик-бик ихтирам итәләр. Шулай түгелме, нәни дустым?

Малайлар һәм кызлар үзара яхшы, ышанычлы дуслар булырга тиеш.

Ә дусларны — без инде беләбез — сакларга кирәк. Аларны кайгыртырга, аларга карата тәрбияле һәм әдәпле булырга кирәк.

Шуңа күрә әдәпле малай трамвайда яки автобуста кызларга һәм гомумән хатын-кызларга урын бирми калмас.

Шуңа күрә ул, кызлар утырып бетмичә, беркайчан да өстәл янына утырмас. Әдәпле малай һәрвакыт үзенә кунакка килгән кызга пальтосын салырга булышыр, әнисе һәм әбисенә башмакларын китереп бирер, аларга йорт эшләрен эшләшер.

Чын рыцарь беркайчан да кызларны рәнҗетмәс.

Һәрчак дусларың күп булсын дисәң, киңәш итәм...

Иптәшләреңә беркайчан да тупаслык күрсәтмә. Хәтер калдырырлык сүзләр әйтмә. Аларга кушамат такма. Үзеңә җайлырак урынны алыр өчен (мәсәлән, уйнаганда) берәрсенә суга яисә төртә күрмә.

Дусларыңның барысы белән дә исәнләшергә онытма. Хәтта иң кечкенәләре белән дә. Нәниләр һәм өлкәннәр белән дә, малайлар һәм кызлар белән дә дус булырга мөмкин.

Әгәр берәр нәрсә өчен дустыңа үпкәләгән булсаң, үпкәңне тизрәк онытып, дустыңны гафу итәргә тырыш. Усалланма!

Әгәр дустың синнән берәр уенчыгыңны яисә укып-карап чыгар өчен китабыңны сорый икән, кызганма. Комсызланма!

Әгәр дустыңнан үзең китап яисә уенчык алып торгансың икән, бу әйберләрне саклап тот һәм вакытында (дустың әйткән яисә үзең вәгъдә иткән вакытка) кайтарып бирергә онытма.

Бу кагыйдәләрне һәрвакыт үтә, нәни дустым. Һәм, Дуслар бәйрәменә чакыргач, шушы кагыйдәләр белән иптәшләреңне дә таныштыр.

ДУСЛАР БӘЙРӘМЕ

Бәйрәмнең көнен-сәгатен сиңа әтиең, әниең яисә өлкәннәрдән башка берәрсе әйтер.

Бу вакытта, дусларыңа өләшер өчен, чакыру билетлары әзерләргә кирәк булыр.

Бүлмәңне тәртипкә китер. Өеңдәге тузаннарны сөртеп, идәннәрне себереп чык.

Калганын Дуслар бәйрәмендә бергәләп эшләгез. Чөнки бу — үзенә бер төрле, үзенчәлекле көн.

Тик, зинһар, буяу, пумала, кәгазь, җилем, кайчыларыңны алдан хәзерләп куй. Аннары үзегез җыелган бүлмәне бергәләп флаглар, гирляндалар белән бизәгез.

Бу бәйрәмдә малайлар кызларга, йорт хуҗасына (әбиең йә әниеңә) бүләкләр әзерләсен. Кәгазьгә ясалган әкияти чәчәкләр, клоун яки үзегез ясаган кәгазь җәнлекләр дә бүләк итәргә була.

Ә кызлар бу вакытта малайлар өчен челтәрле кәгазь салфеткалар, йолдызлы калфаклар һәм шаян битлекләр шикелле бүләкләр әзерлиләр.

Аннары хуҗалар белән кунаклар бергәләп матур, дөрес табын хәзерләргә тиеш. Ризыкларны әбиең йә әниең белән әзерләсәгез, яхшырак булыр. Чынаякларга иплән кенә компот йә чәй салып чыгыгыз.

Беренче булып өстәл янына — кызлар, аннары малайлар утыра.

Малайлар да, кызлар да өстәл янында әдәпле генә, матур гына утырырга тиеш. Бу да Дуслар бәйрәменең мәҗбүри шарты.

Савыт-сабаны кем юа, кем сөртеп урнаштыра, кем өстәлне җыештыра — хуҗалар белән кунаклар, табын яныннан кузгалганчы ук, шуны хәл итәләр. Җыештырып бетергәч, бераз шау-шулы уеннар уйнап, күңел ачып алырга ярый.

Шаян инеш. Бу уенда кызлар һәм малайлар пар-пар булып бер-бер артлы басалар да тотынышып кулларын күтәрәләр. Парсыз калган бала уенны алып бара: коридордан узган шикелле, күтәрелгән куллар астыннан уза. Узышлый берәрсен ала да, шулай ук тотынышкан кулларын күтәреп, аның белән артка барып баса. Хәзер инде парсыз калган малай йә кыз шигырь сөйли, бии яисә җырлый. Аннары, үзеннән алдагы алып баручы шикелле үк, баш очында тоташкан куллар астыннан уза. Үзенә пар сайлап ала. Алар да иң артка барып басалар.

Яңадан шулай кабатлана...

Әдәпле сүзләрне кем күбрәк белә? Бу уенны өлкәннәр белән уйнаганда яхшы. Балалар түгәрәк ясап басалар. Уенны алып баручы өлкән кеше, түгәрәкнең эченә басып, уенда катнашучыларның берәрсенә сораулар бирә:

— Исәнләшкәндә нинди сүзләр әйтергә кирәк?

(Җавап: исәнмесез, хәерле иртә, хәерле көн, хәерле кич һ. б.)

— Берәрсенә үтенечең булганда нинди сүзләр әйтергә кирәк?

(Җавап: үтенәм сездән, рәхим итеп, зинһар өчен, зинһар, рөхсәт итегез.)

— Берәрсеннән гафу үтенгәндә нинди сүзләр әйтәбез?

(Җавап: кичерегез, гафу итегез, кичерүегезне үтенәм.)

— Хушлашканда нинди сүзләр әйтәбез?

(Җавап: хушыгыз, сау булыгыз, хәерле юл, тыныч йокы һ. б. ш.)

Кирәкле сүзне тапмаган яисә исенә төшерә алмаган бала уеннан чыга. Уенны алып баручының барлык сорауларына да тиз һәм тулы җавап биргән бала җиңүче була.

АКЫЛЛЫ-ЗИРӘК ГНОМНАР БЕЛӘН ХУШЛАШУ

— Берәр вакыт без дә Дуслар бәйрәме ясарбыз әле,— диештеләр Гномнар.— Һәм ул бәйрәмгә барлык малайлар һәм кызларны, әкият илендә яшәүчеләрне, җәнлекләр һәм кошларны, агачлар һәм чәчәкләрне, кортлар, коңгыз һәм үрмәкүчләрне, күбәләкләрне, кояшны, тагын әллә кемнәрне чакырырбыз.

— Ничек чакырып бетерерсез икән аларны? — дип гаҗәпләндем мин.— Ул кадәр дусларыгыз сыярлык өйне каян табарсыз икән?

— Әлбәттә инде әкияттән! — диделәр акыллы-зирәк Гномнар.— Сезне дә чакырырбыз.

Без инде акыллы-зирәк Гномнар белән дуслашып өлгергән идек. Шуңадыр, ахры, бабай-Гном:

— Гафу итегез... Безгә очарга вакыт,— дигәч, миңа бик-бик ямансу булып китте.

— Кая очасыз?

— Әлбәттә, әкияткә!

— Әкият-шәһәрдә әллә нинди... дөрес түгел хәлләр булып беткән,— диде эти-Гном.

— Бәлагә тарыганнарны коткару — һәрбер әдәпле Гномның изге бурычы! — диде малай-Гном, башына калфагын кия-кия.— Хушыгыз!

Башка Гномнар да, беравыздан.

— Хушыгыз! — дип кычкырдылар.

Аннары, зур зонтларына утырып, ачык ишектән очып чыгып киттеләр.

Зәп-зәңгәр һавада очып баручы бабай-Гном, эти-Гном һәм малай-Гном артыннан шактый озак карап тордым. Алардан алдарак, Әкият-шәһәргә юл күрсәтеп, акыллы-мәрхәмәтле карга оча иде.

— Каррр! — дип кычкыра үзе.— Алга! Сөйләшә торган сәгатьнең миндә ачкычы бар. Мин аны ялгыш кына Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның борын төбеннән диярлек чәлдергән идем!

ҮЗ ҮРНӘГЕҢДӘ ТӘРБИЯЛӘҮ

(өлкәннәр белән сөйләшү)

Бала тәрбияләүнең иң элек өебездә урнашкан даими әхлак, культура атмосферасыннан, гаиләдәге — яхшы (иисә, кызганычка каршы, начар) мөнәсәбәттән башлануы хакында сүз булган иде инде.

Сабый шул атмосферада яши, шул һаваны сулап үсә. Тату, тыныч гаиләдә балалар, гадәттә, сәламәт психикалы, тыныч холыклы булалар.

Безгә, ата-аналарга, инде әйткәнебезчә, балаларыбызны тәрбияли башлаган-

да бу әһәмиятле психик факторны исәпкә алырга кирәк.

Үз чиратында, гаиләдә дуслык-татулык, тынычлык, ихтирамлы мөнәсәбәт урнаштыру өчен, һәрбер әти-әни үзләре дә югары культурага ия булырга тиешләр. Әтисе, бабасы йә өлкән абыйсының яхшы үрнәгеннән башка гына кыю, намуслы, үзен һәм якыннарын яклардык ир бала тәрбияләү мөмкин түгел. Ялкау, шапшак, таркау, эш рәтен белми торган ананың пөхтә һәм эш сөючән кыз бала үстерә алуы да шикле.

Кечкенә баланың гадәтләре, үз-үзен тоту рәвеше хезмәткә һәм тирә-юнендәге кешеләргә мөнәсәбәте өлкәннәр үрнәгендә формалаша. Балалар, бигрәк тә нәниләр, гадәттән тыш күзәтүчән булалар. Искиткеч яхшы хәтерле булулары өстенә, алар, үзләре дә төшенмәстән, һәрнәрсәдә өлкәннәргә охшарга тырышалар.

Һәрвакытта да әтисе әбисенә өс киемен салырга булышамы, әнисе балалар бүлмәсен җентекләп җыештырамы — бала, инде 3—4 яшендә үк боларны бик яхшы күрә. Әнисенең ничек ашыга-кабалана аш әзерләп, кер юып, кер үтүкләп йөрүен дә, әтисенең бу вакытта газета укып яисә телевизор карап утыруын да күрә. Һәм өйдәге башка, инде күптән күнегелгән, гадәтләнгән булганга безнең күзгә чалынмый торган вак-төякләрне дә бала көн саен, сәгать саен күңеленә салып бара. Шул рәвешчә, үзе дә сизмәстән, безнең, ягъни өлкәннәрнең тормышы үрнәгендә тәрбияләнә.

Балага сабый чагыннан ук аралашырга туры килгән өлкәннәрнең барысы да, телиме-теләмиме, аның тәрбиячеләре дә булалар. Шулай да, табигый инде, аның гадәтләренә, формалашып кына килүче холкына бала өчен иң якын кешеләрнең — гаиләнең балага игътибарын, назын күбрәк бирүчеләрнең — йогынтысы зур. Бу очракта бала өчен (бигрәк тә ул ир бала булса) аны якын итүче, яратучы кешеләрнең берсе үз әтисе булу — искиткеч зур бәхет.

Аналарның бала тәрбияләүдәге (бигрәк тә кечкенә балаларны тәрбияләүдәге) роле турында күп язылган. Әмма сабыйның сәламәт һәм нормаль үсүе өчен ана назы, ана түземлеге, ана игътибары, ана мәхәббәтенең зарурлыгы турында тагын шул кадәр үк язарга мөмкин. Әнисенең иркә, ягымлы бишек җырын тыңлаган сабый шатланып тыныч йокыга тала... Авырган чакта әни биргән дарулар да алай ук ачы булмый. Әнинең йомшак куллары чирне дә юып алгандай итә... Янәшәдә әни булганда, кап-караңгы бүлмәгә керергә дә тамчы да курыкмыйсың.

...Шулай да, малайларда кыюлык, батырлык тәрбияләү турында сөйләгәндә, мин бала чагыма әйләнеп карыйм. Көтмәгәндә Фин култыгында башланган штормны хәтергә төшерәм... Чәчрәп күзләргә кадала торган тозлы су тамчыларын. Әтием кулындагы авыр дулкын сындырган ишкәкне. Куркуымны.

— Хәзер ни эшлибез инде? Сыңар ишкәк белән ярга чыгып булмас бит!

Әтиемнең тыныч тавышы:

— Тынычлан. Һичшиксез, чыгарбыз.

Һәм абыем Genаның нәзек тавышы:

— Әлбәттә, чыгарбыз! Син курыкма.

Тагын... Шәһәрара автобуста кинәт кенә дөрләп киткән янгын. Ишеккә тыгылып бер-берсен таптаучы куркынган пассажирлар... Паника. Һәм, бөтен шау-шуларны басып, әтием тавышы:

— Хәзер үк паниканы туктатыгыз!

Шунда ук ике абыемның бераз гына калтыравык тавышлары:

— Апалар, курыкмагыз!..

Тәрәзәләрне ватып, балаларны чыгардылар. Аннары ирләр янгынны сүндерде...

Төрле гаиләләр һәм хәтта төрле халыклар тормышыннан бик күп мисаллар белән шунысы бәхәссез расланган: малайларның характеры өлкән ирләр үрнәгендә формалаша. Алар өчен сабый чактан ук иң аңлаешлы, иң якын ир кеше — әтиләре.

Әти булу — бик җитди һәм гадәттән тыш җаваплы эш. Шуңа күрә әти кешенең, үз күңелен дә, баласы күңелен дә фәкыйрьләндереп, бала тәрбияләүнең бөтен авырлыгын хатын-кыз җилкәсенә аударырга хакы юк. (Кызганычка каршы, андый хәлләр дә була.) Бала тәрбияләү — күпме дәрәҗәдә хатын-кыз (аналар) эше булса, шул ук дәрәҗәдә ирләр (аталар) эше дә. Менә шуңа күрә дә, тәрбия эше иң элек үз-үзеңне тәрбияләүдән башлана дип әйтәбез икән, мо-

ның белән без бала каршында әти кешенең дә җаваплылыгын раслыйбыз. Аеруча ир бала каршындагы, чөнки бала өчен әти кеше — батырлык идеалы. Бала кечкенә чагында бу бигрәк тә шулай.

Сөйгәне, әнисе һәм башка хатын-кызлар каршында җаваплылык хисен, аларны яклау, ярдәм итү теләген үз-үзен тотышы, әнисенә, хатынына ягымлы, игътибарлы мөнәсәбәте белән беренче булып малаенда нәкъ менә әти кеше уятырга тиеш.

Кечкенә малайның үз-үзен тотышы — бик еш кына атасының үз-үзен тотышының көзгедәге чагылышы ул... Шуның өчен дә әти кешеләрнең намуслы, әдәпле, көчле булырга, тормыш йөгенең авыр өлешен үз җилкәләренә алырга тиеш икәнлекләрен онытырга хаклары юк. Бигрәк тә балалары алдында.

Транспортта әтисенең һәрвакыт хатын-кызга урын бирүен күргән малай үзе дә нәкъ шулай эшләячәк. Әтисенең тотнаклы һәм тәрбияле икәнлеген, беркайчан да тавышын күтәрмәвен, ничек кенә арып кайтса да, кәефе юклыгын сиздермәскә тырышуын белгән бала үзе дә хисләрен йөгәнләргә өйрәнәчәк. Малай әтисенең әнисенә, әбисенә карата ягымлы һәм сак мөнәсәбәтен, аларны очсызкырыйсыз йорт эшләреннән азат итәргә тырышуын гел күреп тора... Әниләре берәр кая ашыкса, авыру яки арыган булса, үтенгәнне дә көтмичә, әтисе үзе белеп «хатын-кыз эшен» эшли: савыт-саба, идән юа, кибеткә бара һәм, кирәк икән, хәтта бик тәмле ризыклар да пешерә... Мондый гаиләдә балалар кече яшьтән үк әбиләренә, әниләренә бик теләп булышалар, йорт эшләрендә катнашалар. Әтиләре үрнәгендә, аларга охшарга тырышып шулай эшлиләр алар.

Акыллы ата бала каршындагы абруеннан бик белеп кенә файдаланыр. Тирә-юнендәге кешеләрне генә түгел, үз баласын да ихтирам итәр. Беркайчан да аларның кешелек дәрәҗәсен рәнҗетмәс. Беркайчан да, бигрәк тә чит кешеләр алдында, тавышын күтәрмәс. Ялганлаган, үзеннән көчсезрәкләрне яисә иптәшләрен рәнҗеткән бала мондый атаның ризасызлыгын тизрәк сизәчәк, гаебен тирәнтенрәк аңлаячак.

Әйтергә кирәк, тәрбияле ата андый хәлләрдә дә тотнаклы булып кала, уйлап эш итә. Җитди һәм кырыс сөйләшү вакытында улының (йә кызының) гаебе хакында үз фикерен әйтә. Тиеш тапса, җәза да бирә: мәсәлән, урамга алып чыкмый, балыкка алып бармый, өйдә малае бик яратып эшли торган «ирләр эшеннән» бу кичне азат итә һ. б. (Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, хөрмәтле әтиләр, балага мондый җәза кычкыруга караганда ныграк тәэсир итә. Мәсхәрәле булуына карамастан, кычкыруларга бала күнегә. Тагын да начаррагы — баланы гел хурлап, мыскыллап торган кеше аның ихтирамын, ышанычын бик тиз югалта. Алай гына да түгел, гел кычкырып тору, җәза бирү баланы усалландыра. Үзен хаксызга рәнҗеткән кешене, хәтта ул әтисе яки әнисе булса да, бала бөтенләй хөрмәт итми башлый.)

Көндәлек өй эшләреннән тыш, тагын әтисе (бабасы яки өлкән абыйсы) белән уртак «ирләр эше», мавыгуы булу бала өчен бик файдалы. Мәсәлән, балалар бүлмәсендә швед стенасы яки ишегалдында спорт мәйданчыгы ясау кебек эшләр булу. Әбисенә талган аякларын утырып ял иттерер өчен улыгыз белән бергәләп эскәмия ясап куйсагыз да начар булмас.

Яз көне — сыерчык оялары, ә кышын кошларга җимлекләр ясап, өй каршысына яисә урманга илтеп куярга мөмкин. Чын ир-егеткә эш бетәмени соң! Һәрбер шундый эш баланы әкренләп һәм табигый рәвештә хезмәткә, түземлеккә, өлкәннәр дөньясына катнашы барлыгыннан канәгатьлек алырга өйрәтә.

Әти кешенең кыз балага, кызына йогынтысын да аз дип әйтеп булмый. Акыллы, житди, йомшак күңелле, оста куллы ата кыз бала өчен бик озак, ә бәлки гомере буенадыр, егетлекнең чын үрнәге булып кала. Шулай да кыз бала тәрбияләүдә аналарның роле әйтеп бетергесез зуррак. Чөнки кызларның гадәтзәвыклары, өйгә, гаиләгә, якыннарына мөнәсәбәте иң элек үз әниләре үрнәгендә формалаша. Менә шуңа күрә дә кызлы гаиләдә әни кеше үзенә карата гадәттән тыш таләпчән, әдәпле, тотнаклы, пөхтә, җыйнак, мөлаем булырга тиеш. (Хәер, кыз баласы булмаган әниләрнең дә башкача булырга хаклары юктыр дип уйлыйм мин.) Кечкенә кызын йорт эшләренә

түземлек һәм осталык белән нәкъ менә әнисе өйрәтә. Гаиләдә ана белән кызның (ата белән улныкы кебек үк) үзләре генә эшли торган уртак «хатын-кыз эшләре» булырга тиеш. Ул баштарак гади генә була: кызыгыз һәркөнне кич (йокларга ятар алдыннан) уенчыкларын җыеп, тәртипкә китереп куйсын, көндез курчакларының күлмәк-алъяпкычларын юсын... Соңрак, 5—7 яшьләргә җиткәч, аның эшләре күбәер, катлаулана барыр. Әмма инде йорт эшләренә күнеккән кыз аларны бик теләп, шатланып башкарачак.

Ата-ананың таләпләре нигезле, аңлаешлы һәм бала үтәп чыгарлык булырга тиеш.

4—7 яшьлек баланың өйдә үзенә йөкләнгән даими эше була. Мәсәлән: тузан сөртү, әбисенә кухнядагы савыт-сабаны җыеп юарга булышу, тәрәзә артындагы җимлеккә кошлар өчен җим сибү, үзенең аяк киемен чистарту, кибеттән икмәк алып кайту, китап һәм уенчыкларын тәртиптә тоту. Бала боларны эшләргә гадәтләнсен өчен, көндәлек режимында даими вакыт бүлеп бирергә, эшенә тиешенчә җитдилек белән таләпчәнлек күрсәтергә кирәк. Без, хөрмәтле ата-аналар, нәни улыбызны яки кызыбызны тырышып, яхшы эшләгәне өчен мактарга, ә инде иренеп, аннан-моннан гына эшләсә, шелтәләргә, алай гына да түгел, яңабаштан эшләтергә онытмаска тиешбез. Шул чагында гына бала үзенең өйдәге эшләренә, ә соңрак, үсә төшкәч, башка вазифаларына да җитди һәм җаваплы карар.

Менә шулай ата-ананың һәрбер эшгамәле тәрбия максатына хезмәт итәргә тиеш. Безнең балалар каршындагы җаваплылыгыбызны беркайчан да, бер генә минутка да хәтеребездән чыгарырга хакыбыз юк. Хәтта вак-төяк мәсьәләләрдә дә...

Шуңа күрә ата-аналарга күп укырга, укыган әйберләре хакында җитди уйланырга өйрәнү зарур. Балалар белән бергәләп кино, театр, концертларга ешрак йөрергә кирәк. Үзләре туплаган рухи байлыкларны соңрак балаларга тапшырып калдыру өчен, ата-аналар армыйталмый акыл тупларга, хисләрен тәрбияләргә тиеш.

Тәрбияле ата-ананың, эшләре бик тыгыз булуга да карамастан, иртәләрен зарядка ясавы, спорт белән җитди һәм даими шөгыльләнүе бер дә гаҗәп түгел. Андый гаиләләрдә балалар да спорт белән бик кечкенәдән дуслаша. Димәк, таза, көчле була. Ә бу — тәрбия эшендә җитди фактор. Чөнки ата-ана физик яктан саусәламәт баласына таләпләрнең дә зуррагын куя ала.

Табигатькә сакчыл мөнәсәбәт, тирәюнендәге кешеләргә яхшы мөгамәлә күрсәтүче, якыннарына игътибарлы ата-ана тирән ихтирамга лаек. Димәк, аларның балалары да шушы сыйфатларга ия булачак.

Улларыбыз һәм кызларыбызны тәрбияләгәндә, билгеле инде, турылыклы дусларыбыз — әдәбият һәм гомумән сәнгатьне онытырга ярамый. Бала белән ешрак китаплар укырга, аларның эчтәлеге турында фикер алышып, төрле геройларның эш-гамәлләренә бәя бирергә тырышырга кирәк. Шул чагында яраткан героеның үз-үзен тотышы безнең балабызга да үзен дөрес, яхшы тоту үрнәге булачак. Ул барлык нәрсәдә үзенең яраткан китап героена охшарга тырышачак.

Караган фильм яисә балалар спектакле дә сабый өчен шундый ук әдәплелек һәм гомуми культура дәресе булачак. (Монда да ата-аналар уңай һәм тискәре геройларның эш-гамәлләренә баланың игътибарын юнәлтеп, ул турыда фикер алышырга тиеш.)

Безнең көндәлек тормышта балага тәрбия бирү мөмкинлеге адым саен диярлек чыгып тора. Бары тик бу мөмкинлекләрне күрә һәм алардан файдалана белергә генә кирәк. Ә иң мөһиме, хөрмәтле әтиләр, әниләр, бабайлар һәм әбиләр, әлбәттә инде, балаларның иң элек безнең үзебездән үрнәк алуларын онытмау.

ӘТИЛӘР ҺӘМ МАЛАЙЛАР ӨЧЕН БИРЕМНӘР

1. Кошларга җимлек ясагыз. Урманда яки паркта йөргәндә, аны агач кәүсәсенә беркетеп куегыз. Җимлегегезгә ярма, сохари ише азыклар куярга онытмагыз.

2. Аяк куяр өчен әбиегезгә яисә әниегезгә эскәмия ясагыз.

3. Сырлап-бизәкләп кухня тактасы ясагыз.

ӨЛКӘННӘРГӘ КАЙБЕР ИСКӘРМӘЛӘР

Тәрбияле ата-аналар тирә-юньнәрендәге барлык кешеләр (һәм үз балалары) белән әдәпле мөгамәләдә булалар.

1. Тәрбияле әни һәм әти беркайчан да (сүз белән дә, эш белән дә) улының яисә кызының кешелек дәрәҗәсен төшерергә тырышмый. Беркайчан да балага кычкырмый. Аның янында тупас сүзләр әйтми. Тәрбия чарасы итеп бервакытта да тән җәзасын кулланмый.

2. Әдәпле ата-аналар балаларына юкка-барга кисәтү ясамыйлар. Мөмкин булган һәр очракта балаларының мөстәкыйльлеген хуплап торалар.

3. Андый ата-аналарның балаларына куелган таләпләре дә бердәм була. Әгәр аларның кайсы да булса берәрсе шушы вакытта икенчесенең шелтәсен хаксыз дип таба икән, ризасызлыгын, аның сәбәпләрен соңрак әйтә. Бала янында түгел.

4. Акыллы ата-ана, баласын кимсетмәс өчен, аңа кисәтү ясаганда яисә нәрсәдән булса да тыйганда, «син әле кечкенә», «син әле моны аңламыйсың», «баласың яшь әле» кебек сүзләр белән баланың кечкенәлеген сылтау итми.

5. Балага куясы таләпләрен ата-аналар иң элек үзләренә куеп карасыннар. Шуңа күрә үз балаларына карата алар да әдәпле, игътибарлы булырга тиеш. Улыңа яки кызыңа «хәерле иртә», «тыныч йокы», «рәхмәт» кебек сүзләрне ешрак әйтергә, шулай ук аны эшләгән эше яки игътибары һәм кайгыртуы өчен мактарга онытмаска кирәк.

6. Культуралы, тәрбияле ата-ананың таләпләре даими була. Алар әдәплелеккә балаларын әллә нигә бер, исләренә төшкәндә генә түгел, кагыйдәләрне аз-азлап катлауландыра барып, даими рәвештә өйрәтәләр.

ӘНИЛӘР ҺӘМ КЫЗЛАР ӨЧЕН БИРЕМНӘР

1. Төсле кәгазь яисә тукыма белән иске китапларны төпләгез. Алар элеккегә караганда да матуррак булсын.

2. Кухняда кайнар савыт-саба тотарга бияләй тегегез.

3. Бизәкле тукымадан берничә чәчәк һәм күбәләк кисеп алып, ачык төстәге җептән чит-читләренә челтәр тотыгыз. Килгән кунакларыгыз алдына куярга үзенчәлекле, матур салфеткалар килеп чыгар.

ФЕЯНЕ НИЧЕК УЯТЫРГА ИНДЕ?

Коточкыч явыз тылсымчы Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян соры болытка утырган да шәһәр өстенә кар сибепме-сибә!

Бу карлар гади карлар түгел!

Ул карның берәр бөртеге кешенең колагына керсә, теге кеше акыллы сүзләрне ишетми башлый. Авызына керсә, көлә-елмая алмый. Ә күзенә эләксә, дусларын күрмәс була. Әгәр инде алай-болай тылсымлы кар бөртеге йөрәккә эләксә, теге кеше гаҗәеп могҗизаларга ышанмый башлый!

Кар бөртекләрен җил шәһәр буйлап куып йөри, ишек һәм форточкалардан өй эчләренә сибә. Ә явыз тылсымчы моңа әйтеп бетергесез канәгать.

Менә ул тату гына уйнап утыручы Кызчык-Бөтерчек белән аждаһаны тәрәзәдән күреп алды да ниндидер усал-явыз сүзләр кычкыра башлады. Аның тавышыннан коточкыч зилзилә күтәрелде дә, тәрәзәләрне ватып, Кызчык-Бөтерчеккә учлап кар томырды.

Шул карның дүрт бөртеге кызның колагына, өчесе — авызына, икесе ике күзенә эләкте. Ә берсе, аеруча чәнечкелесе, йөрәгенә үк барып кадалды. Шундук Хат ташучы кызының йөзеннән елмаю качты.

Дусларын күрмәс һәм могҗизаларга ышанмаска әверелгән Бөтерчек күзгә күренеп агара, ябыга, эреп юкара башламасынмы! Аның аша хәтта соры болытка атланган Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян күренә иде.

— Хәзер аны коткарса могҗиза гына коткарыр! Кии-крикүүүк! Ләкин бу шәһәрдә гаҗәеп могҗизалар бетте! — дип кычкырды да тылсымчы, кар өермәсенә кереп югалды.

Шундук тәрәзәдән кечкенә аждаһа очып чыкты. Соры, ямьсез өйләр өстеннән, очмый торган зонтлар Сатучы йокымсырап утырган парк өстеннән, йоннарын кабарткан калай этәчле шәһәр манаралары өстеннән кат-кат әйләнде... Ләкин аңа күтәрелеп караучы да булмады. Тирәсендә тылсымлы кар бөртекләре генә бөтерелеп биештеләр. Аждаһа авызыннан ут бөркүгә, алары да эреп юкка чыкты.

Алеша, ниһаять, кумәчханә болдырына төшеп, ишек шакыды.
— Кем бар? — диде ишек артыннан Күмәчче.
— Мин... Аждаһа.
— Ни калган сиңа монда?
— Могҗизалы сикертмә-кабартма кирәк иде.
— Мин андый кабартмалар пешермим хәзер. Чөнки безнең шәһәрдә могҗизага ышанучы калмады...
— Мин ышанам! — дип кычкырып җибәрде кечкенә аждаһа. — Бөтерчекне могҗиза гына коткара ала. Югыйсә ул эреп бетәчәк!
— Ул шәфкатьле кыз өчен тырышып карармын мин, — дип ризалашты Күмәчче. — Әмма үзең булышсаң гына...
Өч көн, өч төн тырыштылар Күмәчче белән аждаһа. Кып-кызу итеп зур мич яктылар. Чип-чиста итеп он иләделәр. Камыр изделәр... Һәм шундый гаҗәеп күмәчләр пешерделәр, авызга алар үзләре сикереп-йөгереп керәләр иде.
Инде Күмәчче, аждаһаның тәпиен кысып:
— Мине бүгенге көннән гомерлек дустың дип исәплә, — диде.
— Рәхмәт.
Могҗизалы сикертмә-кабартмалар салынган кәрзинне эләктереп, кечкенә аждаһа шундук Хат ташучы өенә очты.
Калай әтәчләрнең кайберләре аңа ялгыш кына карап алдылар.
Аждаһа өйгә очып керде. Тәрәзә янында утырган Кызчык шундый үтә күренмәлегә әйләнгән, аның аша күршедәге соры йорт күренеп тора иде.
— Рәхим ит, аша... — диде аждаһа, кәрзинне Бөтерчеккә сузып.
Ләкин кыз алсу кабартмаларга кагылып та карамады.
— Ай-ай! — дип урыныннан сикереп торды боек Хат ташучы. — Бу могҗиза аңа ярдәм итә алмас дип куркам шул мин.
Ә кечкенә аждаһа яңадан очып чыгып китте.
Күңелсез соры йортлар өстеннән, базары кайнап-шаулап торган иң зур мәйдан өстеннән, калай әтәчле шәһәр манаралары өстеннән очты ул... Калай әтәчләр аңа бу юлы гаҗәпләнеп карадылар...
Аждаһа читекченең ишеген шакыды.
— Мондый җилле-буранлы көндә кем йөри? — дип сорады ишекне ачмыйча гына Читекче.

— Мин. Аждаһа.
— Ни кирәк сиңа?
— Йөгерек башмаклар.
— Искеләре инде теткәләнеп бетте. Ә яңаларны текмим,— дип мыгырданды Читекче.— Хәзер безнең шәһәрдә берәү дә могҗизага ышанмый.
— Ләкин миңа могҗиза кирәк! — диде аждаһа.— Кызчык-Бөтерчекне коткарыр өчен!
— Ул кыз хакына тырышып карармын, әгәр миңа үзең дә булышсаң,— дигән сүзләр белән Читекче ишеген ачып аждаһаны кертте.
Өч көн, өч төн баш күтәрми эшләделәр. Һәм шундый гаҗәеп йөгерек башмаклар тегеп-ясап куйдылар, моңа кадәр берәүнең дә андыйны теккәне булмагандыр. Теләсә нинди аякка сыя иде ул башмаклар!
Читекче дә аждаһаның тәпиен кысты:
— Хәзер мин синең гомерлек дустың.
— Рәхмәт...— диде кечкенә аждаһа.
Гаҗәеп йөгерек башмакларны алып, Хат ташучының өенә очты. Бу юлы калай әтәчләр аңа игътибар белән карадылар.
Аждаһа очып кергән тәрәзә янында Кызчык-Бөтерчек утыра. Шулкадәр юкарган, аның аша бөтен шәһәр мәйданы үтәли күренә иде.
Алеша-аждаһа могҗизалы йөгерек башмакларны кызның аяк очына китереп куйды:
— Рәхим ит, киеп җибәр...
Ләкин Бөтерчек могҗизалы башмакларга кагылып та карамады.
— Ай-ай-ай! — диде Хат ташучы.— Аңа бу могҗиза да ярдәм итми...
Шунда ул ялгыш кына йөгерек башмакларны киеп куйды да... коточкыч тизлек белән өстәл тирәли йөгерә башлады.
— Аңа бары фея генә ярдәм итә ала! — дип кычкырды ул, йөгергән уңайга.
Аждаһа тагын шәһәр өстеннән, күңелсез-соры йортлар, соргылт парк һәм иң зур мәйдан өстеннән очты... Манаралар өстеннән очканда, калай әтәчләр түземсезләнеп канат кага башладылар.
— Кая? Кая ашыгасың соң син? — дип сорады Күмәчче, тәрәзәсеннән башын тыгып.

— Биек манарага! Феяне уятырга кирәк!

— Алайса,— диде Күмәчче,— мин дә синең белән барам. Һәм аждаһа артыннан чапты.

— Кая болай ашагасыз? — дип сорады Читекче, ишегеннән сузылып.

— Биек манарага! Феяне уятырга!

— Алай булгач,— диде Читекче,— мин дә сезнең белән барам!

Кечкенә аждаһа белән Күмәчче артыннан Читекче дә чыгып йөгерде... Озакламый алар өчесе дә биек манара янында иде инде. Манара ишекләрендәге тимер йозаклар күгәреп беткән. Никадәр генә тырышмасыннар, Читекче дә, Күмәчче дә, аждаһа да йозакларны ача алмады. Шуңа бик нык кәефләре кырылды. Өчесе дә, миңа карап, болай диделәр:

— Мәрхәмәтле экият законнары нигезендә безгә хәзер берәрсе ярдәм итәргә тиеш!

Кемдер аларның баш очында гына:

— Шулай шул, бик дөрес! Каррр! — дип карылдады.

Бу, әлбәттә, мәрхәмәтле карга иде. Аның артыннан зонтларына утырып акыллы-зирәк Гномнар килеп җитте.

Башына тылсымлы кызыл калфак кигән озын ак сакаллы бабай-Гном.

Тылсымлы яшел калфагын кигән җирән мыеклы әти-Гном.

Җирән башына зәңгәр калфак утыртып куйган сипкеллесе — малай-Гном.

— Каррр! Каррр! — диде әдәпле-мәрхәмәтле карга.— Бу шәһәр ни исемле, шуны әйтмәссезме икән?

Кечкенә аждаһа, Күмәчче һәм Читекче, беравыздан диярлек:

— Әкият-шәһәр! — дип җавап бирделәр.

Гномнар бик шатланышты:

— Рәхмәт яусын! Димәк, килеп җиткәнбез икән! Исәнмесез!

Шунда мәрхәмәтле карга явыз тылсымчының борын төбеннән диярлек чәлдереп киткән ачкычны томшыгыннан чыгарды. Аннары, Гномнар һәм кечкенә аждаһа белән бергәләп, сөйләшә торган сәгать янына очып килде...

Өч көн, өч төн азапланды Гномнар, карга һәм аждаһа. Өч көн, өч төн буена, күзләрен дә йоммыйча, коточкыч явыз тылсымчы ваткан сәгатьне төзәттеләр.

Өч көн, өч төн буена аларга Читекче белән Күмәчче файдалы киңәшләр биреп тордылар... Ниһаять, сөйләшә торган сәгать телгә килде:

— Тек-тек! Бик зур рәхмәт сезгә! Ә манара ишегендәге тутыккан тимер йозакларны, беләсегез килсә, әдәпле сүзләр әйтеп кенә ачып була.

Читекче белән Күмәчче башларына ябыштылар:

— Ай! Бөтен әдәпле сүзләрне онытып бетергәнбез шул!

Кечкенә аждаһа елап ук җибәрде:

— Ник кенә, никләр генә әдәпле булырга тырышмадым икән соң? Нигә әдәпле сүзләр өйрәнмәдем икән? Хәзер менә мин әдәпсез булганга Бөтерчек эреп бетәр инде. Ә мин аңа берничек тә ярдәм итә алмам!

— Зинһар, алай кайгырмагыз! — диде мәрхәмәтле карга.— Карр! Без сезгә ярдәм итәрбез...

— Әлбәттә,— дип ризалаштылар акыллы-зирәк Гномнар.— «Әдәплелек әлифбасын» яттан беләбез без.

Бераз пышылдашып-киңәшеп алдылар да, барысы бергә:

— Зинһар өчен, хөрмәтле йозаклар, ачыла күрегез! — дип үтенделәр.

Йозаклар шундук ачылып та китте. Кечкенә аждаһа, Күмәчче, Читекче һәм акыллы-зирәк Гномнар сөенечләреннән кулларын чәбәкләп куйдылар.

— Карр! — дип җитди генә кисәтте аларны мәрхәмәтле карга.— Ашыгырга кирәк.

Шулай диде дә бормалы баскычтан башлап үзе йөгереп менеп китте. Аның артыннан башкалар да иярде. Менә алар ишек төбенә килеп җиттеләр. Менә ишекне әдәпле генә шакыдылар... Менә, сызык кына ачып:

— Уянчы, шәфкатьле фея! Зинһар өчен! — дип үтенделәр.

Әмма җавап бирүче булмады. Бүлмә бушаган, фея исә юкка чыккан иде.

Фея сорау бирә:

1. Ә бу бүлектә кечкенә аждаһаны ошаттыңмы? Хәзер ни өчен ошый ул сиңа?

2. Әйт әле, хәзер син аның белән дуслашырга риза булыр идеңме?

3. Ни өчен Алеша-аждаһаның чын дуслары артты?

4. Тимер йозакларны нинди тылсым белән ачып була иде? Ә син нинди әдәпле-яхшы сүзләр беләсең, дустым? Ул сүзләрне кешеләргә еш әйтәсеңме?

КУНАККА ЧАКЫРУ

Әкияти вакыйгабыз ахырына якынлашып килә. Сөйләшә торган сәгать бу вакыйганың актык минутларын исәпли.

— Тек-тек! — ди ул.— Тиздән, бик тиздән әкият геройлары белән аерылышыр вакыт җитә, дустым. Тек-тек! Шуңа күрә барыбызга да бераз ямансу булып китте. Тек-тек!

Дөресен әйткәндә, синең белән аерылышу миңа да ямансу, дустым. Ләкин шунысы юаныч бирә: безнең танышлык сиңа күп нәрсәләрне аңлап, белеп, хәтереңдә калдырырга ярдәм иткәндер.

Бу китапның сиңа файдасы булыр дип өметләнәм. Әгәр дә аның барлык әкияти һәм чын дәресләрен игътибар белән тырышып өйрәнгән һәм барлык күнегүләрен дә эшләгән булсаң, һичшиксез, әдәпле кешегә әверелгәнсеңдер. Моның шулай икәнлегенә мин ышанам. Акыллы-зирәк Гномнар да, Саумы фея дә, мәрхәмәтле карга да, Кызчык-Бөтерчек тә, шулай ук әкият илендәге башка танышларың да моңа ышана. Шуңа күрә дә алар сиңа менә шушы ашыгыч әкияти телеграмманы җибәргәннәр.

АШЫГЫЧ-ӘКИЯТИ ТЕЛЕГРАММА

«Кечкенә дустыбыз!

Без сине яратабыз. Чын-чынлап әдәпле кеше булуыңа ышанабыз. Шуңа күрә сине барлык дусларың белән кунакка чакырабыз. Рәхим ит!

Озын-ерак юллар үтеп, алан-кырлар аръягына, шикәр таулары артына Әкият-шәһәргә кил. Көтәбез».

Менә бит эшләр ничек тора, дустым. Сиңа юлга җыенырга вакыт.

Ләкин Әкият-шәһәргә эләгер өчен син бер шартны үтәргә, ягъни әдәплелеккә имтихан тапшырырга тиеш буласың.

Андый имтиханны дуслар белән бергә тапшырганда күңеллерәк тә әле. Әкият-шәһәргә алар да чакырылган бит. Син аларга шушы чакыруны тапшыр, имтиханның көнен һәм сәгатен хәбәр ит.

Әдәплелеккә имтиханны чын бәйрәм кебек уздырырга кирәк. Син инде андый бәйрәмнәрне оештыра беләсең. Тик бу юлы барысын да үзең генә эшләргә тырыш. (Әгәр дә инде әниең, әбиең яисә апаңның ярдәменнән башка берничек тә булдыра алмыйсың икән, алар да булышырлар дип уйлыйм.)

Ә менә имтихан сорауларын сиңа әйтә алам.

Аларны әтиеңме, әниеңме, кәгазь, битләренә яисә открыткаларга язып алып, феянең алъяпкыч кесәсенә салса, бик яхшы булыр иде. Кунаклар, ул кесәдән икешәр-өчәр открытка алып, андагы сорауларга чиратлашып җавап бирергә тиеш булалар.

Дусларыңның берәрсе җавабын онытса, әйтеп җибәр. Бу имтиханда бер-береңә әйтеп торырга, хәтта сорауларга бергәләп җавап бирергә дә рөхсәт ителә. Җавабыгыз гына дөрес булсын.

Дөрес җавап биргән һәр кешегә Әкият-шәһәргә керү билеты бирелә. (Билетларны алдан әзерләп куярга кирәк!)

Сәяхәт бераз соңрак башланыр. Ә хәзер, имтихан тапшыргач, нинди дә булса уен уйнап, бераз күңел ачып алырга мөмкин.

ИМТИХАН СОРАУЛАРЫ

1. Табын янында утыра беләсеңме? Чәнечке, калак, пычакны дөрес тотасыңмы?

2. Әниеңә, әбиеңә син булышасыңмы? Ничек итеп булышасың?

3. Берәр кешенең өенә йә квартирасына барып кергәнче нишлиләр?

4. Кем белән һәм ничек исәнләшергә кирәк? Очрашканда һәм хушлашканда нинди сүзләр әйтәләр?

5. Кунакларны яисә эштән кайтучы әти-әниеңне, туганнарыңны ничек каршы аласың?

6. Кунакта яисә транспортта кем кемгә урын бирергә тиеш?

7. Кунакка, театрга яисә балалар китапханәсенә кергәч, баш киемен салырга кирәкме?

8. Әгәр конфет ашасаң, кәгазен нишләтерсең:

а) җиргә ташларсыңмы, әллә чүп савытынамы;

б) әниеңә бирерсеңме?

9. Кинода, театрда яки башка шундый урыннарда сөйләшергә ярыймы? Яраса, кайчан ярый?

10. Клумбадан чәчәк өзгән, урманда яисә паркта агач ботакларын сындырган кешене без кем дибез?

11. Ни өчен урмандагы чәчәкләрне өзәргә ярамый? Ни өчен коңгызлар, күбәләкләр тотарга ярамый? Ни өчен кырмыска ояларын туздырырга һәм чебен гөмбәләренең матур эшләпәләрен бәреп төшерергә ярамый?

12. Тереклек ияләрен рәнҗеткән кешене әдәпле дип әйтеп буламы?

13. Ни өчен чын-чынлап әдәпле кеше беркайчан да ялганламас, мактанмас һәм бүтәннәргә тупас сүз әйтмәс?

Болар гади сораулар түгел. Аларга җавап биргәнче, башта яхшылап уйларга кирәк. Әгәр инде берәр җавапны онытып җибәрсәң, «Әдәплелек әлифбасын» актарып, аннан кирәкле һәм дөрес җавапны эзлә.

МОГҖИЗАЛАР КИРЕ КАЙТА

Фея кая югалган соң?

Ул инде сихерле йокысыннан акыллы-зирәк Гномнар, аждаһа һәм карга сөйләшә торган сәгатьне шак-шок төзәткән, ә Кумәчче белән Читекче аларга шау-гөр килеп төрлечә киңәшләр биргән тавышка әллә кайчан уянган икән. Уянган да, бик гаҗәпләнеп, үз-үзенә:

— Нишләп әле мин болай көпә-көндез йоклап ятам? — дигән.— Алай гына да түгел!..

Һәм шундук барысы да исенә төшкән...

— Ай-яй! — дип уйлаган ул.— Мин йоклаган арада коточкыч усал тылсымчы Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян әллә никадәр явызлыклар эшләгәндер инде. Тизрәк! Эшкә тотынырга! Тиз генә барысын да төзәтергә кирәк!

Саумы фея, зонтигын тапмагач, яраткан әбисе әллә кайчан бүләк иткән иске себеркегә атланды да, аллы-гөлле тәрәзәне ачып, очып чыгып та китте.

Шулхәтле ашыкты, хәтта аждаһа, Кумәчче, Читекче, карга һәм Гномнарны да күрмәде.

Тегеләре дә феяне күрми калдылар. Аның каравы сөйләшә торган сәгать күрде, шуңа тагын да ашыгыбрак һәм кычкырыбрак текелди башлады.

Шәһәр өстеннән очса да, бер җирне дә танымады фея.

— Әйтегезче, зинһар, кая соң мондагы шоколад өйләр? — дип сорады ул кечкенә генә сөйрәлеп тыкрыктан килеп чыккан берәүдән.

Әдәпсез узгынчы аңа ичмасам борылып кына да карамады.

— Гафу итегез...— диде икенчесенә. Анысы урам уртасына утырып чикләвек вата, ә кабыгын як-ягына ыргыта иде.— Түбәләр ник болай соры икән?

Ләкин бу кеше авыз чите белән көлеп кенә куйды.

Фея бераз парк өстендә әйләнеп йөрде дә ял итәргә дип җиргә төште. Парк эскәмиясендә зонтлар Сатучы йокымсырап утыра иде.

— Гафу итегез...— диде аңа Саумы фея.— Яңа зонт кирәк иде миңа. Сатмассызмы икән? Зинһар өчен...

Сатучы күзен дә ачмады:

— Ал...

Фея, зонтигын баш очында ача-ача:

— Менә рәхмәт! — дип сөенгән иде, шундук кәефе китте: — Очмый бит!

Сатучы:

— Ә кемгә кирәк аның очуы? — дип мыгырданды да яңадан гырлап йокыга китте.

— Ай! — Фея кайбер нәрсәләргә төшенә башлады.— Ахрысы, Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян олысына-кечесенә һәм башкаларга әдәпсезлек чире йоктырган. Шуңа күрә шәһәрдәге могҗизалар юкка чыккан. Әйе-әйе! Алай гына да түгел... Мин үзем генә, мөгаен, мондый явыз тылсымны җиңә алмам! Кем ярдәм итә алыр икән соң?

Шунда феянең исенә Кызчык-Бөтерчек килеп төште.

— Ул кызның гаҗәеп башмаклары бар. Шулай булгач, аңа бернинди явыз тылсым да куркыныч түгел!

Һәм фея, иске себеркесенә атланып, Хат ташучы өенә юнәлде.

...Боек Хат ташучы әле һаман, авызга үзләре сикереп керә торган күмәчләрне чәйни-чәйни, коточкыч тизлек белән диван тирәли йөгереп йөри. Тәрәзә янында утырган Кызчык-Бөтерчек шулхәтле дә үтә күренмәлегә әйләнгән, сөйләшә торган сәгатьле манараны аның аша рәхәтләнеп күреп була иде.

Кемдер ишек шакыды.

— Кем бар? — дип көч-хәл белән сорый алды Хат ташучы, күмәч чәйни-чәйни.

— Мин. Саумы фея.

— Ах! Фея!

Хат ташучы йөгереп килеп ишекне ачып җибәрде.

Шул арада мамыктай җиңел кызны коточкыч үтәли җил күтәреп алып бөтерелдерә башлады. Аннары билгесез тарафка очыртып алып китте!

— Ярдәм итегез! Тотыгыз! Тот! Ах! — дия-дия, йөгерек башмаклар кигән Хат ташучы кызы артыннан чыгып чапты. Янәшәдән генә иске себеркегә атланган Саумы фея оча иде.

— Могҗиза! — диделәр моны күргән олысы-кечесе һәм башкалар.— Күптәннән мондый хәлнең булганы юк иде!

Шул арада манарадагы сөйләшә торган сәгать тә суга башлады. Тизрәк уникене сугарга ашыга иде ул.

— Дең-дең! Даң-даң!..

Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның моны ишетеп коты алынды. Һәм ул, сәгатьне туктатырга дип, җан-фәрманга манарага йөгерде. Ләкин тылсымчының юлында көтмәгәндә фея пәйда булды.

— Гафу итегез,— диде ул әдәпле генә.— Сез үзегезне бик начар тотасыз. Сезне тәрбияләргә кирәк.

— Киии-крикүүүк! Тагын нәрсә! — дип, Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян кесәсеннән тылсымлы төнәтмә салынган лейкасын чыгарды.

Ләкин шул чак манарадагы сәгать сукты:

— Дең-дең! Даң-даң!

Лейкадагы төнәтмә кипте дә бетте. Алай гына да түгел... Коточкыч Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның яңгыравык көчле тавышы кинәт кенә әллә кая югалды. Аның каравы манарадагы калай әтәчләрнең барысы да кычкырыша-җырлаша башлады:

— Кии-кри-күүүк! Олыгыз-кечегез һәм башкалар! Гаҗәеп фонтан янына ашыгыгыз! Фонтанны бастырган авыр ташны алып ташлагыз! Шуннан сезгә гаҗәеп могҗизалар яңадан кайтыр! Якты дөньяда могҗизаларсыз яшәү күңелсез бит!

— Чыннан да...— диештеләр олысы-кечесе.— Могҗизаларсыз яшәүнең бер кызыгы да юк...

— Кая барасыз? Туктагыз! — дип Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян кычкырып калса да, һәммәсе җан-фәрманга фонтан янына йөгерделәр.

Сөйләшә торган сәгать тагын сукты:

— Дең-дең! Даң-даң!

Һәм коточкыч явыз тылсымчы каршысында, җир астыннан калкып чыккандай, әдәп-тәртип Сакчысы пәйда булды. Теге вакыйгалардан соң ул бөтен дөньяны очып әйләнгән, шулкадәр күпне күреп, шулкадәр күпне ишеткән, хәтта югалткан авырлыгын яңадан җыйган. Алай гына да түгел... Әдәп-тәртип Сакчысы аягында шулкадәр нык басып тора, хәзер инде аны бернинди җил дә очыртып алып китәрлек түгел иде.

Сакчы тылсымлы дип әйтерлек таягын селтәп җибәрүгә, сөйләшә торган сәгать төп-төгәл уникене сукты.

Коточкыч явыз тылсымчы Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян ничектер җыерылып-куырылып килде дә... асфальттагы рәсемгә әверелде дә куйды. Ә Саумы фея ул рәсемне тылсымлы себеркесе белән себереп үк ташлады.

— Менә шулай әйбәтрәк булыр...— диделәр яңадан чып-чын, теп-тере кешеләргә әверелгән әни, әти, ике әби һәм түти Ивановлар.

— Иптәшләр, гаҗәеп фонтан янында сезне аждаһа көтә,— диде аларга әдәп-тәртип Сакчысы.

...Ачы күз яшьләрен түгеп соры таш өстендә кечкенә аждаһа утыра. Читекче дә, Күмәчче дә, мәрхәмәтле карга белән акыллы-зирәк Гномнар да аны юата алмыйча аптырашка калганнар.

— Кызчык-Бөтерчек беркайда, беркайда да юк... Мөгаен, эрегәндер ул!..— дип үкси аждаһа.— Ә мин аңа ярдәм итмәдем, коткармадым!

— Елама. Әйдәгез әле бергәләп шушы авыр һәм әдәпсез ташны алып ыргытыйк! — дип, Саумы фея очып килеп җитте.

Үзе хакында әдәпсез дигән сүзне ишеткәч, соры таш кып-кызыл булып кызарды да билгесез әкияти тарафка очып китте. Фонтаннан күккә алтын-көмеш зәңгәр тамчылар чәчрәде.

— Теләкләр теләгез! — диде Саумы фея.

— Кызчык-Бөтерчек кайтсын! — диде аждаһа.— Зинһар!

— Алеша яңадан малайга әверелсен! — диделәр әнисе, әтисе, ике әбисе һәм түтисе, барысы беравыздан.— Зинһар өчен!

— Шәһәребезгә гаҗәеп могҗизалар кире кайтсын! — диде олысы-кечесе һәм башкалар.— Рәхим итеп, шуны эшләгезче!

Һәм барысы да нәкъ алар теләгәнчә булды.

— Ми-һа-һай! — дип мәйданга күбаяклы Тулпар ат килеп керде. Аның өстендә сау-сәламәт Кызчык-Бөтерчек утыра иде.— Мондый уен бик ошый миңа! Миһа-һай! Уйламаганда-көтмәгәндә өстемә күктән бер кыз сикерде! Һәм без аның белән Әкият-шәһәргә җилдерттек. Шоколад өйле, монпаси түбәле шәһәргә! Читекче йөгерек башмаклар тегеп, Күмәчче сикертмә-кабартмалар пешерә торган шәһәргә! Очар зонтлар сатыла торган шәһәргә!

Ми-һа-һай! Миңа әкияти-әдәпле шәһәрдә яшәү бик ошый! Әмма хәзер үк җир шары тирәли сәяхәткә китү тагын да кызыграк! Атланыгыз миңа, малайлар-кызлар! Ерак-ерак илләргә, күз күрмәгән җирләргә китәрбез! Кешеләр әдәпле, яхшы күңелле, бер-беренә мәрхәмәтле булырга тиеш! Җир йөзендәге балаларның барысы-барысы-барысына да шуны сөйләп аңлатырбыз.

Аның белән һәммәсе дә ризалашты.

Алеша Иванов, Кызчык-Бөтерчек һәм башка малайлар-кыз-

лар һәммәсе, күбаяклы Тулпар атка атланып, ерак илләргә җилдерттеләр.

Ә әниләре, әтиләре, әби-бабайлары, агай һәм түтиләре болай дип кычкырып калды:

— Хәерле юл!

Фея сорау бирә:

1. Ни сәбәпле Саумы феянең сорауларына узган-барганнардан берәү дә җавап бирмәде?

2. Ни өчен Гөрби-Гөрби-Гөрби-Янның тамчы да әдәпле буласы килми? Ни өчен аның дуслары юк?

3. Син кинәт юкка чыккан тылсымчыны кызганасыңмы? Кызганмасаң, сәбәбен әйт.

4. Әкият-шәһәр кешеләренең теләкләре яхшымы, әллә начар идеме? Ә син нинди теләк теләр идең?

5. Хәзер бу әкият геройларының кайсына охшыйсың килә? Кайсы белән дуслашыр идең?

6. Ә чынында син бу геройларның кайсына охшаган? Ә кемгә бик-бик охшарга тырышасың?

ӘКИЯТ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

Беренчедән, әкиятне укыганда без үзебезне дә шул дөньяда дип хис итәбез.

Менә әкрен генә кыштырдап китап битләре ачыла да безне әллә кайдагы, җир читендәге әкият иленә алып кереп китә. Менә без әкият геройлары арасында. Алар белән бергә сөенәбез, алар белән көенәбез...

Икенчедән, рәсем ясаган чакта да без әкият илендә. Кулларыбызда карандаш, пумала, кәгазь, буяу теләсә нинди әкияткә җан кертә: аллыгөлле чәчәкләр зәңгәр күккә үрелә, болытлар арасында ай белән кояш бии...

Театрда яисә кинода утырганда да әкият дөньясында без. Тирә-юне-

без кап-караңгы. Ә әкият менә ул, янныбызда гына: сәхнәдә, экранда яши.

Син дә, дустым, әкият иленә барып кайттың. Чөнки безнең әкиятне укыдың.

Хәтта бер тапкыр геройларының рәсемнәрен дә ясадың (биремнәрне эшләп барган булсаң, әлбәттә). Шулай да мин сине барлык дусларың белән бергәләп тагын бер тапкыр Әкият-шәһәргә, әкият геройларының кайберләре белән очрашуга чакырам. Моның өчен өеңдә әкият театры оештырырга кирәк булыр. Бу катлаулы эшкә берүзеңнең генә көчең җитмәстер, мөгаен. Ярдәмгә әти-әниеңне, дусларыңны чакыр.

Иң элек сезгә рәссам-декораторлар булырга туры киләчәк. (Һәрбер театрда шундый рәссам була.)

1 нче бирем. Зуррак бер бит кәгазь алыгыз да аны гармун кебек сырлап бөкләгез. Шул бөкләнгән кәгазьгә өй түбәләренең контурын төшерегез. Рәсемне пөхтә итеп кисеп алыгыз да сүтеп җибәрегез. Менә Әкият-шәһәрнең декорациясе әзер дә булды. Кайбер вак-төякләрне генә ясап буйыйсы калды.

Бүлмәдә чып-чын Әкият-шәһәр барлыкка килерлек итеп, декорацияләрне тезегез.

2 нче бирем. Калын кәгазьгә шушы әкият геройларының маскаларын ясагыз, аннары кисеп алыгыз. Таныдыгызмы?

Ә хәзер, дустым, иптәшләрең белән сезгә артист булырга туры килер. Берегез Алеша-аждаһа булса, икенчегез — Кызчык-Бөтерчек, өченчегез — фея, дүртенчегез — явыз тылсымчы Гөрби-Гөрби-Гөрби-Ян, бишенчегез — Читекче, алтынчыгыз Күмәчче булыр.

Ни өчен теге я бу геройны сайлавын, әкиятнең бу персонажы аңа ни өчен ошавын һәрбер «артист» үзе сөйләп аңлатса, арагызда бернинди бәхәскә дә урын калмас. Алай-болай бәхәс чыга-нитә калса да тыныч кына, санамыш белән хәл итегез.

3 нче бирем. Әкиятебезне кыска һәм ачык аңлаешлы итеп сөйләү юлларын әбиегез, әниегез яисә өлкәннәрдән башка берәрсе белән уйлагыз.

Менә шулай сезнең пьесагыз (яисә сценариегыз) әзер дә булыр. Ә уйнарга җиңелрәк булсын өчен, бу пьесаны (сценарийны) берничә күренешкә бүлегез.

1 нче күренеш. Алеша явыз тылсымчы рәсемен ясый.

2 нче күренеш. Алеша аждаһага әверелә.

3 нче күренеш. Аждаһаны базарда саталар. (Аны кем сатып ала? Ничек итеп Кызчык-Бөтерчек кечкенә аждаһаны коткара?)

4 нче күренеш. Кызчык-Бөтерчек эреп югары башлый.

5 нче күренеш. Саумы феяне йокысыннан уяталар. Могҗизалар кире кайта.

Декорацияләр, геройларның маскалары һәм пьеса әзер булгач, репетиция ясагыз. Уеныгыз бик яхшы чыксын өчен, сценариегызны берничә тапкыр (тәмам исегездә калдырганчы) уйнап карагыз.

Ниһаять, берничә көннән, пьесаны ятлап бетергәч, «Әдәплелек әлифбасы» бәйрәме үткәрергә мөмкин. Бу бәйрәмгә калган дусларыгызны да чакырыгыз. Тик аларның һәммәсе дә әдәплелек имтиханын тапшырсын. Аннан соң дусларыгызны Әкият-шәһәргә, үзегез, ягъни кечкенә әкиятче-артистлар уйнаячак әкияткә чакырыгыз.

...Хәзер, дустым, синең белән, иптәшләрең белән саубуллашыр вакыт җитте. Хәерле юл телим сезгә!

ЫШАНЫЧ КҮРСӘТЕП ТӘРБИЯЛӘҮ

Бу безнең соңгы сөйләшү, кадерле әтиәниләр, бабайлар һәм әбиләр... Минем сезгә әйтер сүзләрем күп иде. Әмма педагогиканы, тәрбия сәнгатен (хәтта әдәплелек әлифбасына кагылган өлешен генә дә) колачлап бетерү мөмкин түгел.

Ниндидер бер акыл иясе: «Педагогика — фән түгел, ә рухи халәт ул»,— дигән. Моңа тагын: «искиткеч гүзәл рухи халәт»,— дип кенә өстәргә була.

Тәрбияче ата-ананың, педагог атаананың тормышы хезмәт һәм бәхет белән тулы. Җир йөзендә иң кадерле нәрсә — балалар күңелен иҗат итү бәхете ул! Йөрәгебездә шушы бәхетне тоймыйбыз икән, димәк, нәрсәнедер дөрес эшләмибез, кайдадыр ялгышканбыз. Димәк, гадәтләребезне, балаларга мөнәсәбәтебезне өр-яңадан тәнкыйть күзлегеннән карап чыгарга, тормышыбыздагы күп нәрсәләр хакында уйланырга, холкыбыздагы, тирә-юньгә мөнәсәбәтебездәге күп нәрсәләрне үзгәртергә кирәк.

Ата-аналар, тәрбиячеләр буларак киткән ялгышларыбызны, уңышсызлыкларыбызны бәләкәчләр җилкәсенә аударырга безнең хакыбыз булмады, юк һәм бервакытта да булмаячак. Ата-ананың балага җәза бирүе — аның тәрбия өлкәсендә кайчандыр үзе җибәргән ялгышларын, уңышсызлыкларын, наданлыгын һәм булдыксызлыгын тануы ул. Кем безгә баланы, бигрәк тә сабый баланы, тупас кычкырып яисә тән җәзасы белән рәнҗетү хокукын биргән әле? Яклаучысыз нәни кызыбыз йә улыбызга кул күтәреп, без, өлкәннәр, үзебезне гаять ямьсез, шыксыз яктан күрсәтәбез.

Сабыйларның безгә, өлкәннәргә булган ышанычы, мәрхәмәтлелегебезгә, атааналар буларак гадел, акыллы һәм киң күңелле булуыбызга ышанычы — искитәрлек могҗиза бит ул. Бу ышаныч кимчелекләребездән, җитешсезлекләребездән арынырга ярдәм итсен.

Без үзебез дә аларга ышаныч белән карарга, шәфкатьле булырга тиеш.

Таләпчән булырга, әмма назга да саранламаска кирәк. Таләпчәнлегебез дә дустанә булсын, өлкәннәрнең үзенә ышаныч күрсәтүен сабый һәрчак сизеп, тоеп торсын.

Шушы ышаныч баланың үз мөмкинлекләренә инануын ныгыта, өлкәннәргә ярдәм итү теләген уята.

Ата-аналар баланы бүгенге уңышсызлыклары өчен ачуланмаска, холыксызланмаска, белгәннәрен сабыр гына аңлатып, төшендереп бирергә тиеш.

Балалы гаиләдә ягымлы кайгыртучанлык атмосферасы хөкем сөрсен. Үз көченә инанган, кешелекле оптимистларны бары шундый мохиттә генә үстереп була. Мондый атмосфера сабыйны актив эшчәнлеккә дәртләндерә.

Әлбәттә, балаларны без тәрбиялибез. Әмма гамьсезләнергә, ялкауланырга ирек бирмәүләре, тирә-юньгә мөнәсәбәтебезнең үткенлеген, сафлыгын саклап калырга ярдәм итүләре, алдыбызга яңадан-яңа катлаулы мәсьәләләр куеп торулары белән алар да безне тәрбияли бит.

Безнең бөтен тормышыбызның нәтиҗәсе, дәвамы һәм мәгънәсе — балалар. Алар шәфкатьле, акыллы, сәламәт һәм бәхетле булып үсәргә тиеш. Әмма моны тәрбия процессының үзен шәфкатьле, акыллы, сәламәт һәм бәхетле иткәндә генә эшләп була. Моңа бала җанының никадәр нәфис һәм шул ук вакытта күндәм механизм икәнлеген аңлап, балаларның эш-кыланышларына әдәпле һәм

зирәк бәя бирергә өйрәнеп кенә ирешергә мөмкин. Ә бәлки безнең белән биргәләп баланың тәнен генә түгел, рухын, җанын да тудырган, иҗат иткән табигатькә дә күбрәк ышану, тәрбия эшен табигать иркенә дә күбрәк кую кирәктер? Улларыбыз һәм кызларыбызның даһи кызыксынучанлыгын, дөньяга якты карашын, хикмәтле фантазияләрен, балалар рәсемендәге кебек кызгылт-йонлач кояш астындагы җирдә яшәүче барча җан иясенә мәңгелек мәхәббәтен, ышанычын уята алган борынгы һәм мәңгелек анабыз Табигать, мөгаен, сукыр да, чукрак та, акылсыз да түгелдер!

Табигатькә мондый ышанычны ата-аналарның томана битарафлыгына тиңләргә ярамый... Табигатьне бозмыйча, юкка чыгармыйча, аның мәңгелек законнарын өйрәнеп, ул законнарның үсешен игътибар үзәгендә тотып иҗат итүче кешенең акыллы карашына тиңләп була аны.

Баланы эчпошыргыч мораль, катгый боерыклар белән түгел, ә ата-аналарның көндәлек уңай мисалы һәм уеннар белән тәрбияләргә кирәклеген безгә нәкъ менә шул законнар күрсәткән иде инде.

Ата-аналарга, мөгаен, шушы нәрсәгә ныклап игътибар итү тиештер.

Бүгенге әти-әниләр иң элек дөрес фикер йөртергә сәләтле, кешелекле, эшчән, түзем һәм ярата белә торган итеп үз-үзләрен тәрбияләргә, армый-талмый культура дәрәҗәләрен, белемнәрен күтәрергә тиеш.

Балалар уенны бик ярата. Тәрбия процессында шуннан файдаланып, уен аша баланы хезмәткә, культурага өйрәтергә, аның акыл үсеше өчен зарур яңа мәгълүматлар биреп барырга кирәк. Сабый уйлый белсен, эш-гамәлләренә бәя бирә белсен. Балаларыбызны дусларыбыз итеп тәрбияләүгә бөтен сәләтебезне җигәргә тиешбез.

Боларны эшләү җиңел түгел. Әмма бүгенге ата-аналарның ярдәмчеләре дә күп: алга киткән фән, сәнгать, балалар бакчалары, мәктәпләр. Әгәр дә, кадерле әтиләр, әниләр, бабайлар һәм әбиләр, шушы китапны да ярдәмчеләрегез исәбенә кертсәгез... Әгәр дә ул сезнең игелекле гаилә дустына әверелсә, мин бик бәхетле булыр идем.

Уртак эшебездә сезгә уңышлар телим.

Васильева-Гангнус Л. П.

B 19 Әдәплелек әлифбасы./Русча икенче басмадан Ф. Г. Иштирәкова, Р. И. Раскулова тәрҗ.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 110 б.: рәс. белән.

ISBN 5—298—01110—1

Әдәплелек әлифбасы — үз-үзеңне культуралы тотуның мәҗбүри кагыйдәләре җыелмасы гына түгел, ә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны әдәплелек күнекмәләренә өйрәтүдә ярдәм күрсәтүче киңәшче дә.

Бу — балалар, ата-аналар һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре тәрбиячеләре өчен әкият-китап, әкият-уен, балаларда әхлак тәрбияләү теориясе һәм практикасының үзенчәлекле «әлифбасы».

В $\frac{4312000000—046}{М\ 132(03)—92}$ БЗ—58—53—91 ББК 74.113

Издание для детей и юношества

Людмила Петровна
Васильева-Гангнус

АЗБУКА ВЕЖЛИВОСТИ

(Перевод с русского на татарский язык)

Второе издание

Редакторы *А. Ә. Тәхәвиев*
Художество редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Р. М. Галимова*
Корректоры *Д. Р. Мифтахова*

ИБ № 6315

Җыярга кул куелды 20.08.91. Басарга кул куелды 14.12.92. Форматы $70 \times 90^{1}/_{16}$. 80 гр. офсет кәгазе № 1. «Т. Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,19. Шартлы буяу-оттиск 33,93. Нәшер-хисап табагы 6,97. Тиражы 10 300 экз. Заказ К-364. С-43.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе. 420111. Казан, Бауман ур., 19.